# ТОРМЫШМЫ БУ?

«Бер шәкертнең хатирәләре» дигән исем берлә кулыма төшкән шул дәфтәр безнең тормышымызның иң җәрәхәтле йирләрене ачканга, бик күп яшьләремезнең тереклегенә охшаган бу бәхетсез шәкертләрнең буш, мәгънәсез гомеренә карау минем күңелемдә дә шул: «Тормышмы бу?» дигән сөальне китергәнгә, үзем хәл кыла  алмаган шул мәсьәләне, бәлки, укучыларым хәл кылыр, мин җавап таба алмаган сөальгә, бәлки, анлар табар дип, шул «Тормышмы бу?»ны китап итеп бастырырга  уйладым.

*Мөхәммәтгаяз  әл-Исхакый*

## 1

Без хәзер әти берлә чәйдән кайттык. Чәй эчкәндә, бербуйдан бүлмә ярыгын кайчылар, чыралар берлә зурайтып, кызлар карап тордылар. Мине быел карчыклар да: «Зураеп кайткан, егет булган»,—диләр. Булганмын шул! Элгәре мине маңка сарыгы дип мыскыл итә торган күрше кызлары, минем берлә су буйларында бәпкәләр саклаучы Миңлебай кызлары бары да миннән качалар. Күрше хатыннары да, мине күргәч, яулыкларының очларын тешләренә кабып, минем берлә исәнләшмичә китәләр. Карчыклар да: «Зур булды инде, Алла хәерле бәхет бирсен, атаң урынында картай»,— сүзләренә, әни алдында мине кызартып: «Матур бикәч бирсен!» — диләр. Урамнардан үткән вакытта да кешеләр: «Нинди зурайды, әле генә малай иде, шәһәр суы килеште»,— дип сөйләп калалар. Мине күрү берлә тәрәзәләргә кызлар атылалар. Чыннан да, мин шул хәзер кызлар кызыгырлык егет булганмын, ахры. Кызлар карый башласа, үземнең йөрәгем сирәк сикерә башлый. Бик якыннан карасалар, колакларым, битләрем ут кеби яна башлый. Бүлмә ярыгы аркылы «фәлән» кызлар күзе берлә күзем очраса, никадәр карыйсым килсә дә, ихтыярсыз күзем түбән төшә. Мин аларнын күз карауларына каршы, әллә нәрсә эрегән кеби

булып, йомшарып-изрәп китәм. Әллә нәрсә оят кеби була, үземне үзем били алмый башлыйм. Тәннәрем калтырый башлый, аяк өстендә басып торырга хәлем калмый. Шуның өчен мин кызларны үзләре караганны белмәгәндә яшеренеп карарга яратам. Ул вакытта мин озак иттереп, анларның һәр әгъзаларыны карап бетерәм. Анларның йөзләрене, күзләрене, кашларыне, керфекләрене, авызларыны, иреннәрене, билләрене, күкрәкләреен җентекләп карыйм. Анларның шул авызларыннан үбәргә, билләрене кочарга фаразына чумам. Анларның хыяллары берлә кочына, уйнаша башлыйм. Ләкин анларның минем каравымны сизүләре минем бөтен кәефемне боза. Мине башына салкын су койган кеби итеп, баягы фараз кыз урынына исән, терек, селкенә вә хәрәкәтләнә торган кызны китереп бастыра. Мине, тагы анлардан оялыпмы, куркыпмы, күземне алырга, яисә анлар күрми торган кечкенәрәк ярыктан карарга мәҗбүр итә. Мин кайвакытта шул кызлар берлә күзем күзгә очрашкач, күз кысарга да яисә бармак селкергә дә уйлыйм. Ләкин вакыты җиткәч, күземнең кабаклары кадаклап куйган кеби селкенми, бармагым урынннан кузгалмый. Мин үземнең булдыра алмавым өчен үземне шелтәли башлыйм. Ахырдан: «Ярый әле, селекмәү яхшы булды, ул әнисенә әйтер иде. Әнисе минем әнигә әйтеп, мине оятлы ясар иде»,— дип шатланам да. Тагы, шуның өстенә, кызлар берлә уйнашу бит яхшы эш түгел!

Әти берлә безнең мөнәсәбәтебез яхшы. Әти миннән әллә ничә сүз сорады. Мин һәммәсенә җавап бирү генә түгел, әти берлә моназарә кылышып китеп, әнине куркыттым да. Ләкин җәй көне өйдә бер эш тә булмау уңайсызрак. Күңел берлә әллә ниләр эшләсе килә. Нишлисең, эш юк! Йөрешергә-нитәргә дә кеше юк. Мужик малайлары берлә уйнап йөрергә миңа килешми дә инде. Мин — Казан шәкерте. Егетләре берлә йөрергә тагы килешми. Анлар соң ни беләләр! Анлар шул бик җамидләр. Кызлар берлән йөрергә тагы шул баягы бер...

*28 нче май, 1895 нче ел*

## 2

Ягъмурдан соң көн матураеп китте. Мужиклар бары да эчләреннән бәйрәм итәләр. Бүген көн буе кулларына таяк тотып, мужик картлары ашлык карарга баралар. Сабан ашлык кырында хәзер кара җирләр бер дә калмады. Бөтен кыр ямь-яшел күренә. Арыш кыры азрак дулкынылана да башлады. Безнең бакча да матурланып киткән. Мескен агачлар бу арада бик моңаеп торалар иде. Бүгенге һавалылыкларын күрсәң, исең китәр! Кичәге тузан берлә буялып беткән яфраклар бүген зәмрүд кеби ямь-яшел торалар. Кичә үләм-үләм дигән кеби тора торган агачлар бүген, яшь егетләр кеби, яшел яфраклары берлә шаулашып торалар. Тәмле иттереп юеш исе килә.

Мин ындырга барып кайттым. Андагы үләннәр дә бик матураеп үсәргә хәзерләнеп торалар. Күрше ындырда Шакирның ике кызы ындыр табагы ябып маташалар иде. Мин килгәнне күреп, бүре кеби, куышка керделәр. Безнең якка чыга торган читәнне шытыр-шытыр сындырып тишекләр ача башладылар. Мин куыш янына бик киләсем килсә дә, бара алмадым. Яхшы түгел, йә шунда аналары бардыр, яисә күрше ындырдан, йә авылдан бер-бер кеше күрер. Үзләренең куышта икәнлеген белдерер өчен кеби кычкырып көлешәләр.

Мин анлар чыгып киткәч кенә куыш янына килеп, ярыктан карый башладым. Эчемнән анлар берлә сөйләшергә уйладым. Ләкин ничек сүз башласы? Ничек? Тагы бит алар — икәү! Исеме берлә: «Фәхриҗамал!» — дип дәшсәң, берсенең хәтере калыр. «Миңлесылу!» — дип дәшсәң, икенчесенке. Миңлесылуы куышка керде дә минем тарафка сәнәге берлә чүп ыргытты. Әллә белеп, әллә белмәенчә, ләкин мин куркып киттем. Мин бик озак уйлап торганның соңында: «Миңлесылу җаным!» — дип дәштем. Ләкин үз тавышыма үзем куркып, теге ишеткәнне-ишетмәгәнне белмәенчә дә торып, ындырның теге ягына киттем. Менә анлар үзләре сөйләшә башласалар иде!

Фәхри карт зияраттан кайтышлый минем яныма туктап кәефне изде. Кызлар ындыр табагын ябып бетереп кайтып киттеләр. Мин дә Фәхри карт берлә, аның киленнәрен яманлаганыны тыңлый-тыңлый, өйгә кайттым.

Бүлмәдә әни янында әллә нинди хатыннар чәй эчәләр. Менә элгәрерәк булса, мин дә шунда сәке янына утырып кына чөй эчәр идем. Хәзер шул инде юк. Мин менә шундый хатыннарның бертуктамаенча гайбәт сатуларыны яратам. Бүген тагын көн үтә. Эш юктан, ичмасам, намазга барып килим. Анда да буш, әллә нәрсә тулмаган кеби күренә! Берәр көннән, булмаса, әбиләргә кунакка барып килергә кирәк.

*3 нче июнь, 1895 нче ел*

**3**

Көтмәгән җирдән мулла җизниләр килеп төште. Өй бераз җанланып китте. Кичә кунаклар янына дип авылның байгураларыны ашка чакырдык. Мин хуҗа кеби булып ашлар ташыдым. Мулла җизни берлә түбән оч мулласы саилченең сәламен алу тиешме-түгелме хакында бик каты моназарә кылыштылар. Ахырдан, аш уртасында, әти китап киштәсеннән «Ибне Габидин»не алдырып, шуннан сәлам алуның тиеш түгеллеге хакында гыйбарә күрсәтте. Ул шуннан соң үзе дә көлеп куйды. Эченнән үзенең шул яшь муллаларның бәхәсләрен тиз хәл кылуына бераз һаваланды булырга кирәк. Байгуралар да бер-берсенә карашып, акрын гына: «Бу бүтән шул, бүтән!» — дип, әтине мактый башладылар. Берсе акыртын гына: «Тирә-якта бер инде!»—диде. Яшь муллалар да, әтигә бик кызыккан кеби, әллә нинди бик олуг кешегә караган кеби карыйлар кеби күренде. Безнең әти шәп инде. Ул нәхүне белә, мантыйкны белә, фикъһене белә, гарәпчә бик оста, фарсыча бик оста. Шуның өстенә бик динле, бик ихласлы, бик яхшы. Яшь муллалар кеби, базардан базарга йөреп вакытын уздырмый. Әллә ниләрне хәйлә итеп, авылдан авылга кунакка йөрми. Өч тәңкә акчага бөтен динен сатып, теләсә кемнең хатыныны аерып йибәреп, теләсә нинди хатынга никях укымый. Аның бар белгәне — мәсҗед берлә мәдрәсә. Шуның өчен шул аны мәхәллә халкы да ярата, тирә-як халкы да олылый. Мине дә әтисе төсле булыр диләр.

Аштан чәйгә калган кешеләр арасында мин, туп атып болыттан ягъмур яудыруларны һәм дә Төрек берлә Англия политикасын сөйләп, үземнең мәгълүматым күплегенә исләрен китәрдем. Ахырдан солтанның,

гакыллылыгы берлә Викторияне алдап, Мисырны кайтарып алуыны сөйләдем. Муллалар, мужиклар мөселманның кяферне җиңүенә бик шатландылар. Әти шуннан соң мөселман мәмләкәтләренең таралуы, Бохараның китүе, Шамилнең җиңелүе, Төрекнең мәгълүб булуы хакында фикерләрен сөйләде. Анларның барысының да сәбәбе «низам» дигән булып, башка падишаһларга ияреп китеп, шәригатьне аяк астына таптау, имеш.

Мин кич берлә, әтиләр намазга киткәч, әниләр, Шәрифә абыстайлар берлә чәй эчтем. Анларга мәдрәсәнең ниндилеген, шәкертләрнең ничек торуларымы сөйләдем. Сөйләгәндә, әлбәттә, үземезнең мәдрәсәнең шәкертләрене, хәзрәтен мактап, башка мәдрәсәләрне яманлап сөйләдем. Инде безнең мәдрәсәдә дә усал, начар шәкертләр бар барын да, мин инде анларны башка мәдрәсәләргә багышлап сөйләдем. Ахрысы бит үз мәдрәсәңнең исемене сату ярамый инде. Әни шунда: «Соң, анда тәмәке тартучылар булмыймы, син тартмыйсыңмы? Мин бер дә тәмәке тартуны яратмыйм»,— дип куйды. Мин, әлбәттә, тартмыйм, мин андый эшне яратмыйм, мин эчмим, тәмәке тартмыйм, башка китап кушмаган эшләрне эшләмим. Алай гына ярамый бит, кыямәт бар. «Вәлбәгъсу бөгьдәл мәүти хак».

*5 нче июнь, 1895 нче ел*

## 4

Мин тышка чыккан йирдән, тәһарәтханә ярыгыннан, күрше кызы Галимәне карап тордым. Әни аны кунак-төшем булганга кул арасына керешергә чакырган. Ул мунчаның идәнен юып кайтышлый йорт уртасында, яшел чирәм өстендә, яланаяк көенчә чиләкләр, савытлар юа иде. Аның сызганган җиңе астында калын, тулы, былт-былт итеп тора торган беләге күренә иде. Юешләнгән күлмәге дә күкрәгенә ябышып, аның күкрәгенең кайсы төше биек, кайсы төше чокырлы идекен тәмам ачык күрсәтә иде. Ул кулы берлә ышкып-ышкып агач савыт юганда, аның күкрәкләренең лып-лып итеп селкенүе дә күренеп тора иде. Мин бик озак үземне үзем онытып шуны карап тордым.

Башымнан әллә нинди уйлар үтте. Әй шуның шул тулы кулларын кысып торып, таза тәнен кочакларга! Әй шуның сулаганда бер күтәрелә, бер төшә торган имчәкләренә башымны куеп торырга! Мин шуны үбәргә, кочакларга төрле уйлар кордым. Бердән хәзерлән чыгып шуны кочакларга уйладым. Ләкин, Алла сакласын, ул кычкырса яисә кеше күрсә, харап буласың бит! Шуннан ул лапас астына кермәсме дип, шунда керсә, өстенә керергә уйлый башладым. Анда да керде. Янына чыгарга вакыт җиткәч, әллә нәрсә аякларым калтырый башлады. Ихтыярым бетте, чыга алмадым. Мин тагы план корганча, ул кереп китте. Ярый әле, андый-мондый җиңелчә уйлап ташлап, кунаклар алдында оятлы булмадым. Ни уйласаң да, кызлар берлә уйнау бит гөнаһ инде! Минем болай да гөнаһым бик күп әле. Менә хәзер баягы күңел гөнаһым өчен намаздан соң тәүбә кылдым. Ләкин Галимәнең үтеп китүе тагы нәфесемне кузгатты. Усал бу каһәр суккан шәйтан, мөселманның тәүбәсене карап кына тора!

6 нче июнь, 1895 нче ел

## 5

Кунаклар килү файдадан хали булмады. Без инде өч көннән бирле иртәдән кичкә кадәр ашка йөримез. Минем кесә дә шактый файда итте. Кайтканга ике атна вакыт үткән, мин инде бер сум сиксән тиен акча җыйдым. Җәй шулай үтә. Казанга киткәнчә ун тәнкә акча җыям. Баргач та, Аллаһе теләсә, чалбар, камзул тектерәм. Бүген түбән оч мулласына ашка төшәмез. Мулланың балдызы бунда диләр, күреп булса ярар иде. Матур, ди.

Минем сәгать юклыгы кәефсезрәк. Мулла җизнинең дә, түбән оч мулласының да сәгатьләре бар. Минеке юк.

Бүген көн бик эссе! Коенырга барырга бик шәп булыр иде... Унайсызрак. Ничек итеп малайлар берлә коенып йөрергә кирәк. Менә монда Казандагы кеби купальнялар булса, һәйбәт булыр иде. Юк шул. Иртәгә кунаклар китәмез диләр. Күңелсез булып калыр. Әле мулла җизниләр мунчада. Бик кызык, кунак

килдисә, безнең әни мунча ягарга тотына. Кунакларны иртүк уятып, мунчага җибәреп, мазаларын китәрә. Мин шуны бер дә яратмыйм. Алай да, мунчада кызарып-пешеп беткән мулла җизни берлә лимон йә бал берлә чәй эчәргә яратам.

Бүген дә мулла җизни берлә чәй эчтем әле. Йа ул күп эчә! Ничек карын ярылмый! Утыз чынаяк эчкәндер! Әнә бер мужик ат җигеп ашка алырга килде. Тизрәк хәзерләнергә кирәк. Безнең әти кеше көттерүне яратмый.

Бүген тагы сигез җиргә ашка барырга. Корсак кына чыдасын инде. Акчасы күпме булыр икән? Менә бар да бишәр тиен бирсә, кырык тиен булыр иде, ләкин күбесе өч тиен бирә яисә ике тиен. Мулла бер тиен дә бирми инде. Минем кара бүрекне әти яратмаса да, шуны киям инде.

*9 нчы июнь, 1895 нче ел*

## 6

Кунаклар киткәч, өйләр ташландык йорт кеби буп-буш калды. Кунаклар, аларның балалары берлә шау итеп, куәтле умарта кеби гөрләп тора торган өй тынланды, моңланды. Бу көннәрдәге ягъмур да, соңгы матур ачык һава да кунаклар берлә бергә китте. Кичә кичтән бирле әллә нинди, яз көне бик сирәк була торган вак ягъмур болыты бөтен дөньяны каплаган. Болытлар, башка төшәм дигән кеби, түбәннән генә акыртын гына агып, матур күк күкне, ялтыраган кояшны каплап, бөтен дөньяга моңлык, ялкаулык йоктыралар.

Мин, бик озак йоклап, сәгать тугызда гына көчкә уяндым. Өй түбәсенә шыбыр-шыбыр яуган ягъмур тавышлары йокы арасына кереп, әллә нинди төшләр күрсәттеләр. Чәйнең дә тәме булмады, әти, әни берлә дә сүз сөйләнмәде. Чәйдән соң нишләргә белмәенчә тышка чыктым. Тавышсыз яуган ягъмур, йокы арасында баса торган албасты пәрие кеби, мине акыртын гына һәр ягымнан кочаклый, изә башлады. Мин, үземнең нишләргә теләгәнемне белмәенчә, нишләргә дә кирәклеген уйлый алмаенча, келәт янына утырдым. Ихтыярсыз күзләрем суга туеп бетеп өстләре каралган җиргә текәлде. Йир

йотып бетерә алмаган өстендәге су бөртекләрене, анлар өстенә вак ягъмур төшеп, анларның төрле төсле селкенеп китеп, өстләренең шәүләләр берлә каплануларын карап торып, башымдагы фикеремнең шул ягъмур шәүләләре берлә каплануыннанмы, анларны сузып, артык алга йибәрә алмадым. Мин башымның уйсыз-нисез туктап торганын хис итеп, шул эшсезлеккә каршы нишләргәлекне уйлый алмадым. Менә әллә кайдан бак-бак дигән тавыш чыкты. Бер үрдәк артыннан берникадәр үрдәк балалары сөйләшә-сөйләшә почмакка җыелган суга таба барып, суда былчырана, быкырдый башладылар. Мин шунларның быкырдауларын күреп, минем өчен шулкадәр кәефсез көннең анлар өчен бәйрәм булу ихтималы барын уйлап, төрле хайванның төрлечә ратуларыны, төрлечә шатлануларыны вә төрлечә кайгыруларын уйладым. Менә хәзер бу үрдәкләр кычкырышып-кычкырышып бәйрәм итәләр, сөйләшәләр, шаулашалар, шул ягъмур өчен Аллага рәхмәт укыйлар. Мин шул ягъмурдан туеп, үземне үзем кая куярга урын таба алмый торам. Шулайдыр шул, һәртөрле үзгәрүдән төрле халыкка, төрле хайваннарга файда була торгандыр. Корыдан кирпеччегә файда була, игенчегә зарар була. Иген уңудан ярлыга файда була, байга зарар була. Тагы әллә ниләр, әллә ниләр.

Никадәр йокласам да, йокы туймаган төсле күренә. Ахрысы тагы аштан соң бераз йокларга кирәк. Түбәгә шыбыр-шыбыр итеп ягъмур яуганны тыңлап бераз ләззәтләнергә кирәк.

*12 нче июнь, 1895 нче ел*

## 7

Кичә ягъмур туктаганга, бүген кояш бик күптән бирле шул дөньяны яктырта алмаганы өчен, шул көннәрнең казасыны кылган кеби яисә аның яктылыгыннан пәрдә булып каплап торган болытларны җиңгәнгә «җиңү бәйрәме» иткән кеби, аның дөньяга сыймый торган яктылыгы, һәр караңгы нәрсәне яктырта торган нуры берлә бөтен нәрсәләрне йомшак кына иттереп кочаклаган, бөтен дөньяны нуры берлә тутырган иде. Аның ямь-яшел кырларга, моңлы-куркынычлы урманнарга, сузылып яткан ялтыраган суларга

күз кысулары, анларга төрле мәгънәләр аңлата торган елмаюлары, яшел кырларның, чәчәкләр берлә бизәлгән болыннарның, һавалы урманнарның аңар каршы башларын акыртын гына иеп, аңар каршы нәфис исләре берлә сәлам җибәрүләре; кыр тургайларының, шул сәламнәрне алып тизрәк хуҗасына бирергә ашыккан кеби, җырлый-җырлый, борылып-бормаланып кояшка таба очулары; аллы-гөлле төстәге күбәләкләрнең хәтфә кеби йомшак канатлары берлә шул саф һаваны яшелле, сарылы, кызыллы, аллы йолдызлар берлә бизәкләүләре; төрле бал кортларының матур тавыш берлә кызуланып, бер чәчәктән икенче чәчәккә күчеп бал җыюлары — һәммәсе бу көнгә бик зур бәйрәм төсе бирә, бу көнне гади көннәрдән аера иде.

Авылларның урамнарындагы яшел чирәмнәрендә бертуктамаенча ат-ат, куян куышы, ат карагы уеннарын уйный торган балалар һәм дә, яшел чирәмнәргә корсаклары берлә сузылып ятып, елның матурлыгыннан, яхшылыгыннан шатланып, иске елларны, иске эшләрне, авылларның януларыны, атларның үлүләрене, казна өчен әйберләр сатуларыны, солдатка китүләрене сөйләп, иске хатирәләрен яңарта торган агайлар; урамнарда көтү-көтү тавыкларның әтәч әфәнденең командасы астында сузып-сузып кырлаулары; әтәчнең авылның башка урамындагы әтәчләр берлә кычкырышып сөйләшүләре — бу манзарәне тагы матурлата, аңар тагы күбрәк мәгьнә бирә иде. Мин дә, шул матурлыкка хәйран калып, шул матурлыктан ләззәтләнеп озак кына карап торганның соңында, әбиләргә барыр өчен тарантасны майлап, ат җигәргә тотындым. Ат та, бу матур көннең гади бер көн түгел икәнлеген белгән кеби, шул матурлыкның әллә нинди тулмаган җирен хис итеп, шуны тутырыр өчен кеби, бик матур итеп кешнәп йибәрде. Саф һава калтырап китеп, атның кешнәве тавышы колаклардан китәргә өлгерә алмады, авылның тагы бер тарафыннан җавап кешнәве килде. Ат, минем җигәргә маташканыма илтифат итмәгән кеби тагы башын күтәреп, тагы кешнәп куеп, шул кешнәүләрдә әллә нинди вәгъдәләр бар кеби, аягы берлә тыпырчынып китәргә теләгәнене белдертә башлады. Мин дә, утырып чыгып, кояшка каршы шул матур кырлар, урманнар арасыннан, йомшак кына йөгерткән тарантас

селкенүе берлә әллә нинди уйларга чума-чума, әбиләргә киттем. Авылны чыктым, яшел игеннәр эченнән диңгездән ярып бара торган көймә кеби, шул яшеллекне кара атым, кара арбам берлә ярып бара башладым. Кырның хуш исләре, мине каршы алыр өчен хәзерләнгән кеби кошларның оркестрлары, мин үткәндә ике тарафтан да ашлыкларның, баш иеп, миңа сәлам биреп калулары мине тәмам исертте. Мин, үземнең шатлыгыма чыдый алмаенча, үземнең кәефемне нәрсәгә сарыф кылырга белмәвенчә, шул шатлык, матурлык галәмендә йөзә идем. Әллә нинди берсеннән-берсе матур фикерләргә чума идем. Шул фикерләрне, шул фаразларны хакыйкатьтән аермаенча ләззәтләнә идем. Менә тагы ат кешнәп җибәрде. Мин йокыдан уянып киткән кеби булып алдыма, артыма карый башладым. Күктән төшкән кеби, күз алдымда француз күлмәк, француз яулык, ап-ак оекчабатадан бер хатынга җиткәнне, аның мине уздырыр өчен кырыйга басканын күрдем. Минем бөтен әгъзаларым хәрәкәткә килде. Әллә нинди зур бер эш көткән кеби, битләрем кызара, кулларым калтырый башлады. Хатынның тугрысына барып, мең төрле фикерләргә күмелеп, хатынга туп-тугры карый башладым. Хатынның матур төсле таза тәннәре минем күңелемдә тагы әллә нинди фикерләр уятты. Ул да туп-тугры карап, нидәндер көлде. Мин иреннәремне кыймылдатып, әллә ни әйтмәкче булдым. Иренем кыймылдамады, авызымнан сүз чыкмады. Мин башымны аңар каерып карап уза башладым. Күңелемдә: «Утырырга чакырыйм, фәлән итим, төгән итим»,— дигән мен төрле фикерләр йөри башлады. Ләкин берсен дә мәйданга чыгара алмаенча, һаман ерагая башладым. Кыз, минем күңелемдәге бөтен фикерләремне аңлаган кеби, минем шул булдыксызлыгымнан көлгән кеби, шаркылдап көлде. Мин кызардым. Миннән көлүе өчен ачуым килеп, атны сугып чаба башладым. Ләкин тагы башымны борып карарга тотындым. Кыз кесәсеннән яулык алып селки башлады. Мин дә тагы гайрәтләнеп, атны сабырлатып, кызны көтәргә карар бирдем. Ләкин кыз якынылаша башлагач, тагы әллә нинди курку фикерләре берлә, тагы артыма карый-карый, тагы кызның көлүләреннән хурлана-хурлана киттем. Шул очрашу минем күңелемдә кырык төрле фикер уятты. Бердән, шул кыз берлә

сөйләшәсем, уйнашасым килүе бөтен башымны каплады. Шуның берлә бергә үк курку фикере, «кеше күрер, кеше ишетер, яхшы түгел» фикере сугыша башлады. Шуның өстенә карарсызлык һәм дә кызның көлүеннән ачу килү кушылып, минем башымда зур сугыш ачылды. Шул фикерләрнең иң соңында үземне үзем шелтәләү уе, үземнең шундый форсаттан да файдалана белмәү уем куәтләнеп, үземне үзем: «Син нинди егет, син нинди яшь! Син кай вакыт егетлекнең, яшьлекнең ләззәтене күрәчәксең»,— дип шелтәли башладым. Шунларга җавап таба алмаенча: «Икенче тугры килсә, болай калдырмам»,— дип, үземә үзем сүз биреп, үземнең шул начар хәлемнән чыгар өчен кеби, атны куалый башладым.

Менә биек тау өстендә әбиләрнең ялтырап ята торган авылы күренде. Мин, баягы фикердән тизрәк котылыр өчен, тиз-тиз авылга ашыга башладым. Моң гына тора торган җил тегермәннәре, ямьсез уйлар гына уята торган ташлар берлә тулып беткән зияратлар яныннан үтеп, авылга да кердем. Теге фикеремне авылның тышында калдырып, иске генә, моң гына бер йортның капкасын ачтым.

*15 нче июнь, 1895 нче ел*

## 8

— «Вә рөтбәттә» тәртип кылдым мин аны, «галә мөкаддәмәт» бер мөкаддәмә үзәренә, «вә сәлясә мәкаләт» өч мәкалә үзәренә, «вә хатимәт» бер хатимә үзәренә,— дигән, күрше өйдән ишетелә торган әби берлә бер кыз тавышы мине йокымнан уятып җибәрде.

Өй түбәсенең ярыкларыннан гына сузылып-сузылып кергән яктылык, башка бер тәрәзәсе булмаган караңгы чоланда һәм дә мантыйктан бик ерак торган әбиләрнең чоланында «Вә рөтбәттә галә мөкаддәмәт вә сәлясә мәкаләт вә хатимәт»не ишетү, бердән, бер мине әллә нишләтеп җибәрде. Мин, бер яктан, мәдрәсә вә мәдрәсәдәге иптәшләр, дәресләр, сәлясә моназарәләре вә, бердән, шул күрше өйдән ишетелә торган, чыкыр-чыкыр майда пешә торган пәрәмәч тавышы, коймаклар исе арасында калдым. Күңелем дә буйларның

берсе берсене истисна кылганга: «Йә чыкырдап пешә торган коймак хәкыйкать, сөлес мәсьәләсе хыял яисә мин мәдрәсәдә ятам, сөлес — хәкыйкать, бу коймак, пәрәмәч исләре ашыйсы килгәннән булган бер хыял»,— дип төшенә башладым. Ләкин кызу табага яңадан салынган суык майның тагы бик зур куәт берлә чатыр-чотыр итеп китүе вә шуның соңындук яшь кенә бер тавышның сузып кына: «Вә рәтбәттә» тәртип кылдым мин ул китапны, «галә мөкаддәмәт» бер мөкаддәмә үзәренә, «вә сәлясә мәкаләт», «вә сәлясә мәкаләт» дип сөаль тарызында сузып торуыны, әбинең шуның сузган «вә сөлес мәкаләт»енә «өч мәкалә үзәренә» дип җавап бирүене һәм дә: «Нәрсә күзеңне акайтып торасын? Укы!» — дип кычкыруы, аның артыннан «әгузе бисмилла» әйтеп:

- Гайсә иңгәй тәмам төгәл тугыз йөздә,
Дәҗҗалны үтергәйләр белең анда...—

дип сузып көйләве минем әбиләрдә идекемә аз гына шөбһә калдырмады.

Мин тиз генә сикереп торып, киенеп, юынырга чыктым; һәм дә кереп, чәй эчәргә утырган бабай һәм әби янында теге өйдәге сабак кызлары хакында, анларның китаплары хакында сораштым. Әби: «Яңа бер китапка керт дип маһирәсе йөдәтте, шуңарга керттем, бер дә күргән китабым түгел»,—диде. Мин ул китапның «Шәмсия» икәнлегене әйткәч, карт мулла бабай да исе китеп: «Кертеңез әле шул китапны»,—дип, китапны керттерде. Китапның «Шәмсия» булуы бабайның эчене катырды, һәм дә аның берлә минем арамда сөлес хакында бер моназарә ачылды. Бабай минем сүзләремнән разый калды булырга кирәк: «Бу китаплар мәрхүм Габдулланыкы. Ул бик һәйбәт Казан шәкерте иде, үлеп китте. Менә шул аның агасының кызлары, башка кызлардан узар өчен, анларда булмаган китапларны укырга маташалар»,—диде һәм дә анда минем өчен дә яраклы китаплар барлыгын сөйләде. Мин, чәй эчәр-эчмәс, ул үлгән Казан шәкертенең китапларын карар өчен, шул кешеләргә киттем. Кайнап торган самавыр янында ике сумка китапларны актара башладым. Әллә никадәр дәрес китапларына башка, төпләмәгән, таралган төрекчә бер китап таптым. Бөтен сумкага таралган бу китапны җыя башладым. Җыя-җыя аның

«Тарихы госмани» дигән бер китап икәнен белеп, ул тарих-фәләнне бер дә белмәгәнгә һәм дә теле дә бик үк аңлашылмаганга гаҗәпсенеп, башка китаплар берлә шуны да алдым. Алып кайткач ук тарихы ислам кыйсьмене укып чыктым. «Алты бармак» кеби китаплардан тарихы исламны бераз белгәнгә, буны аңлау да авыр булмады; акрын гына тегеләрен дә аңлый башладым.

Менә хәзер кунактан кайтканыма ике атна булды. Тарихны өч мәртәбә укып чыктым. Бу тарих әллә нинди уйлар уятты. Кечкенә бер халыкның зураеп падишаһлык ясавы, ул падишаһлыкның дөньяның иң зур падишаһлыклары арасына керүе, соңыннан аның акрын-акрын гына җимерелүе күз алдымнан кичте. Мин шуның сәбәпләрене эзләдем. Ачык бернәрсә таба алмадым, әтидән сорадым. Ул да: «Соңгы заманада «низам-интизам» дип, шәригать ташлап, аурупалану»,—диде. Бу җавапка мин бохараиларның, «низам-интизам»ны кабул итмәенчә, «шәригать»тән аерылмауларыны, анларның изелүләрен сөйләдем. Әти дә аптырап: «Әләмрү лиллаһи, Алланың бер хикмәте бардыр»,—диде. Булса бардыр, ләкин мин дә шул хикмәтне беләсем килә. Казан беткән, Әстерхан беткән, Кырым беткән, Бохара беткән. Тагы әллә нинди гарәпләр беткән. Истанбул начарланган. Бунлар минем башымда бик күп фикерләр, бик күп кайгылар ачтылар. Ник беткән? Ник бетә? сөальләре башымны ваттылар. Мин бик күп уйладым, бик күп уйлыйм...

*26 нчы июнь, 1895 нче ел*

## 9

Тарихтагы Әңдәлес гарәпләре хакындагысын әти берлә бергә укыдык. Әндәлеснең кайда икәнлегене белә алмаганга, тегеннән алып кайткан кечкенә «Асәре Сәлим Габит» дигән җәгърафия хариталарыннан эзләп таптык. Әтинең дә бунын хакында мәгълүматы юк икән. Анларда гыйлемнең бик алга китүенә, шулай булса да, әллә нигә бетүләренә мин тагы гаҗәпкә калдым. Чыннан да, ник бу ислам халыкларының башына һәммә йирдә бәла туган? Бунлар һәммәсе дә миндә әллә нинди, шул киткән мәмләкәтләр өчен матәм кайгысы уятты.

Мин, шунларны укыган саен, үз йортым йимерелгән кеби кайгырдым, хәсрәтләндем.

Кичә бер иптәштән хат алдым. Җәйне кызык үткәрү хакында, күрше кызлары берлә шури-мурилар ясавы хакында язган. Миңдә дә шул фикерләрне уятты. Хат язарга карар бирдем. Язам. Быел да җәй үтеп китә. Үткән гомер кайтмый! Яшьлек бер килә. Язам, язам!

*30 нчы июнь, 1895 нче ел*

## 10

Күңел әллә ни тели, эч поша. Кәеф юк, төрлелек юк. Көннәр бары да берсенә берсе охшап үтеп бара. Күңелсез, мәгънәсез! Әллә ни эшлисе килә, әллә ни тудырасы килә. Берни дә эшләп булмый. Иртәдән кичкә кадәр йортта йөреп, ындырга барып вакыт уздырдым. Үземнең язмышымнан үзем разый түгел.

*1 нче июль, 1895 нче ел*

## 11

Тагы төрлелек: авылга ишан килде. Без тагы ишан берлә кунакка йөримез. Мужиклар бик иелеп ишанның кулыны үбәләр, аннан фатиха үтенәләр. Ишан да, чыннан бер зур эш эшләгән кеше кеби, бик зур иттереп кулыны күтәреп, озын иттереп дога кыла. Ишан һәрвакыт итәгенә карап утырганга, мужиклар аны: «Алла берлә юллаша»,—диләр. Мәҗлеестә чыккан сүзләрне һәммәсене дә ишаннан хәл кылдырмакчы булып: «Хәзрәт ни әйтер әле!» — дип куялар. Ләкин хәзрәт һаман астка караган көенчә дәшми-тынмый тора.

Кич берлә ишанга мөрид булыр өчен өем-өем хатыннар җыелалар. Анлар кайсы сөлге, кайсы ашъяулык, кайсы әбисеннән калган бөтен тәңкә, кайсы җәмәгатеннән урлаган акчаны күтәреп килеп, ишанны шул әйберләр берлә күмәләр. Өшкертүченең исәбе-хисабы юк. Пәри сукканнан, каршы орынганнан, сихердән, күз тиюдән, зыяндаштан, бизгәктән, бабасырдан, баш авыруыннан, күз авыруыннан, йөрәк авыруыннан, катудан, чәнчүдән,

очкылык тотудан, тел бәйләнүдән, белмим, тагы нинди чирләрдән өшкертәләр. Ястүдән соң яшеренеп кенә картлар, карчыклар кызларының яхшы тормавыннан, киленнәренең угылларыны кулларына алудан зарланырга, угыллары солдатка китмәсен, солдаттагысы исәнлектә-саулыкта кайтсын дип нәзерләр китерәләр. Бала таба алмый торган хатыннар, балалары булмый торган ирләр бала табу дарулары сорарга, балалары үлә торганнар балаларын үтерми торган догалыклар алырга, ире сөйми торганнар сөйдергечләр алырга, байыйсы килгәннәр байлык догалары, байлык бөтиләре алырга киләләр. Бунлар барысы да җанлы-җансыз хайваннар, анларның тиреләрене, айларның йоннарыны, тулаларыны, анлардан булган акчаларыны китерәләр. Алладан булган теләкләренә ишан хәзрәткә пошлиналар түлиләр. Ишан мәсҗедтә мужиклар берлә зикер укый. Бик озак итәгенә карап торганның соңында, пошкырырга тотына. Мужиклар аның пошкыруыннан бик зур «мәне» (мәгънә)ләр чыгаралар. Ишан да шул пошкырулардан шактый күп акча чыгара. Безнең әти ишанны яратмаса да, аңар мөрид булу-фәлән кеби ваклыкларга риза булмаса да, анын шунда, мәсҗедтә пошкыруларына каршы тормый. Ишан килгәндә шактый файда булгангадыр, ахрысы, ишан тугрысында ләм-мим дип сүз сөйләми.

Мин ишанның шактый кәефен җибәрдем. Ул: «Бохараи шәриф...» — дип сөйләргә тотынган иде, мин: «Шәриф инде!» — дип, Бохараның начарлыкларыны саный башладым. Икенче көнне: «Аксак Тимер хәзрәтләре әүлия булган»,— дип тотынган иде, теге төрек тарихыннан аның мөселманга никадәр зарар иткәнлегене сөйләп, тагы каршы төштем. Әти мин сөйләгәндә көлеп кенә торды. Ишан бер җавап кайтармый тагы башыны бөкте. Мин, шул халыкның ишанны әллә кем дип йөрүеннәнме, әллә ишанның, һәрнәрсәне беләм дигән булып, халыкның барын-югын җыюыннанмы, аңар дошманлык били башладым. Ишан килүдән кесә файда итсә дә, күңел файда итмәде, тагы элгәреге кеби бушлык биләде. Тагы күңел төрлелек сорый башлады.

*3 нче июль, 1895 нче ел*

## 12

Кем бу хатыннар? Шәйтанмы? Фәрештәме? Кеше түгел, улсыны беләм. Ләкин шәйтанмы, фәрештәмелеген аера алмыйм. Минем бөтен күңелем шунларны күрәсе, шунларның эченә керәсе, шунлар берлә рәхәтләнәсе, шунлар берлә сөйләшәсе, уйнашасы килә. Шунлар мине әллә нинди куәт берлә үзләренә таба өстериләр. Ләкин шунлар янына килгәч, шунлар берлә әллә кайчаннан бирле уйлап йөргән уйларны мәйданга чыгарырга вакыт җиткәч, миндә шунларга әллә нинди дошманлык, анларның матурлыкларына, анларнын сөйли белүләренә, үзләрене тота белүләренә каршы көнләү хисе уяна. Минем күңелем анларның шул сабырлыклары, анларның шул салкынканлылыклары, үзләрен тота белүләренә протест ясый. Анларны шул салкынканлылыктан чыгарасым, анларның кызган күңелләрене, кайнаган бәгырьләрене япкан шул пәрдәләрене ертасым килә. Мин анларны хайван кеби уасым, изәсем килә. Миндә әллә нинди ерткыч хисләр уяна. Шунларны мәйданга чыгарырга карар бирүем берлә, анларның йомшак сүзләре, матур көлүләре, йөзләренең ай кеби ялтыраулары, эчләрендәге хиссиятне саклаудан яңакларының ахак кеби янулары, мин сөйләргә сүз таба алмый торганда анларнын йөрәкләренең леп-леп тибү тавышлары мине изәләр, эретәләр, мине әллә нинди көчсез бер чүпрәккә әверәләр. Мин тагы, бер яктан, шунларны әллә нинди олуг нәрсә иттереп, анларга баш ию, анлар ни кушса, ни теләсә шуны булдыру, бер яктан, үземне шулкадәр изүләре өчен, үз-үземне югалттырулары, оныттырулары өчен анларны әллә нинди дошман күрү, шунларны бетерү хисләре арасында кысылам, уалам. Тагы бер якка да хәрәкәт итә алмаенча, аягы-кулы бәйләнгән батыр кеби, үземә, үземнең шулай булуыма сәбәп булучы кызларга, ниһаять, дәрәҗә ачуым килә. Ачуым эчемә сыймый, колакларымны кыздырып, битләремнән яндырып тышка чыга. Аннан тагы тәнемә, җаныма тәэсир кылып, мине тагы эчемнән вә тышымнан яндыра. Мин шул ике ут, ике хис арасында янам. пешәм

Менә бүген дә шулай булды. Иртүк торып үземезнең кечкенә өйгә чыктым. Әниләр, этиләр йокласа да бу арада бездә куна торган түбән оч кызы Фатыйма кечкенә өйдә күптән торып, чебешләр-фәләннәр ашатып бетереп, тегүенә ябышкан иде. Мин әүвәл керүемдә аны күргәч тә аптырап китеп, юыныр өчен комган гына алып чыктым. Юынган вакытта әллә никадәр уйлар корып, шуның янына кереп сөйләшергә, уйнашырга шуның берлә дустлашырга карар бирдем. Акыртын гына кердем. Ул миннән яшь хисабыннан зур булганга миннән качмый, миндә андый-бундый уй барлыгын да белми торгандыр. Үземне үзем көчләп кенә аның янына барып утырдым. Аның бик гади: «Ник бик иртә тордың?» — дигән сүзенә әллә нинди мәгънәле җаваплар бирергә теләсәм дә, тавышларым калтырый, иреннәрем кыймылдый, битләрем ут кеби яна башлады. Мин калтыраган тавыш берлә әллә нәрсәләр мыкырдадым. Ул, минем нинди халәттә идекемне белүдән булырга кирәк, көлде дә: «Кандала ашадымыни?» — диде. Мин тагы ни җавап бирергә аптырап калдым. Теккән вакытта энә чәнчеп җеп тартудан килгән бөтен тәненең хәрәкәтләренә сәер итә башладым. Ул тагы көлде дә, миңа карап: «Әллә авырыймсың?» — диде. Мин тагы бу сөальгә: «Сине сөям фәлән»,— дигән кеби сүзләр әйтергә уйласам да, үземнән «юк» дигән сүзгә башка нәрсә чыкмады. Минем болай торуым бик мәгънәсез булганга, акыртын гына кызның янына шуып-шуып килеп кулымны муенына салмакчы булдым. Әллә ничә күтәреп, әллә ничә төшергәннән соң, кулымны акыртын гына муенына куйдым. Кыз бер сүз дәшмәенчә, минем тарафымнан башка хәрәкәтләрне көткән кеби, миңа карамаеңча тегүеңдә дәвам итте. Минем йөрәгемнең лепелдәве бөтен өйгә ишетелә башлады. Кыз мине бераз батырайтыр өченме, бик күп мәгънә аңлатырлык бер караш берлә миңа карады. Мин бу караршта әллә никадәр дәрт аңласам да, буннан соң да кулымны селкетеп яңа бер хәрәкәт ясый алмадым. Кызның муенындагы минем кулым җансыз кеби хәрәкәтсез калды. Кыз, табигый уларак, минем бу ярым-ярты хәрәкәтемнән риза булмадыгыннан, үз тарафыннан миңа таба бер-бер эш эшләргә үзен җиңә алмаудан булырга кирәк, тагы бераз шулай торгач, тагы минем күземә: «Һаман шулай торасыңмы, йә әле, мәми авыз»,—дип

караганның соңында: «Алай ярамый...»—диде. Миннән тагы бер-бер хәрәкәт көткән кеби, тик калды. Мин тагы бер эш эшли алмадым. Ул: «Ал кулыңны»,—диде. Мин кулымны алдым. Үзем кып-кызыл булып, үземне үзем сүгә башладым. Кыз тагы тегәргә тотынып, мине юк кеби иттереп эшенә дәвам итте. Бераздан соң күзенең очы белән генә карап, миндә артык куәт юклыгын хис кылып булырга кирәк: «Бар, чык, кешеләр керә башлар»,— диде. Мин, никадәр чыгасым килмәсә дә, никадәр шул кызны кочаклыйсым, үбәсем килсә дә, торып чыгып киттем. Бакчада утырып бик озак үземне үзем сүктем. Авызга чәйнәп салган ашны ашый алмавыма, үземне үзем тота алмавыма хәйранга калдым. «Буннан соң икенче кат тугры килсә, болай ясамам»,— дип, бик нык үземә суз бирдем. Йитәр, әле дә бик күп форсат югалттым!..

*5 нче июль, 1895 нче ел*

## 13

Кичә шәһәрдән бер әллә нинди китап алып кайттым. Теле минем тарих теле берлә язылган булса да, тырышып укый торгач, аңладым.

Китапта бер Ташкентлы мулла Габбас дигән кешенең кырык газизләр зиярәтен эзләп йөреп, Испаниягә барып чыгып, минем теге Әңдәлес тарихында укыган гарәпләрнең калдыкларыннан гизле бер атауда яшәүче мөселман гарәпләргә барып очравын һәм дә анларның хәзерге тормышларының ничек икәнлеген тасвир иткән. Бу китап дөрест булса, чынында шундый йир булса, ул оҗмах инде. Анда фәкыйрь юк, ач-ялангач, теләнчелек иткән зәгыйфь юк, актык сулышында авызына су салырга кешесе булмаган авыру юк, золым юк, җәбер юк, һәр йирдә тигезлек, һәр йирдә гадәләт. Тормышлары шулкадәр уңайланган, анда безнең кеби начар атлар берлә йөрүне, дөяләр, үгезләр берлә шәһәрдән шәһәргә килүне әллә кайчан оныткannar. Анларның бөтен шәһәрләре, авыллары арасында күз ачып күз йомганча күз күргән йиргә йитә торган пыраклар кеби электрик вагоннары йөри. Анда бездәге кеби мелт-мелт итеп, ярлы кешене сүнәм-сүнәм дип куркытып тора торган табагач лампалар урынна һәр өйдә, һәр бүлмәдә әллә

нинди матур, пөхтә электрик лампалар төнне кичтән аермаслык иттереп яктырталар. Анда, бездәге кеби ирләр теләсәләр, йомычканы йомыш итеп, хатыннарын кыйнау, кечкенә генә эшләрне сәбәп итеп, анларны аеру урынына хатыннар үзләре үзләрен идарә кылалар үз эшләре өчен үзләреннән хатыннар сайлап, үзләренең низагъларын үзләре күрәләр.

Анда, бездәге кеби, муллалар бот күтәреп, һәрнәрсәне инкяр кылып: «Шәригатькә сыймый!» — дип тормыйлар. Анларның мәдрәсәләре, бездәге кеби, чүплек башында чүплек оясы кеби булмаенча, безнең падишаһларымызның сарайлары кеби зиннәтле, пөхтә, зур эшләтелгәннәр. Анларның падишаһлары, төрекнеке кеби, йөзәр, меңәр җарияләр берлә чормалып-чуалып ятмаенча, гади кеше кеби эш итә, гади кеше кеби мәмләкәтенә хезмәт итә. Хасыйле, андагы эшләр һәммәсе мондагының киресе. Чын, бездә дә шулай булса, нинди кызык булыр иде. Һәммә кеше рәхәтләнеп яшәр иде, һәммә кеше әллә нинди кирәкмәгән тамак кайгылары берлә йөдәмәс иде. Бар да эшләр иде, бар да ашар иде.

Ник бездә шулай булмаган? Әнә ул гарәпләрдә шулай булган, ник бездә булмаган? Без дә мөселман ич! Ник анларда уку ул кадәр алга киткән дә, бездә наданлык шулкадәр падишаһлык сөргән? Ник бездә шулкадәр золым-җәбер җәелгән дә, анларда ул беткән?

Ник бездә бөтен урамнар хәерче, карак берлә тулган да, анларда ул беткән?

Ник бездә хатыннар җарияләр кеби калган д. анларда падишаһлар булганнар? Буның сәбәбе ни?..

Тәкъдирдер шул!

Ник бездә Ходай шулай тәкъдир иткән? Анларда тегеләй?

Әй! Безгә дә Ходай аларныкыча тәкъдир иткән булган.

*7 нче июль, 1895 нче ел*

## 14

Бүген карабогдайларны карарга дип, кырга чыккан идем. Ни күзем берлә күрим: түбә өстендә, бер борай йире кырыенда, шәйтан таягына ил сарган.

Мин, әллә ни тапкан кеби, йөгерә-йөгерә өйгә кайтып әнигә сөйләдем. Әни, бер кешегә дә сөйләмә дип, бик тиз корт тубалыны, битлегене миңа бирде дә, кечкенә генә шәл ябынып, кеше күрми торган җирдән су буйлап кына киттек. Судан кайта торган хатыннар минем тубалымны күреп: «Абыстай, әллә ил таптыңызмы?» — дип әйтергә теләсәләр дә, әни: «Юк, Миңлекол абзыйларга тубал төзәтергә генә илтәмез, умартамыз уйнаткалап тора»,—дип җавап бирә дә кызу-кызу китә иде. Хатыннар әнинең сүзенә ышанмыйчарак аптырап калдылар. Менә без авылдан чыгып та киттек. Мин эчемнән: «Таба алырмын микән? Урынны онытмадым микән? Ил үлмәде микән?» — фикерләре белән мәшгуль булсам да, канатлы кош кеби очам гына.

Менә түбә өстенә менеп йитә башладык. Мин алтын тау тапкан кеби, тиремә сыймый барам. Әни дә, минем арттан калмаска тырышса да, арыды, мине еш-еш: «Кызуланма! Кызуланма!» — дип туктата башлады. Менә барып җиттек. Менә теге борай, әнә теге ягы солы, аның күршесе — карабогдай. Әнә шәйтан таягы һаман сыгылып тора, ә, китмәгән икән. Менә мин хәзер барып та йиттем. Әнине көтеп торам. Әни илне күргәч, аның зурлыгына исе китеп, тирә-ягына «бисмилла» әйтеп, «күз тимәсен» дип төкерде. Үзенең битләреннән кызыл тир чыкканга, акыртын гына утырып хәл җыярга тотынды. Мин шул вакыт тубалларны хәзерләдем. Ул битлек киеп, кулларына бияләйләр киеп, җыярга хәзерләнде. Минем өчен битлек булмаганга, казакием берлә томаланып кына әнигә ярдәм итә башладым. Менә әни, «бисмилла» әйтеп, әүвәлге чүмечне алып состы. Кортлар бердән кузгалып китеп уылдый башладылар. Ул тагы берне салды, тегеләрнең уылдаулары тагы куәтләнде. Шәйтан таягында калганнары казан кеби кайнарга башладылар. Тубалга кергәннәре тагы кырык төсле музыка уйный башладылар. Чүмечтән очып киткәннәре әнинең башы, минем башым тугрысында әйләнеп-әйләнеп җырларга тотындылар. Шул арада берсе быж иттереп килеп, минем борынмның очына утырды. Мин төшерергә өлгерә алмадым. Борынма бик очлы, бик ачы утын тыкты. Мин кинәттән сикереп китеп кортларны куркыттым. Анлар тагы тавышлырак җырлый, тагы безнең башлар өстендә

күбрәк әйләнә башладылар. Әни кызу-кызу тубалга сала башлады. Әни салган саен, тубалда гөрләү куәтләнә башлады. Шәйтан таягыннан корт шактый кимеде. Аның сыгылып яткан бер ботагы бераз башын да күтәрде. Кортлар үзләреннән үзләре дә, күпердән чыга торган хайван кеби, тубалга таба керә башладылар. Әни: «Анасы керде, хәзер бетерәмез!» — дияргә өлгерә алмады, әллә кайдан арба тавышы ишетелә башлады. Һәм дә бик тиз безнең тугрыга килеп җитеп: «Ил тапканнар, ил тапканнар! Уртак!»—дигән тавышлар ишетелә башлады. Мин ул тарафка әйләнеп карап, ямь-яшел чапкан печән өстенә ат тотып утырган бер ир, ак эшләпәләр, кызыл күлмәкләр киеп утырган ике хатынны күрергә өлгерә алмадым, анлар бары да бердән атларыннан сикереп төшеп «Уртак!» дип йөгереп килә башладылар һәм дә әни янына килеп, җыю мөштәрәк булып, биләү дә мөштәрәк булсын өчен, куллары берлә берәр корт салган төсле кылана башладылар. Ирләре, салыйм дигәндә маңлаены бер корт чагудан кулы берлә нишләгәнен белмәенчә тубалның эченә бөтен кулын тыкты. Кортлар бердән дулый башладылар. Бер минутта әнинең бөтен башы-өсте корт белән тулды. Бик зур тавыш күтәрелде. Теге мужик вә хатыннар кулларыны селки-селки кортлардан кача башладылар. Әни тубалны ябарга өлгерә алмады бөтен корт чыгып бетте. Анлар югарыда тагы әйләнеп-әйләнеп җырларга тотындылар һәм бер-ике әйләнгәннән соң урманга таба ага башладылар. Теге мужиклар, үзләренең ни кылганлыкларын хәзер белсәләр дә, калган-поскан кортлар анларны куып-куып йөгертеп чакканга, анлар акырып-бакырып йөрергә тотындылар. Атлары элгәрерәк тик торса да, берничә корт барып чаккач та ул да сикерә-сикерә чабып, арба артын чыгарып юл буйлап авылга таба китте. Мин, алтын тау югалткан кеше кеби, ил артынан бераз чапсам да, күземнән югалгач әни янына кайттым. Әнинең битләре, маңлае тирләп-пешеп беткән, куллары да корт угы берлә шешенеп беткән иде. Йөзенә дә әллә никадәр ачу килү төсе чыккан иде. Теге мужиклар, хатыннар һәммәсе дә безгә күренмәс өчен арбаларыны калдырып, ашлыклар арасыннан киткәннәр иде. Без әни берлә бераз карашып торганнан соң, әни: «Каһәр сукканнар! Нинди зур илне әрәм иттеләр!»- диде дә, торып кайта башлады

Миңа бу юлы буш тубал, буш битлекне күтәреп кайту, бердән, авыр, икенчедән оят төсле тоелды. Кеше күрсә: «Илеңез кая?» дияр кеби булды. Курка-курка яшеренә-яшеренә генә, буш тубалны күтәреп өйгә кайттык.

*9 нчы июль, 1895 нче ел*

## 15

Тагы эш йитә, тагы җәй үтә. Мин тагы җәйдән бер файда итә алмаенча калдым. Кичләрен, иртәләрен бөтен авыл чалгы кайрау тавышы берлә яңгырый. Чалгылар хәзерләнәләр. Кызлар кызу-кызу киндерләрен агартып бетереп, тукмаклап сандыкларга җыеп, янмый торган балчык келәтләргә кертеп куярга ашыгалар. Яшь киленнәр, кызлар, урак, печән өчен яңа эшләпәләр бастыралар, искеләрен буяталар. Аркаларына тагар өчен сач такмаларыны яңадан тезәләр, кулларга җиңсәләр тегәләр. Хәзерләнәләр, елыңда бер килә торган зур эш бәйрәменә хәзерләнәләр.

Озак үтмәй печәнгә төшәрләр. Аның артыннан уракка, аның артыннан орлык йитәр; аның артыннан тагы урак. Авыл халкы тәмам кыр кешесе булып китеп, өйләренә ашарга-эчәргә генә кайтырлар. Авылларда бөкре картлар, чебеш ашатырга калган карчыклар, өй сакларга калган балаларга башка безнең кеби эшсез халык кына калыр. Ул вакытта эшләргә теләсәң дә бер эш эшли алмассың. Шуның өчен, бу елны ичмасам әрәм итмәс өчен, мәдрәсәгә баргач башка шәкертләр арасында сөйләргә минем дә сүзем булсын өчен, кызларга хат язарга кирәк. Кичә бик озак кемгә язарганы уйладым. Күрше кызы Сәгыйдә бик матур булмаса да, анда кереп-чыгып йөрү уңай булганга, аңар язмакчы булдым. Ләкин ул язу таныймы, анысын белмим. Ни дип языйм? Мужик егетләренке төсле иттереп, читләрен чуарлап, бәетләр язарга миңа килешми. Шәкертчәрәк иттереп, гарәпчә кушып язсаң, аңламас. Үземнән бертөрле иттереп языйм ахрысы. «Җаным, Сәгыйдә... мин сине сөям...» Инде нәрсә язарга?.. «Кавышыйк, җаным...» Тагы нәрсә? «Гыйшык тоту Йосыф, Зөләйхадан калган». Бу килешеп бетми. Йә тагы нәрсә?.. «Мине яндырма!..»

Шул гынамы? Укып карадым, бердән бик аз була, икенчедән бер дә аңлашылмый. Бу ярамый, зуррак кәгазьгә һәйбәтләп язарга кирәк. «Алтын бармагым, көмеш тырнагым»,— дип язсаң, тагы матур төсле күренми. «Сезгә газизелвөҗүд вә кәсирелсөҗүд» дип башласаң, этигә, әнигә язган хат төсле була. Юк, берсе дә ярамый, яңадан язам. «Җаным Сәгыйдә, сиңа бик чук-чук сәлам бәгъдендә сүзем шулдыр...» Инде нәрсә языйм? «Сине сөям...» Тагы?.. Сөю берлә эш бетми бит, миңа тегесе кирәк! «Кавышыйк, җаным Сәгыйдә, син кая ятасың?» Бусы килешмәс! Минем ни эшем бар кая ятуында? Шулай бетерим ахрысы. Үзе дә белә инде. «Сине сөйгүче...» Укып чыккач, бу хатны да яратмадым. Ни булса булсын, мәкъсуд — хат язу бит. Шуны җибәрәм. Ләкин ничек җибәрәм? Бербер бала аркылы җибәрергә, баласы юк. Тагы ул балага ышанырга ярыймы? Карчыклар аша җибәрергә, ул карчыкны кайдан табасың? Үзем бирергә кирәк. Таптым, мәчеләренең муенына бәйләп җибәрергә кирәк. Ләкин аны әллә кем алса, ул вакыт нишләрсең! Юк, әүвәл йортларына чыкканны саклап торырга кирәк тә ташка төреп ыргытырга кирәк. Хәзер печәнлектән аның чыкканын саклап торырга киттем.

*10 нчы июль, 1895 нче ел*

## 16

Өч көн бербуйдан саклап торып туеп беттем. Һич тугры китерә алмадым. Яисә чыкмый иде, яисә чыкса да, кеше берлә була иде. Менә бүген тегүен алып безнең печәнлеккә каршы ышыкка чыгып утырды. Мин әллә кайчаннан бирле карап торам. Мин аның шул тулы битләрене, шул кызыл авызыны үбәрменмени? Аның шул йомшак куллары берлә кочаклатырмынмыни? Ыргытам... Ләкин ул хатны алмаса... нишләрмен? Яки әнигә бирсә! Ай элгәре үзе язса шәп булыр иде соң! Тукта әле, читәнне азрак шытырдатыйм. Ишетми... тагы... Кара... ишетте... күзе берлә эзли... Ташлыйммы? Юк, куркынч! Ул, шул, читән шытырдагач үзе килсә иде. Юк, килми! Тукта, тагы бер шытырдатыйм әле... һаман эзли... үзе килми! Ыргытыйм, хәзер кеше юк. Күңел курка!.. Кул бармый!.. Йөрәк леп-леп сикерә!.. Ыргытыйммы?.. Юк,

булмый... Ник булмасын... Ул кыз түгелмени?.. Аның егетләр белән йөрисе килмимени?.. Килә, килә!.. Алай булса, ник үзе мина хат язмый?.. Йә, ярар... Фәлсәфә сатар вакыт түгел, ыргытам. Уф... Тагы кулым үземнең әмеремне тутырмады. Тагы ыргыта алмадым! Менә инде Сәгыйдәнең әнисе дә чыкты! Инде ни була? Әнә Сәгыйдә әнисе белән көлеп сөйләшә. Миннән көлә торгандыр!.. Миннәндер!.. Иә, менә, әнигә әйтерләр!.. Китим тизрәк!..

*14 нче июль, 1895 нче ел*

## 17

Йокыдан иртә тору сәбәпле йир күрсәтергә барганда мин башымны җыя алмасам да, кайтырга чыкканда кәеф тәмам ачылып беткән иде. Йирнең кырыеннан чыгып килә торган зур кызыл кояшның, шул чык юешлегеннән котылыр өчен кеби, тырышып-тырмашып өсткә чыга баруын карый-карый, атны авылга таба борып кайта башладым. Кырга уракчылар килеп беткәнгә юл буп-буш булса да, бөтен җир тулы халык иде. Бөтен юл буенча озын арканнар берлә бәйләнгән атлар, киләсе көннең эсселегенә кадәр тамакны туйдырып калыйк дигән кеби, шатыр-шотыр ашыйлар иде. Арбалар янындагы көлтәләрдән ясаган куышларда лагун-лагун сулар, тырыс-тырыс катыклар, зур-зур икмәкләр уракчыларның сусауларын кайтарыр, тамакларын туйдырыр өчен хәзерләнгән иде. Өчаякларда кечкенә генә балалар, киләчәктәге елларда шул аталары, аналары, агалары кеби күш-күш урак урыр өчен мыш-мыш йоклап хәзерләнәләр, шул саф һавада әллә ничә төрле саф чәчәкләр исен иснәп, киләчәк хезмәтләргә көч җыялар иде. Йирләрнең эчләрендә хатын-кызлар, ирләр, егетләр алын-алын алып игеннең уңганлыгына шатлана-шатлана кеби иштереп-иштереп уралар иде. Егетләрнең калын беләкләрене тамат ябыштырган ак җиңсәләр, кулларында үткен ураклар оста сугышчының кулындагы кылыч кеби тиз-тиз селкенеп, күз ачып күз йомганчы артларында зур-зур көлтәләр калдыралар, атлаган саен шул иген гаскәрене җиңә-җиңә алга таба баралар иде.

Кызларның, хатыннарның алъяпма бавы берлә нечкәләнгән билләре өстеннән язгы ак су кеби агып төшкән озын сачтакмалары, анларның ике кырыеннан озын-озын итеп, шуның кара ярлары-якалары кеби томырап-караланып, елан кеби түгәрәкләнеп сузылып яткан сач толымнары, анларның кулларындагы нечкә үткен уракның селкенүе берлә селкенеп, кояшка каршы елтыр-елтыр уйныйлар, аңарга каршы шул куе, озын, тулы башаклы арышларны үстергән өчен үзләренең рәхмәтләрене йибәрәләр, аңарга башларын иеп-иеп дустлык сәламе сөйлиләр иде. Һәр кешенең кулында чаж-чож итә торган ураклар да үзләренең елтыраулары берлә бу тәңкәләрнең рәхмәтләренә, тәбрикләренә катнашалар иде. Кыр тургайлары, кырдагы әллә ничә йөз төрле кошлар, кортлар, күбәләкләр дә кешеләрнең фикерләрене бүлешәләр, анлар да шул игенне уңдырган кояшка үзләренең шатлыкларын, сөенүләрен мең төрле авызларыннан мең төрле аваз чыгарып сайрыйлар, шул кояшның олуглык җырын җырлыйлар иде. Бөтен кыр эшли иде. Бөтен кыр шул эшнең барлыгына шатлана, шул эшнең бәйрәмене итә иде. Кай тарафына карасаң да, шул сачтакмалар, ураклар ялтыравы берлә кошлар сайравы күреләэ, кай тарафына баксаң да, бөтен кешеләрнең эшкә чумганлыклары, шул эшнең күплегеннән шатлана-шатлана эшләүләре, шул эшнең бәйрәменә тагы эш берлә бәйрәм итешкәннәре хис ителә иде. Бу эш диңгезендә, эшчеләр тулкын арасында, атымны акыртын гына атлатып бара торган эшсез мин дә, шул эшчеләрнең бәйрәмендә үземнең эшсезлегемне белеп, үземнең шуннарның матур эш бәйрәмнәрендә йөрергә хакым юклыгын уйлап, мине сизмәсеннәр дигән кеби, урланып кына, акыртын гына китсәм дә, күңелемнән һаман үземне үзем гаепли идем. Үземне үзем әрәмтамак дип исемли идем. Шулкадәр күп эш бар вакытта, шулкадәр эшнең кадере зур вакытта үземнең эшләмәвемне хаклы ясар өчен бөтен башымнан әллә никадәр дәлилләр эзләсәм дә, таба алмыйм, шул уйларда тирәнләнгән саен үземне үзем шелтәли бара идем.

Һәммә халык эш эшләгәндә, һәммә халык табигатьнең биргән байлыкларын күбәйтергә тырышканда, һәммә халык бөтен бәни бәшәрнең киләчәге өчен

икмәк хәзерләгәндә ничек бер эш эшләми торырга кирәк? Ничек шул хезмәткә катышмаенча шул хезмәтнең җимешләреннән файдаланырга кирәк?

Колагыма ишетелгән бала тавышы мине фикеремнән чөерде. Мин тавыш тарафына карый башладым. Бер баланың әнисенең эре куллары өстендә сыгылып-сыгылып, суырып-суырып имчәк имүен, анасының да шул баласының имчәк имүенә карап ләззәтләнүен күреп, мин дә шатландым.

Им, бала, им! Имдекең сөтләр хәләль! Им, бала, им! Имдекең сөтләрне түләргә уйлап, имдекең сөтләрдән булган куәтне шул киң кырларда, шул бетмәс-төкәнмәс эшләргә тотарга уйлап им! Им, бала, им! Анаң кеби таза, нык, матур, эш сөя торган кызлар, атаң кеби эштән арымый, байлык ясый, байлык җыя торган угыллар тугдырыр өчен, айларны үстерер өчен, анлар берлә шул киң кырларда, шул эш диңгезендә колачлап-колачлап йөзәр өчен им!

Им, бала, им! Шул кырларны гөл бакчаларына әверер өчен, шул кырларны алтын таулар ясар өчен, белем өйрәнергә, зиһен ачарга көч ясар өчен им!
Имез, ана, имез! Эш арасында туган, эш арасында үскән, эш өчен яратылган балаңны имез!

Имез, ана, имез! Балаңның әрәмтамак булмаенча, эшче булачагына ышанып, аның эшләячәк куллары, эшкә йөриячәк аяклары, эшне уйлаячак башлары үссен өчен имез!

Имез, ана, имез! Син, үзеңнең имчәгеңнән аккан хәләль сөтләрең берлә эш эшләп тамак туйдырачак, эш эшләп әллә никадәр әрәмтамакларның корсакларын туйдырачак балаңны имез! Шул баланың әрәмтамак булмавына шатлана-шатлана, бәйрәм ясый-ясый имез! Имез, ана, имез! Шул матур көннәрдә, шул иген диңгезендә, шул мең төрле кошлар, кортлар шатлана-шатлана сайраганда син дә, эшче ана, балаңны сөя-сөя имез! Син дә, ана, шул матурлыкка аналык мәхәббәтен дә кушып, шул бәйрәмнең тулмаган җирен тутыр.

Яшә, эшче ана! Яше, эшче бала! Бөтен дөньяның кыйммәте, бөтен дөньяның сәгадәте синең эшлекле кулында икәнлеген бел дә, яшә! Яшә!

*21 нче июль, 1895 нче ел*

# 18

Урак бетте. Халык бер яктан бик кызу-кызу көлтә ташый, икенче яктан орлык суга. Җәй көне бушсызлыктан моңаеп тора торган ындырлар хәзер җанланды. Кара токлар янына өем-өем кечкенә чүмәләләр өелә, ындырның кырыйларына бик матур иттереп очлаңдырып бетерелгән кибәннәр куела башлады. Хатыннар, кызлар ындырга кайттылар. Анлар кояшта пешкән, кызарган битләреннән тирләр агызып, уҗым өчен орлыклар суга башладылар. Зуррак ындырларда дөбт-дөбт итеп көйләтеп алты берлә сукканның тавышы бөтен ындырдагыларга музыка кеби тәэсир итә башлады. Авылның бөтен тормышы, кайгысы, шатлыгы, өмете ындырга күчте. Шундагы чүмәләләрдә, шундагы кибәннәрдә, шундагы сары ука кеби сузылып яткан салам өемнәрендә, шундагы кап-кара ындыр табагының уртасында өелгән кибәкләрендә (борыкларында) буйларның меңәр-меңәр өметләре саклана, буйларның менәр төрле планнары яшеренә башлады. Бу ел кызлар шул озын-озын, авыр-авыр эшләр бетеп, бөтен эш кырдан кереп, көзге моңлы-ягьмурлы озын төнле көннәрдә, үзләренең хәләль хезмәтләреннән булган ашлыклардан, көзге вак ягъмурның йоклатасы килә торган тавыш берлә акыртын гына салам башлы келәткә явып торган вакытында, үзләре сөйгән, үзләре кеби эштә ныгыган кияүләре берлә ашап-сыйланып, айларның кочакларында ятасыларын уйлыйлар иде. Егетләр, эшләр беткәч, казлар йолкыр вакытлар йиткәч, Алла кушып, солдаттан да котылып кайткач, шул ашлыкларны сатканнан алган акчага бикәчләренә күлмәкләр, читек-кәвешләр, балдызларына сабыннар, иннекләр, каен энеләренә пәкеләр, кәнфитләр алып кайтып, мылтыклар атып, скрипкәләр уйнатып кияү булып кыз катына керергә уйлыйлар иде. Йорт хуҗалары, эшләр бетеп, ашлыклар сугылып келәткә кереп, кызу-кызу җыела торган казна бирелеп беткәч, шәһәргә барып яңа сабан алырга, кара атка яңа сбруй алырга, угылны, кызны өйләндерсәк-нитсәк кирәк булыр дип, тимер ход алырга уйлыйлар иде.

Киленнәр, эшләр беткәч, тавыклар йомырка салудан туктагач, бәрәңгеләр алынып беткәч, казлар, үрдәкләр су буеннан җыелып алынгач, курыккан кеби генә җылыта торган көзге җылы кояшлы көннәрдә яшел уҗым араларыннан үтә торган юллардан, кашка алашаны җигеп, арбага кызыл ястыкны салып, күчтәнәчкә төче, ачы күмәчләр пешереп, сандык төпләреннән алган, бикәч вакытта китерелгән читекләрне киеп, ире берлә әниләренә кунакка барырга, аңда өч-дүрт көн кунак булып һәр иртәне мунча кереп, карендәш-кабилә, дуст-ишкә ашка барып йөрүне уйлыйлар иде.

Яшүсмер балалар, шул ашлыкларны эшләп бетергәч әтисе берлә базарга баргач, үзенә матур кара казаки, кара чалбарлык алдыруны, шунларны киеп, мәктәп ачылгач та букчага тыгып барыр өчен яңа китаплар, кызыл яза торган карандашлар, карандаш очлый торган пәкеләр алуны шатлана-шатлана уйлыйлар иде. Бунларның һәммәсенең дә уйлары дөрест иде. Һәммәсенең дә шул теләгәннәрен булдырырга, үзләре аңлаганча кәефләнергә хаклары бар

*29 нчы июль, 1895 нче ел*

## 19

Безнең дә эшләр бетте. Миңа мәдрәсәгә китәргә вакыт җитте. Әниләр күлмәк-ыштаннар тегәләр, миңа чәкчәкләр, майлар, баллар хәзерлиләр. Әти дә, төрлечә уйлап, мина күпме акча бирергәлегенең очына чыга алмый. Үзем дә күпме акча барлыгын, җәй буе күпме җыелдыгын хисапладым. Баргач ук һәйбәт трико казаки берлә чалбар тектерәм. Сәгать алсаң да яхшы булыр иде, ләкин акча җитеп бетмәс. Берәр атнадан китәм. Мәдрәсәгә барасы килсә дә, әллә нигә авылдан да китәсе килми. Әллә нинди хис шунда үземне бәйләп тота. Мәдрәсәдә бик кызык була инде. Бөтен шәрикләр җыелалар, һәммәсе әллә никадәр яңа хәбәр китерәләр. Әллә никадәр шатлык була. Мин, әүвәле харчевняга барып төшеп, хәзрәт берлә күрешеп килеп, харчевняда бер-ике көн торып, дуст-ишләрне, Шәрикләрне харчевняга алып килеп, пәрәмәч, сумса берлә сыйлап кына барып керәм. Кызык була.

*20 нче сентябрь, 1895 нче ел*

## 20

Бүген китәм. Әйберләрем һәммәсе җыелган. Китаплар, күлмәк-ыштаннар, күчтәнәчләр һәммәсе дә букчаларга тыгылган. Торырга дигән 25 сум берлә, эти казакилар алырсың дип биргән 10 сум берлә, үземнең җәйли җыйган 8 сум 38 тиен дә кәгазьгә алыштырылып, китаплар эченә куелган. Китәм, тагы киләсе җәйгә кайтырга булып китәм. Кыш буе, белмим, нинди үзгәрүләр булыр. Җәй буе берни булмады. Нә кызлар берлә йөрдем, нә башка бер эш эшләдем. Хәер, теге төрек тарихын, теге китапны биш-алты кат укып чыктым. Баргач та тагы шундый китаплар укырга кирәк әле.

Китүне уйлагач, күңелләр йомшарып китә, елыйсы килә. Киткәндә еламасам ярар иде. Бүген иртүк мунчага кереп, яңа күлмәкләр киенеп чыктым. Әни минем чыгуыма коймаклар пешереп, бал берлә чәй хәзерләгән иде. Бик тәмле иттереп эчтем. Әни миңа хәзер кунак иттереп карый. Минем берлә сөйләшкәндә яшь чыкмасын дип көчләнеп кенә сөйли.

Хәзер малай ат җигеп маташа. Әти аштан кайткач, китәм. Хуш, авыл! Хуш, миңа кызларыңнан бер файда бирмәгән, минем эчемне генә пошырган авыл кызлары! Хуш, иген тулы ындырлар! Хуш, җырлый торган тавыклар! Хуш, кечке авылдагы тынчлык! Хуш, авылның моң-кайгысыз тормышы! Хуш, авылның майлы бәлешләре, тәмле итләре! Хуш, яшьтәш егетләр! Хуш, урамнарда туңып уйнап йөри торган балалар! Хуш, бу елгы җәем! Хуш, мәңгелеккә кайтмый торган бу елгы гомерем! Һәммәсе, хуш!

*1 нче октябрь, 1895 нче ел*

## 21

Парахутта бару миңа һәрвакыт үземнең бик күп кимчелекләремне хәтеремә төшерә, әллә нинди үземнән үзем риза түгеллек хисләрен уяндыра. Менә хәзер бөтен парахут тулы кеше арасында мин ялгыз барам. Танышым юк, дустым юк, ишем юк. Башкалар ду килеп шаулашып, шатланышып барганда, мин моңаеп барам. Менә минем берлә кергән укучы рус егете, кергәндә ялгыз булса

да, өч-дүрт сәгать булмады, шундагы никадәр ирләр, кызлар берлә танышып алды. Шунлар берлә гомер буе дуст кеби йөри. Мин һаман тик торам. Татарлар берлә танышып, бергә барырга мөмкин. Ләкин анлардан ни файда итәсең? Анлар һәммәсе үз эшендә: берсе сатуын сөйли, берсе алуын. Миңа бунларның берсе дә сөт тә бирми, май да бирми. Руслар берлә катышып китәргә тел юк. Тел белсәң, менә шул марҗалар берлә рәхәтләнеп сөйләшеп йөрер идең бит. Менә кара, шул студент берлә шул марҗа кызы никадәр сөйләштеләр, белмим, никадәр тирән таныштылар. Әнә шул ябык сары хатын берлә теге сары төймәле рус кайчаннан бирле бергә йөриләр, кайчаннан бирле аерылыша алмаган кеби сөйләшәләр. Әнә тагы теге кечкенә генә кызлар берлә кечкенә генә рус малайлары нинди кызык иттереп уйнап йөриләр. Әнә тагы теге бармагы саен алтын йөзек кигән, корзинасына әллә никадәр ашамак-эчмәк әйбере төягән марҗа берлә танышкан таза егет, аерылмас дуст кеби, бергә ашап, бергә эчеп, кичләрне парахут өстендә бергә үткәрәләр. Әнә тагы бүтәннәр...

Мин һаман ялгыз! Әллә мин так туганмы?

*3 нче октябрь, 1895 нче ел*

## 22

Йа Раббии Казан никадәр зур! Никадәр матур!

Бу кадәр халык кайдан җыелган? Бу кадәр мал кайдан килгән? Бер Устиясендә генә әллә ничә мен кеше бар. Бер Устиясендә генә әллә ничә мең, бәлки йөз меңнәр кешегә ашарга-эчәргә җитәрлек ашамак-эчмәк, йөз мең кешегә сыйланырга җитәрлек тәмле нәрсәләр бар. Бунадагы карбызлар, кавыннар, йөземнәр, дүләләр, айвалар, оливалар әллә ничә авылның игенннән артык; әллә ничә авылның бәрәңгесеннән артык. Кем шулкадәр тәмле нәрсәләрне ашый! Каян бу кадәр тәмле нәрсәләргә акча йитә! Бу кадәр көтү-көтү эшчеләр ашыгып-ашыгып парахутка ташый торган маллар кая китәләр? Бунларны нишлиләр? Имут-имут өелеп куелган тиреләрне нишлиләр? Биек таулар кеби өелеп куелган шикәр мичкәләре кая китәләр?

Белмим, белмим! Шул нәрсәләрне күргәч тә минем күңелем тиз-тиз Казанга барып җитәргә ашыга. Менә мине ямщик алып бара. Әнә Хан мәсҗеде манарасы күренә, әнә башка мәсҗедләр. Мин бөтен эчем-күңелем берлән тизрәк шул Казанга барып керәсем килә. Бөтен ихласым берлә шул Казанның киң, зур урамнарында йөрисем килә. Мин шул Казанга килеп йитүемә шатлыгымнан тиремә сыймаенча ярылырга җитешәм.

Менә Казанга кердек. Кара, нинди матур кыз, пөхтә киенгән дә нинди матур атлап бара. Менә бу егетне кара, ут сүндерергә ашыккан кеби әллә кая ашыга. Кара, бу хатын ничек тирә-ягына карый-карый, әллә кемне көтә-көтә бара. Шунлар һәммәсе дә нинди бәхетле, нинди! Шунлар бит һәммәсе дә шул Казанда торалар, шул Казанның матур урамнарында, матур бакчаларында йөриләр. Шунлар бит һәммәсе дә шул әле гайре ниһайә кавыннар, карбызлар, алмаларны ашыйлар. Һәммәсе бәхетле, һәммәсе бәхетле!

Менә харчевняга килеп йиттем. Мин дә Казан кешесе булдым. Мин дә бәхетле! Бәхетле, бәхетле!

*5 нче ноябрь, 1895 нче ел*

## 23

Мәдрәсәгә килгәнгә бер атна үтсә дә, һаман әле сабак башлаган юк. Көн дә шәкерт килә, көн дә иске иптәшләрдән берсе килеп, әллә ничә айлар аерым үткәргән хәлләрне сөйләшәмез. Һәммәсе кап-кара булып кояшка пешеп, тазарып, зураеп, ирләнеп киләләр. Кайсыларының киткән вакытта шоп-шома мыеклары яңа гына бөркеп чыккан җоннар берлә бизәлгән була. Һәммәсендә дә әллә никадәр гайрәт! Әллә никадәр куәт! Әллә никадәр дәрт! Барсы да бу елны аерым бер ел ясап, әллә никадәр укырга, әллә никадәр алга китәргә, әллә никадәр үзгәрергә уйлыйлар. Һәркөнне кич берлә бер-бер иптәшнең өеннән алып килгән «маддә»ләре берлә сыйланамыз, чәй эчәмез, уйныймыз, көлешәмез, җырлыймыз, бәйрәм итәмез.

Казанда калганнарда да бу ел бер үзгәлек бар. Барсы да кеби җәй буе русча укыганнар. Кайсылары хәзер дә русчаны туктатмаганнар. Кайсылары

җәйләрдә рус кызлары берлә танышканнар. Кайсылары мөселман кызлары берлә дә дустлашканнар. Кайсылары Мәкәрҗә өстләрендәге вакытларын да буш үткәрмәгәннәр. Кыскасы гына: торганнар, яшәгәннәр. Минем кеби лыгырдык булып, бер эш эшли алмаенча вакыт үткәрмәгәннәр.

*13 нче октябрь, 1895 нче ел*

## 24

Кояш әллә нинди: инде сезне җылыта-җылыта аптырадым, арыдым дигән кеби, зәгыйфь кенә нурларын чәчеп, акыртын гына тирә-ягын җылыта, йомшак кына итеп яктылыгын тутыра. Ул инде, җәйге көн кеби, башларыңнан миләреңне эретеп чыгарырлык булып мәрхәмәтсез кылынмый. Аның хәзер шәфкатьле нуры мәрхәмәтле. Ул киң Кабан күле өстендә дә, элгәреге кеби, ялтыр-йолтыр иттереп, яшь батырның кылычын уйнатуы кеби кылынмый. Аны да кызганган кеби, аны да киләчәк суыкларга чыдарга димләгән кеби, үзенең йомшак җылысы берлә кочаклап, елмая-елмая гына бәхилләшә, саубуллаша. Ул хәзер, элгәреге кеби, агачларның яфракларын да, анларның матурлыгына көнләп, кыздырып корыттырырга теләми. Ул анларның соры йөзләренә көлемсерәп карап, анларга дустлык галәмәте күрсәтә, һава да бүген тып-тын. Әллә никадәр очып йөри торган үрмәкүч йипләре, йиддән дә, эсседән дә курыкмаенча, әллә кая таба китәләр. Иске коймалар янындагы кызыл-кызыл «марҗа»лар да бик һаваланып кына кояшның җылысында рәхәтләнәләр, туйлар ясыйлар. Бөтен һава әллә нинди алма, кавын, карбыз, кабак исе берлә тулган. Өйләрдән әллә нинди туклык исе чыга.

Кешеләрнең йөзләреңдә эшлеклелек балкый. Без, бөтен иптәшләр берлә сөйләшә-серләшә туеп беткәнгә, укырга башлыймыз. Бүген беренче мәртәбә хәзрәт дәрескә керә. Әнә эслиләр. Хәзрәт керде.

*20 нче октябрь, 1895 нче ел*

## 25

Дәресләр бик шәп китте. Бик кызу укыймыз. Бер-ике атнадан моназәрәгә йөрергә вакыт йитә. Мин хәзер «Тәрҗеман» гәзитәсе укый башладым. Кызык, дөньда әллә ниләр бар. Әллә кая бер Мәһди чыккан. Әллә кая агачтан кәгазь ясыйлар икән. Америка дигән йирдә егерме йидешәр катлы өйләр салалар икән. Ничек салалар! Кяфер шул! Намазы укыган, рузасы тоткан. Эше дә, шул, шунларны уйлап тору гына!

15 нче ноябрь, 1895 нче ел

## 26

Дуңгызлар, шул ишан малайлары һәммә йирдә эчеп йөрүдән бүтәнгә ярамыйлар! Теге башкорт ишанының угылы да мәдрәсәнең исемен сатып эчеп йөри икән. Кирәген бирдек. Ике көн исереп кайтканын көтеп торып, авызын иснәп бик пешерергә теләсәк тә, тугры китереп булмаган иде. Бүген юри артыннан китеп, бөтен фахешханәләрне ззләдек, таба алмадык.

Ул фәхешханә гаҗәп икән! Минем беренче керүем булганга, дер-дер калтырый-калтырый кердем. Әгәр шул мәдрәсәнең исемен былчыратучылардан үч алу фикере булмаса иде, һич керә алмый идем. Ул кызлар, ул хатыннар! Һәммәсе безне чормап алып: «Утырыңыз, утырыңыз!»— дип йөдәтә башладылар. Күңелгә әллә нинди хис төште. Бердән, тизрәк чыгасы килү, бердән, каласы килү. Әлбәттә, әүвәлге хис җиңде. Без теге малайны таба алмаенча бөтен фахешханәләрне йөреп бетердек. Кич берлә кайткач, капкаларны бикләтеп, сакларга тотындык. Кайтты, дуңгыз, бөтен авызы сыра исе берлә тулган. Аның өстенә тагы канәфер кадагы ашаган булган. Үзенең дә кирәген бирдек. Бөтен авызы-борын кан булды. Шулай кирәк ул, сабак укымаенча, мәдрәсә исемен сатып йөрүче малайларны! Сабак булыр!

*13 нче гыйнвар, 1896 нчы ел*

## 27

Кыш үтеп бара. Мин бер мәртәбә дә яза алмадым. Чөнки язылачак нәрсә булмады. Бу кыш былтыргыга караганда да мәгънәсез үтте. Моназарәләр азайды. Һәммә йирдә «аның базары төште» диләр. Мантыйкка тырышучылар кимеде. Мин дә былтыргы кеби тырышмадым. Әллә нәрсә күңел бунлардан бернәрсә чыгарыр төсле тормый. Йә инде, гыйлем мәсьәләсе берлә угьраш, имеш. Үзең надан бул да, гыйлемнең хәкыйкате ни идекен бел, имеш. Тагы ул гына җитмәгән, «Ваҗиб-ел-вөҗуд»нең гыйльме нинди, ничек, имеш. Мин кайдан белим! Ул моназарәләр кылышып беленә торган эшмени? Гакаиды тагы, әллә кайчан үлеп беткән, сөякләре көлгә әйләнгән рәвафыйзлар берлә моназарә кылыш. Шигыйләр берлә: «Хәзрәти Әбүбәкер хәлифә булырга тиеш идеме, хәзрәти Галиме?»— хакында шәм яндырып кычкырыш, имеш! Тарихтан Хәзрәти Әбүбәкернең хәлифә булганлыгыны беләм. Хәзрәти Галигә хәлифәлек тиешлегене белмим. Ул булса, фәлән булыр иде, төгән булыр иде, ул хак хәлифә дигән сүзләргә тагы: «Бәлки булыр иде, бәлки булмас иде»,— дип җавап бирми ни хәлем бар! Тагы, һич башында гакылы бар кеше шулай дими нишләсен? Ни дип мин хәзер 1300 ел моннан элек булган вакыйга өчен башымны ватып кычкырышып торыйм!

Ихлас кайтты. Бу арада кулга төшкән вак-төяк китапларны укып маташам. Әле менә рәдде нәсаридан бер китап төште. Кызык. Менә безгә белергә кирәк булса, шуны белергә кирәк. Рәвафыйзлар терелеп кайтмаслар. Христианнар күз алдымызда басып торалар!

*18 нче март, 1896 нчы ел*

## 28

Яз булды, көннәр җылынды. Мәдрәсәнең һавасы искиткеч бозылды. Иртә торганда башның эченә кургашын эретеп тутырган кеби булып, башны күтәреп булмый. Укыйсы килми, сөйлисе килми, орышышасы гына килә. Шуның өчен мин хәзер өйлә намазы укыгач та, чәй эчеп, йөрергә чыгып китәм. Урамнар былчырак булса да, һава бик матур булганга, рәхәтләнеп йөрим. Хәзер урамдагы халыкның төсе бөтенләй башка. Һәммәсендә әллә нинди

шатлык әсәрләре бар, һәммәсе дә шул озын салкын кыштан туеп, матур җәйнең якынылашуына сөенәләр кеби күренә. Урамнарда, крепость артларында әллә никадәр мөселман хатын-кызы, араларында нинди матурлары бар. Безгә дә кайчан гына шул хатыннар берлә, дустлашырга түгел, сөйләшергә генә дә насыйп булыр икән? Зур урам бүген искитәрлек. Ул маржа, ул маржа! Кайдан бу кадәр җыелган? Кайдан бу кадәр матур, пөхтә, бай киемнәр тапканнар? Ничек бунлар бу кадәр бай була? Әнә, студентларыны кара. Анлар да нинди киенгән. Без дә шунлар кеби студент. Ник сон без йөрергә чыга башласак, бөтен мәдрәсә буе берсеннән чалбар, берсеннән бүрек, берсеннән бишмәт җыямыз? Ник соң бунлар шул матур кызлар берлә рәхәтләнешеп сөйләшеп йөриләр дә, без анларның артларыннан авыз суымызны гына агызып йөримез? Буның сәбәбе ни? Без кеше түгелмени?

*29 нчы март, 1896 нчы ел*

## 29

Русчадан башка бер эш эшләп булмаганга, мин бу ел җәй калып русча укырга карар бирдем. Укыйм, шул руслар, маржалар берлә сөйләшерлек булырлык укыйм! Авылга да кайтмыйм. Укыйм!

*12 нче май, 1896 нчы ел*

## 30

Хәзер без мәдрәсәнең түбән өендә солдаттан калыр өчен аягыны бозып ятучы Салих берлә икәү генә торамыз. Мин Әндридән, аена өч тәңкә түләп, русча укыйм. Ул, мескен, көн дә күкфараз мае берлә аягыны яндыра. Ул ике атнадан бирле маташа-маташа эштән чыкты инде. Әүвәлләре көн буе ятып тора иде, аякка баса да алмый иде. Хәзер азрак йөри башлады. Ашау-эчүне, әлбәттә, мин хәзерлим. Акча азрак булса да тормыш кызык түгел. Русча бик авыр. Аның нәхүе, әллә нәрсә, безнең гарәп нәхүенә бер дә охшамый. Мин көненә ике сәгать укып кайткач бөтенләй буш. Эч пошканнан бакчаларга чыгып йөрим. Кабан күленә төшеп коенам. Ләкин һәммә йирдә бер бушлык

табам. Халык берлә шыгрым тулган бакчада мин ялгыз! Бөтен кешенең көлешүе, тавышы күкләргә күтәрелгән вакытларда мин моң! Бөтен кеше үзенчә кәефләнгәндә мин кәефсезлеккә чумган. Минем күңел утырткан бер эшем юк. Күңел сөйгән бер кешем, бер дустым юк. Мин һәрвакыт үзбашыма калып, үземнең фаразларым берлә генә яшим. Менә шул бакчада кызлар берлә көлешә-көлешә сөйләшеп йөри торган егетләр кеби йөрисем килә. Агач төпләренә утырып китап укып туйганның соңында, янына килеп утырган егет берлә сөйләшә торган ак киемле кыз берлә мин дә сөйләшәсем килә. Ул егеткә таба аның елмаеп карап сөйләгән сүзләрен минем дә ишетәсем, шул сүзләрне сөйләгәндәге аның йөзендәге үзгәрүләрне минем дә укыйсым килә. Әнә шул агач төбендә утырып тора торган ике татар кызы берлә сөйләшәсем, күрешәсем, дустланасым килә. Ләкин әллә нинди чылбырлар, әллә нинди мин аңламаган богаулар мине шул кызларга якын йибәрми, анлар берлә мине сөйләштерми, дустлаштырмый! Мин эчемдәге әллә нәрсәне, әллә нинди куәтне җиңеп шунлар берлә барып сөйләшә башлый алмыйм. Шулай итеп көн үтә, көн үткән саен минем кәефем китә бара.

*17 нче июнь, 1896 нчы ел*

## 31

Салих терелә төште. Ул хәзер аксап кына йөри Ул авыруыннан зарар итмәгән. Миннән яшерсә дә, аңладым. Ул күрше Садыйк байларның асраулары берлә мөнәсәбәт башлаган. Бүген мәдрәсәнең коймасы аша төшеп, асрау берлә сөйләшеп кайтты. Күзләре, йөзләре — бары да көлә. Мин аның ул асраулар берлә маташып йөрүен яратмаган кеби сөйләсәм дә, ахырдан бунын бер көнләү икәнене генә тасдикъ иттем. Ул, минем күңелне дә алыр өченме: «Әйдә, сине дә алып барам. Кече атна көнгә тагы хуҗалары дачага китәләр. Бөтен өй бер карчык берлә ике асраугa кала. Карчык сүз дәшми Берсе сиңа булыр»,— диде. Мин элгәре «ваклык, фәлән-төгән» дисәм дә, ахырдан риза булдым. Гомердә бер мәртәбә кызлар берлә уйнашырга, сөйләшергә кирәк

Хәзер мин әллә ни көткән кеби җомганы көтәм. Тизрәк килсен дә, мин дә кеше төсле булыйм. Ләкин кызлар берлә ничек сөйләшергә? Анлар бик борып-борып сөйләшергә яраталар диләр. Тырышырмын инде.

*21 нче июнь, 1896 нчы ел*

## 32

Кече атна йите. Мин юындым, киендем, нишләргә белмәенчә йөрим. Шул эш хәтеремә төшсә, калтырарга тотынам. Кич булды, вәгъдә кылынган вакыт йитте Без Салих берлә чыгып, койма янына килеп җиттек. Салих гади бер эш кеби, коймага менеп тә китте. Мин бизгәк тоткан кеше кеби калтырыйм! Йарабби, нишлим!Сөйләргә телем ачылмый. Салихка: «Тукта, бераз сабыр ит»,— димәкче булам. Булмый! Ничек кызларны күрермен? Ничек сөйләшермен? Бу калтырауны ничек туктатырмын? Коймага мин дә менә башласам да, тәнем калтыраганга, егылып төштем. Салих теге яктан: «Тизрәк, тизрәк!»—ди. Бөтен куәтне җыйдым, тагы мендем. Ни күз берлә күрим, караңгыда Салих янында ике кыз тора. Кызларны күрү минем тагы калтыравымны арттырды. Мин: «Бу кызлар берлә безне күрсәләр, хәзрәткә әйтерләр, хәзрәт күрсә, авылга беленсә, никадәр исемсезлек булыр, Алла сакласын!»— дип курка башладым. Ул ара да булмады, Салих: «Тизрәк!»—диде. Кызлар минем акыртынылыктан көлә башладылар. Мин кызардым, бүртендем. Эчемнән кайнар су акты. «Бунлардан ничек үземне мыскыл иттереп торыйм?»— дидем дә мәдрәсә ягына сикереп төштем. Менә ике сәгатьтән бирле Салихны көтәм. Ул кайтмый, ул кызлар янында, мин бунда үземә үзем ачуланып, көеп-янып ятам. Ник мин бер эшне эшләргә вакыт җиткәч кенә эшли алмыйм! Сәбәбе нәрсә?

*26 нчы июнь, 1896 нчы ел*

## 33

Кичә Сафа бутышник кереп: «Билетларыңыз бармы? Билетсыз кеше тормыймы?»— дип сорап, казыйны эзләп йөрде. Ярый әле байларның

приказчиклары тугры килеп: «Билетлы, бары да билетлы! Бездә билетсыз бирәү дә тормый. Әле шуны әйтергә йөри идем, Сафа абый, сезгә зәкяттән тегелгән читек күптән магазинда эленеп тора, юлын тугры килгәндә кереп чык әле»,— диде дә, билет мәсьәләсе хәл кылынды. Югыйсә, без шүрләгән идек. Шул билетсызлык чыннан да бик мазаны китәрә. Алыр идең, әллә кайларга барып, әлләниләр кылып йөреп эштән чыгып бетәргә кирәк.

Мәдрәсә бик туйдырды. Ахыры, кайтырга кирәк. Аз гына булса да авылда торып хәл җыярга кирәк. Быел ел буе мәдрәсәдә торып ни файда иттем? Һич!

*19 нчы июль, 1896 нчы ел*

## 34

Авылның бөтен урамыннан, өйләреннән, бакчаларыннан, ындырларыннан, кырларыннан көйгән ис килеп тора. Урамнардагы үләннәр дә көлгә әйләнеп аяк астында шытыр-шытыр ватылалар. Агачларның яфраклары сап-сары булып, сирәклекләре берлә ботакларын да яшерә алмаенча, үзләренең зәгыйфълекләреннән зарланган кеби, үзләренең ямьсезлекләреннән оялган кеби берсенә берсе бәрелешеп, сөйләшеп, коры-көйгән тавышлар чыгаралар. Һаваланып кына йөзеп йөри торган казлар, бокыр-бокыр сөйләшеп моназарә кылыша торган үрдәкләр, иртәдән алып кичкә кадәр чыкмый торган коенучы балалар берлә гөрли торган су буе да былтыргыча түгел. Көтү-көтү казлар урынында бер-ике канаты йолкынган каз берлә зәгыйфь, авыру каз бәбкәләренең моңлы тавышлары ишетелә. Коеныр чыккач та тәне кибеп беткәч суга төшәргә хәзерләнеп торыр өчен ыштаннарын кими торган тук, таза, ачык малайлар урынында моң гына, тавышсыз гына өч-дүрт малай гына уйнашып маташалар. Су да, үзенең хуҗасызлыгыннан курыккан кеби, үзенең былтыргы көмеш кеби төсен яшелгә буяган, үзенең фәкыйрьлеген, үзенең кадере беткәнен күрсәтмәс өчен, ямьсезлеген яшергән хатын кеби, йөзенә бака яфрагыннан ясалган пәрдәләр япкан. Былтыргы матур, җанлы үрдәк-каз тавышын ишетмәгәнгә күңеле моңаеп, җырчы бакаларга урын биргән былтыргы, яныннан үтеп киткәндә тазалык, исәнлек хис итәлә торган өйләр дә

үзгәргән. Анларның ватык-ватык тәрәзәләреннән чыга торган яңа икмәк май ит исләре, анларның эчләреннән ишетелә торган куәтле умарта гөрләве кеби көчлелек тавышлары һәммәсе дә беткән.

Авылларның кешеләре дә былтыргы кеби таза былтыргы кеби нык төсле күренмиләр. Анларның хәрәкәтләреңдә, анларның эшләрендә әллә нинди бер өметсезлек сизелә. Анларның күз карауларында, сөйләшүләрендә «булмады иңде, беттек» дигән уй тоела.

Былтыргы нык, таза, пөхтә киенгән кызлар да быел үзгәргән. Анларның да киемнәре былтыргы кеби үк яңа түгел. Анларның да төсләре былтыргы кеби ачык түгел. Анларның да күңелләре былтыргы кеби көр түгел. Анларның да кияүгә чыгып рәхәтләнеп тору өметләре былтыргы кеби үк көчле түгел.

Хайваннар да үзгәргән. Былтыр су коендырып кайткач йонының өстеңдә кояш уйнап йөри торган, сыртлары беленми торган атларның да кабыргалары юлланып-саналып тора. Анларның сыртлары да каләм кеби сузылып тора. Былтыр имчәкләреннән сөт ага-ага кайта торган сыерлар да быел ачлыктан зарланган тавышлары берлә бөтен дөньяны шаулаталар. Һаваланып кына көтүнең артыннан гына килә торган, бүген төнлә нинди бакчага урларга барырганы төшенә торган хәйләкәр кәҗәләр дә былтыргы вөкарьләрене бетереп, йөгерә-йөгерә кайтып, калган кычытканнарны ашарга ашыгалар.

Ындырлар да, үзләренең кечкенә, вак, чалыш-чолыш куелган чүмәләләре берлә кеше күзенә күренргә оялган кеби, моң гына торалар. Кырлар да, яу үткән кеби, кап-кара булып, шул бәхетсез, җансыз авылны үзләренең каралыклары берлә кочаклап алып, анларны киләсе өметләреннән дә мәхрүм итәләр. Урамнарда уйный торган бала тавышы, кичләрен җырлый торган егетләр тавышы да әллә кая киткән. Беткән, һәммәсе тынган.Һәммәсе моңайган. Бөтен авыл тын, бөтен авыл моң.

*10 нчы август, 1896 нчы ел*

Тагы көз, тагы мин мәдрәсәдә. Ләкин быел шәкертләр былтыргы кеби ачык-шат килмиләр. Һәммәсе ачлыктан зарлана, һәммәсе авыл хәленең начарлыгын сөйли. Быел мәдрәсә дә фәкыйрь булыр төсле күренә. Башка елларны әллә ничәшәр букчалар, сандыклар, савытлар берлә маддә төяп килүче шәкертләр быел кечкенә-кечкенә төеннәр күтәреп кенә киләләр. Акча да сыек. Харчевняларга төшеп тә кунак булып ятмыйлар. Мәдрәсәдә дә ачлык. Көйгән ис чыга.

*18 нче октябрь, 1896 нчы ел*

## 36

Бу ел кыш буе мәдрәсәдә ысулы җәдид, ысулы кадим низагысы берлә вакыт үтте. Шәкертләр икегә бүленде. Картрак, укымаганраклар — ысулы кадим тарафдары, яшьләр, тырышып укучылар — ысулы җәдид тарафдары.

Әүвәлге важибелвөҗүд, хөдүсе галәм моназарәләре урынны хәзер ысулы җәдид моназарәсе алды. Ысулы җәдид дингә муафикъмы? Пәйгамбәр заманасында булганмы? «Ля» күктән иңгән хәрефләр арасында бар идеме? Әбҗәд, һәүвәз көтүбе сәләфтә бармы, юкмы? Нәхү, сарыф укытуны үзгәртергә ярыймы, юкмы? Бу мәсьәләләр тирәсендә көне буе кычкырышамыз. Кызурак табигатьлеләремез орышыша, талаша да! Хәзер бөтен мәдрәсә шул ике фикер берлә бүленде. Арадагы элгәреге мәдрәсә хәмияте дә бетте. Ысулы җәдидчеләр башка мәдрәсә ысулы җәдидчеләре берлә дустлата башладылар. Ысулы кадим хәзрәтләрдән, хосусән үземезнең хәзрәтемездән көлә башладылар. Бу эш ике арада яңа дошманлык арттырды. Мин — ысулы җәдид. Мине хәзер хәзрәт тә яратмый. Быел русча укучылар тагы күбәйде. Мантыйк дәресләренең базары бик төште. Моназарәгә бары ике мәртәбә генә килделәр. Замана үзгәрде.

*18 нче гыйнвар, 1897 нче ел*

## 37

Бүген өйләдән соң югары урамга йөрергә чыгып киттем. Көн шактый соң булса да, урамда шактый халык бар иде: һәм дә Пассаж ягыннан ике яшь кенә хатын да үтеп бара иде. Мин кызу-кызу анларның артыннан куып җиттем һәм дә күзләренә карап үтеп киттем, бераз киткәч, артыма да борылып карадым. Хатыннар артык илтифат итмәсәләр дә, мин, бер магазин янында әйбер караган булып торып, анларны тагы үземнән уздырдым. Тагы артларыннан җитеп үттем. Яннарыннан үткәндә берәр сүз әйтергә теләсәм дә, бер сүз дә әйтә алмаенча, тагы вакыты тугры килер әле яисә үзләре дәшәрләр әле дип, чатта игълан укып анларны үткәрдем. Тагы бер сүз әйтә алмадым. Тагы артларыннан китим дип торганда, ломбард буеннан кызу-кызу килә торган бер хатын күреп, ашыга-ашыга урамның теге ягына чыгып, хатынга каршы тордым. Хатынга бик тугры карап торсам да, бер сүз дә эндәшмәенчә кызу-кызу үтеп киткәнгә, мин дә еш-еш атлап артыннан киттем. Хатын бер кондитер янында туктаганга, мин күземне бик тутырып карап үтеп киттем, һәм дә берничә мәртәбә артыма борылып карадым. Хатын, минем артымнан килмәенчә, урамның теге ягына чыкты. Мин дә, анда аулаграк дип, минем берлә сөйләшү өмете берлә чыккандыр дип, артыннан чыктым. Ләкин хатын һич илтифат итмәенчә түбән таба төшеп китте. Мин дә, кызу-кызу атлап күземнән югалтмыйм дип ашыксам да, бер йортка кереп киткәч, билгеле, борылырга мәҗбүр булдым.

Кәефсезләнеп кенә, авыны югалткан эт кеби, кайгырып килгәндә, часть буе тавыннан бер бик таза хатын берлә бер әбинең килүене күрдем. Мин, әллә нинди зур бәхеткә очраган кеби, бөтен эчем-тышым берлә шатлана-шатлана, тегеләрнең тау менеп йитүләренә чамалап, акрын-акрын гына атлап теге тарафка юнәлдем. Тегеләр менеп йиттеләр. Мин, күзем берлә ашарга теләгән кеби, теге хатынны сөзә башладым. Хатын, азрак елмаеп, янындагы карчыкка бер сүз әйтте. Тегенең елмаюыннан минем бөтен эчем шатлык берлә тулды. Мин, үземә үзем сыймаенча, шатлыгымнан ярылырга йитешеп, акрын гына алдыларына чыгып, тагы теге хатынның күзенә карадым. Теге хатын бу юлы ап-ачык көлде. Мин урыныда эредем. Аякларым калтырый, бөтен тәнем үзенә

бертөрле хәрәкәткә килә башлады. Битләремә кызыл йөгерде, колакларым ут кеби яна башлады. Мине тагы әллә нинди бер зур куәт артыма әйләнеп карарга кушкан кеби, әллә нинди бер куәт тыйган кеби булды. Минем эчемдә тартышу башланды. Ахырдан чыдый алмадым, әйләндем. Ни күзем берлә күрим, теге хатыннар урамның теге ягына чыгып баралар. Нишләгәнемне белмәенчә дә, борган машина кеби, мин дә анларның артыннан киттем. Анларны узганда тагы теге хатынга карадым. Теге хатын тагы тулы битле майлы күзе берлә миңа таба көлде. Мин әллә нинди сүз әйтергә теләдем, ләкин нинди сүз әйтергәлеген кистерә алмаенча үтеп киттем. Тагы артымнан әллә нинди ук кадалган кеби күз кадалганын күреп, артыма борылдым. Тагы теге хатынның көлгәнен күреп, бер чатта туктап, сүз кушарга кистердем.

Менә киләләр, менә хатын көлә, менә нинди якын, мин ни дип сүз кушыйм? Җаным, сине сөям диимме? Ул килешерме? Менә килеп җитте. Әнә миңа күзен тутырып карап үтеп бара. Мин тагы бер сүз әйтә алмадым. Менә карчыгы да: «Ни телисең?» дигән кеби, сөальле карау берлә карап китеп бара. Мин туктадым. Үземнең эш булдыра алмавыма ачуланып, ни булса булыр дип, кызу-кызу атлап хатын янына барып җиттем. Аның янына җиткәч, йөрәгем леп-леп тибеп, бөтен тәнемне калтырата башлады. Мин никадәр узарга теләсәм дә, куәтем җитмәде. Ахырдан бөтен куәтемне җыеп уза башладым. Тагы күзенә карадым. Тагы ул көлде. Тагы мин бер сүз әйтергә теләдем, тагы авызым минем әмеремне тутырмаенча, мин үтеп киттем. Менә хәзер бер магазин янында туктап торып көтәм. Бу юлы әйтмиче калмыйм. Әнә килеп йиттеләр. Хатын әллә нигә бу юлы көлми. Аның көлмәве бердән минем ачуымны китерде, бердән дәртемне арттырды. Мин тагы артларыннан киттем. Барып йитәр-йитмәс, теге карчык борылды да: «Ни эт эчәгесе кеби кеше артыннан йөрисең! Сөйләр сүзең булса, сөйлә»,—диде. Мин кызардым, бүрттем. Башыма суккан кеби, борылып, түбән урамга төшеп киттем. Бер капка төбендә утырып, бик озак хәл җыеп, тагы зур урамга мендем. Тагы күзем берлә татар хатыннары эзли башладым.

Әнә бер кибет алдындагы урындыкка икәү утырып торалар. Тукта, шунда китим. Берсе шактый матур күренә. Карап кына яннарыннан үтеп киттем. Тегеләр бер дә илтифат итмәгән кеби булдылар. Тагы бераз киткәч, борылып, тагы яннарыннан үттем. Бу юлы берсе азрак карап куйды. Аның каравы мине батырайтты. Мин, эш пешә дип, аз гына киткәч тә борылып карадым һәм дә тагы бик тиз борылып яннарыннан үтеп киттем. Мин үткәч тә, хатыннар тордылар. Мин акыртын гына артларыннан киттем. Хатыннар бер дә карамаганга, мин бер йирдә узып киттем; һәм дә туктап торып, теге берсенең күзенә карап уздым. Күз каравыннан бернәрсә дә аңламасам да, хикмәт чыкмасмы әле дип, артларыннан калмадым. Часть тавыннан төшә башлагач, бераз туктап, төшимме, юкмы дип уйласам да, ахырдан төшәргә карар бирдем. Менә Проломныйдан үттем. Бер чаттан борылганда элгәреге бер хатын, аннан ары берсе борылып карады. Мин тагы батырланып яннарыннан үтеп китсәм дә, берсе дә: «Җаным, сине бик сөям!» — дип сүз катмады. Мин тагы артта калдым. Шулай итә-итә Болак күперенә җиттем. Мин бунлар артыннан баруда файда юклыгын белеп калдым. Көн караңгыланып, фонарьләр яндырыла башлаганга, мин Болакның караңгырак җирләрендә йөри башладым. Менә күземә берсе артлы берсе әллә нинди сәләмә, былчырак киемнәрдә марҗалар очрый башладылар. Барысы да төрлечә иттереп дәшә башладылар. Мин бунларның кабахәтлекләреннән җирәнеп, Проломныйга чыктым.

Проломныйны тагы бер-ике мәртәбә әйләндем. Очраган бер марҗа, татар хатынына күземне тутырып-тутырып карадым. Ахырдан арып бетеп, кайтырга уйлаганда, бер чаттан борылып китә торган ике марҗаның күзләренә бик туры карадым. Марҗалар борылыр-борылмас миңа баш иделәр. Мин әүвәл узып китсәм дә, мин борылып караганда тагы кул изәгәнгә, мин акыртын гына тегеләр артыннан киттем. Күңелем никадәр курыкса да, нәфесем бик барасы килгәнгә, калтырый -калтырый борылдым. Тегеләр янына барганда, бизгәк тоткан кеби, тешләрем берсенә берсе бәрелешеп сөйләшәләр иде. Ниһаять, барып йитеп: «Здрафстуй!» — дидем.Кул бирделәр. Мин икесен дә күздән кичереп, бер матуррак төслесен кулыннан тоттым. Тегесе борылып китте. Без

караңгы гына урамда икәү калдык. Мин теген култыклап, әйдә, дип, сөйләшә-сөйләшә киттем. Бер йиргә барырга карар бирдек. Мин никадәр калтыранам да, очраган бер кешедән качып урамның теге ягына чыксам да, марҗамны югалтмадым. Менә бер мунчага барып кердек. Мин ут яктысында марҗамны күрдем. Күңелемдә ике бик зур куәт сугыша башлады. Керергәме, юкмы?

Керергә дип карар бирергә өлгерә алмадым. Кермәскә кистердем. Ул фикеремдә дә нык тора алмаенча, керергә уйладым. Кердек. Мин нумира алырга киттем. Марҗа калды. Актык минут килеп җитте. Минем бөтен тәнем калтырый, тешләрем шыкылдый башлады. Аяк өстенә басып тора алмый башладым. Кулымдагы портмонетым җилдә селкенә торган агач ботагы кеби кулымда селкенә башлады. Менә ишек ачыла башлады. Бу керүченең минем таныш кешем булу ихтималы күңелемә килеп төшеп, яна торган өйдән качкан кеше кеби, каршы ишектән чыктым. Саф һаваны сулый-сулый, бүгенге эшләремне уйлап, арып-изелеп, үземнән үзем туеп, үземне үзем суярлык булып кайтып киттем.

*10 нчы февраль, 1897 нче ел*

## 38

Кичә мин, безнең мәдрәсәдән чыгып, Истанбулга китеп, төрек мәктәбендә укыган бер бай баласы берлә таныштым. Аның бик күп төрек китаплары бар икәнен ишетеп белгәнгә, шунларны сорадым. Ул килеп алырга кушты. Бүген әллә никадәр романнар, төпләгән гәзитәләр, рисаләләр төяп кайттым. Хәзер укырга тотынам.

*13 нче февраль, 1897 нче ел*

## 39

Төрек китапларыны укыйм. Анларны су урынына эчәм. Романнары әллә нинди, хикәяләрне бик сөям. Ләкин ник бу романнарның кешеләре барсы да Жор, Альфред, Карл, Эмма, Катрин кеби ят исемнәр? Төрекләрнең үз тормышларыннан ник язылмаган?

Укыйм-укыйм да, шул романнардагы тормышка кызыгам. Нинди рәхәт тормыш! Ире-хатын бергә, качу-нитү юк. Сөйләшәләр дә шатланышалар. Матур хатлар язышалар, еглашалар да кавышалар, аерылышалар. Кызык тормыш! Ләкин минем гакылым җитмәгән бер йир бар. Бунлар һәммәсе әллә нинди кыйммәтле әйберләр алалар, зур бүләкләр бирәләр, күп-күп акчалар оттыралар, оталар. Әллә кайларга сәяхәтләргә китәләр. Шулай эшләргә акча каян табалар? Каян йиткерәләр?

*21 нче март, 1897 нче ел*

## 40

Кичә өйдән биш тәнкә акча килгән иде. Бүген чыгып пальтә алып кердем. Альфредлар шулай киенә бит, миңа ник киенмәскә! Иңде аякка ботинка алырга, чалбар алырга, башка яхшырак бүрек алырга гына калды. Аннан ары мин дә, анлар кеби, шул ачык тормышта хатын-кыз берлә катнашып йөрим. Бакчаларга барам. Аңдагы шул матур кызлар берлә теге романнардагы кеби сөйләшәм. Анлар ничек, берсе, мәсәлән, яулыгыны төшереп калдыра, мин илтеп бирәм. Шуннан китә! Нинди кызык!

*9 нчы апрель, 1897 нче ел*

## 41

Мин, толып, самавырны ломбардка салып, казаки, бүрек эшләттем. Теге пальтәне бер да бар киеп булмый әле. Безнең халык надан әле. Ул Альфредларны-ниләрне белми. Хәзер һәркөнне кичкә таба һәйбәтләп киенеп-ясанып бакчаларга чыгам. Шундагы кызлар, хатыннар берлә сөйләшергә, дустланышырга йөрим. Йарабби, нинди матур кызлар бар! Мин шунлар берлә йөрерменмени? Шунлар берлә шул романнардагы кеби сөешерменмени? Нинди кызык!

*1 нче май, 1897 нче ел*

## 42

Ике атна булды, һәркөнне Бакыр бабай бакчасына барам. Бер кыз да килеп сөйләшә башлаганы юк. Әллә теге романнардагы кеби үк булмадымы дип бик уйлагач, исле маем берлә кершәнем юклыгын белеп, кичә хәзрәттән бурычка алган өч тәңкәдән һәйбәт исле май, сабын, кершән алып кердем. Менә бүген шунларны ягынып чыктым. Һаман кызлар килмиләр. Бу ник болай?

*21 нче май, 1897 нче ел*

## 43

Бүген бер кыз миңа бик көлеп карап үткәнгә, барып утырганыны көтеп торып, мин дә янына утырдым. Азрак карап торгач, теге романнардагы кеби, сүз башладым. Кыз бик тиз сөйләшә башлады. Мин, романдагы кеби, ничек китәргә аптырап торганда, кыз үзе: «Әйдә, мороз (туңдырма) ашыйк»,— диде. Мин, әлбәттә: «Әйдә», — дидем. Ашаган морозга да түләдем. Шуннан бакча буе бер мәртәбә әйләндек. Мин төрлечә иттереп, романдагыча сөйләргә тырыштым. Кыз мине бик тиз сөюеннәнме, белмим, нидән, бераз йөргәч тә: «Әйдә, бер йиргә барыйк»,— диде. Мин шатланып: «Кая?» — дидем. Ул: «Теләсәң мунчага, теләсәң безгә»,— диде. Мин бунынң бу кадәр тиз мине сөюеннән, бер яктан, шатланып, бер яктан, гаҗәпкә калсам да, кесәмдә акча азга, бара алмадым. «Иртәгә барырмын»,—дигән идем, кыз миннән борылып китте. Ахрысы, теге романнардагы кеби, мин сүзене тутырмаганга үпкәләгәндер!

*27 нче май, 1897 нче ел*

## 44

Кичә вагунга, безнең өсткә ике татар хатын килеп керде. Без, анлар берлә сүз эләктереп җибәреп булмасмы дип, теге романнардагы кеби, кытайларның тәрәкъкыйсе, Әндәлес гарәпләренең мәдәнияте хакында сөйләргә тотындык. Әлбәттә, ул хатыннар теге романнарны укыган булсалар, андагы Катрин кеби, безнең сүзгә катышып китәргә тиеш иде. Менә шунысы начар шул, анлар берни укымаганнар.

*2 нче июнь, 1897 нче ел*

**45**

Кичә циркка бардык. Нинди кызык! Ул хатыннар атлар өстендә нинди шәп йөриләр, тимерчыбыкта нинди кылыналар! Бу урыслар бигрәк тәрәккъкый иткәннәр, без бигрәк артта. Кайчанга безнең дә шундый циркла-рымыз булыр икән? Кайчанга безнең дә кызларымыз, бөтен халыкның исене китәреп, тимерчыбык өстендә йөрерләр икән? Кайчанга безнең кызларымыз да шундый атлар берлә уйнарлар, маймыллар биетерләр икән? Ул көнне күрергә ерак әле, ерак!

*15 нче июнь, 1897 нче ел*

**46**

Минем шул бакчадагы хатыннар, кызларга әле бик ачуым килде. Ничә атна, ничә айдан бирле йөрим, ичмасам берсе килеп дәшсен?

Бу урыс халкы надан шул. Анлар шул теге романнарны укымаганнар. Югыйсә, әлбәттә, минем кеби, романнар укыган, чиста киенгән, исле майлар сөрткән, кершән ягынган, Әндәлес гарәпләренең мәдәниятен белгән бер егет берлә ник сөешмәскә? Наданнар, наданнар! Бунлар шул, ни сөйләсәң дә, урыс әле! Анлар шул, ничә әйтсәң дә, сары урыс шул!

*4 нче июль, 1897 нче ел*

**47**

Көненә әллә ничәшәр мәртәбә битне сабынылап юганга, битем ярылып беткән. Су тиерер хәл юк, әрни (авырта). Ләкин чиста булсын өчен юынмый хәл юк. Бакчаларда андый-бундый булып йөрергә ярамый бит! Ләкин иртәдән кичкә кадәр бакчада йөрүдән арып беттем. Бер мәгънә чыкмый. Бер кыз килеп танышмый, сөйләшми!

*18 нче июль, 1897 нче ел*

## 48

Мин авырыйм. Башым авырта, начар йоклыйм, төш күп күрәм. Дуктыр авылга кайтып китәргә һәм дә сөт эчәргә кушты. Шулай ук быел укыган романнарымнан аз гына да файда итмәенчә Казанны ташлап китиммени? Хәер, романнарда авыл кызлары берлә сөешүне тагы мактый; анлардагы сафлык, тазалыкны ярата. Мин дә шулай итәрмен. Хәзер инде мин элгәреге кеби мәми авыз түгел, роман укыган кеше.

*22 нче июль, 1897 нче ел*

## 49

Әти берлә без бозылыштык. Мин роман галәмен мактадым. Ул үзенең искедәге сәләфләренең тормышыны мактады. Аныңча, бөтен сәгадәт — каткан икмәк ашап камыш намазлык өстендә ятып, китап карап, зикер-тәсбих берлә мәшгуль булуда, имеш! Юк инде, мин андый әкиятләргә ышанудан үткән. Мин хәзер фикерле шәкерт. Мин хәзер милләт кайгыртам, дин кайгыртам. Үземезнең татарларны шул романнарда укыган кеби итәргә тырышам. Мин — ысулы җәдид. Мин мәктәпләрнең рәтләп укытуларыны телим. Мин гәзитә укыйм. Бөтен дөнья мөселманнары арасындагы артка калуны беләм, аның сәбәпләрен эзлим. Мин киләчәктә әллә ниләр эшләргә планнар корам. Мин фанатик түгел. Мин кием низагьларыны яратмыйм. Мин романнарда киенгәнчә киенәм. Хасыйле, мин — яңа фикерле тәрәккый пәрвәр, әти — иске фикерле!

*29 нчы июль, 1897 нче ел*

## 50

Авылда гомер үткәрү бик авыр. Бунда нә бакча бар, нә музыка бар, нә матур киенгән фәрештә төсле кызлар бар, нә иптәшләр бар! Кая карасаң, кап-кара мужик, салам башлы (түбәле) өй, каткан киемле ирләр, хатыннар. Бөтен авыл тып-тын. Шәһәрдәге музыка урынына кичләрендә бунда бака тавышы берлә этәч тавышы гына ишетелә.

Мәдрәсәдәге кеби, милләт кайгысы урынына мужиклар үзләренең сары алашаларының корчаңгы булуыны, чуар сыерның бозаулавыны, караколак сарыкның йоны кыркылуыны, каз бәпкәсенең югалуыны, үрдәкнең икенче мәртәбә сала башлавыны, тавыкларның йомырка салудан туктауларыны сөйлиләр. Дөньяда шуннан башка эш юк кеби, буннан ун ел элек Кашка биянең югалуына, Кара сыерның вабадан үлүенә, Рәхилә әбинең кәҗәсен бүре ашавына кадәр барып йитәләр. Шуннан тагы аз гына үтеп, быелгы ашлыклар, быелгы каты сука, быелгы печәнгә барып төртеләләр. Шул сүзләрнең тәменнән туймаган кеби, бөтен мәҗлес буе шуннан үтә алмыйлар. Мин сүзне зуррак мәсьәләләргә, ысулы җәдидкә, җирнең түгәрәклегенә әйләндерергә телим; ләкин анларга һич илтифат итмиләр. Минем эчем поша, бунлар берлә орышышасым, сүгешәсем килә. Шул зур авылда үземне үзем ялгыз хис итәм. Әйе шул, салам башлы өйләрдә салам, ашлык, ат, сыер, кәҗә, сарыктан башка нәрсә хакында уйлый белмәгән авыл эчендә, мин — француз романнары укыган, әллә нинди яңа фикерләр берлә маташкан яшь шәкерт — ялгыз шул!

*3 нче август, 1897 нче ел*

## 51

Мин хәзер бик күп уйлыйм, һәркөнне бакчада ялгыз утырып, ындырга барып ялгыз калып, җәяү кырга йөрергә чыгып, һаман фаразга чумам. Үземнең хәзерге хәлемне түгел, шул авылның наданлыгыны, анларның шул теге мин романнарда укыган тормыштан ераклыгыны, анларны шул тормышка кертүнең юлларыны төшенәм. Төшенәм... Төшенәм дә, ләкин бер дә очына чыга алмыйм. Бунларны нишләргә кирәк? Миңа нишләргә кирәк? Шул мәсьәләләрне хәл итә алмыйм. Күңел берлә әллә ниләр эшлисем килә. Шул авылларны, шунларның кешеләрене, Яхъя мулла пәриләре кеби, бер төн эчендә яңадан төзәсем, яңадан ясыйсым килә. Ләкин кай төшеннән тотарга белмим.

*7 нче август, 1897 нче ел*

## 52

Казаннан алып кайткан китапларны укыган саен минем башымда фикерләр күбәя. Минем кечкенә мием, тегермән кеби әйләнеп, шул уйлардан бер авыл ясамакчы була. Әллә нәрсә, әллә нәрсә, бик зур эш эшлисе килә. Бердән, бу бөтен дөньяда яткан, изелгән мөселманнарны күтәрәсе, анларны элгәреге кеби зур ясыйсы килә. Бердән, әллә нинди бик зур, бик зур падишаһтан да зур, сугышчы баһадирдан зур, олуг галимнәрдән зур булып, әллә нинди зур эшләр эшлисе килә. Динне әллә нинди ямьсезлекләрдән пакьлисе килә. Әллә ниләр, әллә ниләр эшлисе килә.

*15 август, 1897 нче ел*

## 53

Кичә, бик эч пошып, үземне үзем күрәсе килми башлагач, иске гадәтемчә, бераз кырларда йөрергә чыгып киттем. Бераз йөреп, су буеннан әйләнеп кайтырга уйладым. Әллә ниләр төшенеп, уйлап килгәндә, көмеш кеби саф тавыш берлә бер кызның көлгәнене ишеттем. Йокыдан уйганган кеше кеби, тирә-ягыма карангалый башладым. Суның теге тарафында, болынның уйсу йирендә, төрле-төрле бизәкле кызыл, ал, сары, аклы-каралы, кызыллы-сарылы күлмәкләр кигән, кып-кызыл француз яулыклар бәйләгән ун-унбиш кызның өелеп торуыны һәм дә анлардан бер-ике адымда гына укалы кәләпүшләр кигән, оек-чабатаны пөхтә иттереп бәйләгән, ак берләнтин күлмәкләр кигән егетләр күрдем. Бунларның бунда нишләргә жыелганыны белгәнгә, күренеп кәефләрене бозмыйм дип, ике солы арасында, анлар күрмәсә дә үзем күрә торган урынга утырдым. Күзләре, йөзләре, бөтен селкенүләре әллә никадәр мәгънәләр аңлата торган егетләрне, кызларны жентекләп карый башладым.

Менә уен башланды. Берәр кыз, берәр егет аерылышып кулга-кул тотыныштылар, һәммәсе шулай бүлешеп беткәннән сон, бер егет, бер таяк берлә сызык сызды да, башкаларга читкә тәртеп-төртеп күрсәтеп, әллә ниләр

сөйләде дә янындагы кызы берлә килеп басты; һәм дә кыз берлә икесе дә, кулларыны сузып, бер кыз, бер егетнең таза, нык кулларыннан бер киртә ясаган кеби юлны яптылар. Анлар артындагы бер пар да, шул кулларны бәреп чыгып китеп, икесе ике якка таба чабыша башладылар. Анлар артыннан кулларын ы киртә ясаган пар куа китте. Кызлар сузылып-сузылып чаба башладылар. Куылганнар, куучылар тотудан элгәре бер-берсенә тотынышыр өчен, дуга ясап, каршы чабыша башладылар. Куа торган егет кача торган кызны тотыйм дигәндә генә, аның каршы егете килеп йитеп, кара-каршы килә торган ике локомотив бәрелгән кеби, кыз берлә егет бер-берсенә бәрелделәр. Егет кызны зур кулы берлә иңбашыннан тотып алды. Куган егет, үзенең урынына китеп, башкаларны куарга тотынды.

Шул уен әллә никадәр озайды. Инде кызлар, егетләр тирләделәр, пештеләр. Битләренә кызыллык йөгерде. Күзләре тагы майланган төсле күренә башлады. Уен озайган саен, куучы егетләр берлә куучы кызлар уен мәйда-ныннан ераккарак, елгаларның борылуларына, кеше күзеннән саклый торган йирләргәрәк китә башладылар.

Менә бер кыз минем күземә генә күренә торган борылгычка керде. Аның артыннан бара торган егет тә, аның кеше күзеннән югалуы берлә, арыслан кеби бер сикерү берлә кызның янына барып йитеп, кызны җил-кәсеннән бер кулы берлә тотып борып, аның янган битеннән чуп иттереп үпте. Мин дә шул эштән әллә нишләп урынымнан сикереп киттем. Шунларның кызыл йөзләренә, ут кеби уйный торган күзләренә, бер-берсе- нен муеннарына салынган кулларына, әллә нинди зур хиссиятләрне түгелмәсен дип куркып, акыртын гына селкенә торган һәр әгъзаларына карап, мин бунларның хәзер шул вакытта мәсгудлекләренә шатлана вә шул мәсгудлекләре өчен анларны көнли, үземне үзем шулай күрә алмавыма кайгыра идем. Чынында никадәр мәсгудләр! Үзләренең яшьлекләренең кадерен нинди беләләр дә, шул яшьлекнең вазыйфасын нинди матур иттереп тутыралар! Нинди гөнаһсыз иттереп, яшел үләннәр, тулы ашлыклар эчендә бер-берсенең эчендәге янган утларыны сизешеп, бу табигый утка каршы килмәенчә, авызларыннан

алышкан үбешүләр берлә анларның куәтләрене арттыралар, анларның ләззәтләрене киңәйтәләр. Нинди матур иттереп үзләренең эшли-эшли ныгып беткән куллары берлә бер-берсенең нык-таза муеннарыны кочаклыйлар. Нинди ихлас берлә кызудан кызарган битләрене кайнар авызларының үбүләре берлә бизәкләп-бизәкләп бетерәләр. Нинди иттереп, үзләренең икелекләренә протест ясаган кеби, бер минутта берләшергә теләгән кеби, ничек бер-берсенә сарылышып-сарылышып кочаклашалар. Йарабби, никадәр рәхәт, никадәр сәгадәт! Яшәңез, егетләр, кызлар! Яшәсен бу гадәтеңез! Яшәсен яшьлек!

*18 нче август, 1897 нче ел*

## 54

Әтиләр мине чынлап мулла ясарга телиләр. Әни, ул мәсьәләне тәмам хәл иткән кеби итеп, миңа кызлар эзли, һәркөнне чәй янында: «Фәлән мулла кызы бик чибәр, имеш. Әле Нәсыйхә абыстай килгән иде. Шул анларның авылларына барган икән, юри барып күрдем, сезне сораштылар, ди. Фәлән байның кызы да бик укымышлы, ди, җиһазы-фәләне бик күп, имеш. Әле миңа хатын Хәерниса абыстай аркылы, дога кылсын дип, күкрәк йибәргән иде. Фәлән кеше кызы фәлән, имеш»,— дигән сүзләр берлә башны әйләндерәләр.

Мин элгәре бундый сүзләрне көлкегә әвереп бетергәләсәм дә, кичә мәсьәләне бик җитди иттереп алдыма китереп бастырдылар. Мәхәлләнең байгураларыннан берничәсе кереп, шул мәсьәләне алга куйдылар. Мин хәзер бу мәсьәләгә чынлап җавап бирергә мәҗбүр калдым. Әти мулла булмаска дигән фикеремне белә, ләкин ул фикер төпле бер уй дип ышанмаганга, аңар артык әһәмият бирми кеби күренә. Әни минем мулла булмавым уены күңеленә дә кертеп чыгара алмый. Ул мулла булмаенча тору мөмкин икенчелегенә дә шөбһә итә. Чынында, ничек мулла булмаенча, иртәдән кичкә кадәр ашка йөрмәенчә, руза гаетендә фитыр җыймаенча, корбан гаетендә тире алмаенча, иген өлгергәч гошер җыймаенча яшәргә кирәк? Хәтта мине мулла итәргә теләүләреннән мужиклар һаваланалар да: «Безнең авыл шәһәр кеби. Фәләннәр

бик булырлар иде дә, әлхәмделиллаһ, әле хәзрәт фатихасыннан чыгып без эш итмимез»,—дип, куәт үзләре тарафында икәнлеген дә күрсәтеп куялар.

Миңа килсә, минем аз гына да мулла булырга исәбем юк. Ничек мулла булырга кирәк? Мин әле, әүвәл, шулай итеп — биш вакыт намаз укып, атнасына бер мәртәбә, җомга көнне, беркем аңламый торган телдә хотбә укып, әллә ниди бер бала исеме кушып йөрүдә һичбер мәгънә тапмыйм. Буннан кемгә булса да файда була дип ышанмыйм. Тагы, шуның өстенә, шул этинең гомере буена сөйли торган вәгазь китапларына, андагы ике тиен садака бәрабәренә җиде оҗмахның җиде капусы ачылуы вәгазьләренә ышанмыйм. Шунларны кылудан, сөйләүдән халыкка файда түгел, зарар була дип игьтикад кылам. Шуның өстенә, безнең авыл кеби, карт муллаларны тәгъзыйм кылырга, анлар ни сөйләде шуны Коръән сүзе кеби тыңларга ышанган халыкка минем яшь уйларым, яңа фикерләрем аңланыр дип, анлардан бер мәгънә чыгар дип аз гына да ихтимал бирмим. Анларны үзем теләгән бер фикергә бора алуыма, анларның шул иске уйларын, черегән гадәтләрен җимерә алуыма ышана алмыйм. Тагы иң авыр җире — һәр нәрсәне сөйләгән вакытта дин ноктаи нәзарыннан сөйләү. Уку кирәк, чөнки дин шулай куша; игеннәрне яхшы эшләргә кирәк, чөнки дин куша; баерга тырышырга кирәк, чөнки байлык берлә дин саклана.

Ләкин русча укырга кирәк, хатыннарны качырмаска кирәк, динне дөньядан аерырга кирәк мәсьәләләрендә ничек итеп дин куша диерсең? Дөньядагы бөтен эшләрне, мәсьәләләрне ничек иттереп кагып-сугып дин эченә тутырырсың? Ничек һәр нәрсәне анларның башларына, уйларына муафикъ итеп үзгәртерсең? Шуның өстенә, мин, тагы, дингә ул кадәр ышанмыйм да. Шунларны ничек иттереп халыкка сөйләрмен? Үземчә булса, анлар мине аңламаячаклар, мине кяфер диерләр. Анларча булса, ул вакыт минем мәгълүматымнан бер файда булмаячак, мин үземнең халкыма тәэсир итмәячәкмен. Шуның өчен мин мулла булмаска тиеш һәм булмыйм. Кеше кешене һәм үзен алдамаенча гына гомер үткәрергә тырышырга кирәк.

*21 нче сентябрь, 1897 нче ел*

## 55

Әти берлә безнең арамыз шактый салкынылашып, мин мәдрәсәгә китәм. Ләкин һич уку фикере берлә түгел. Шул авылдан, шул, көн дә бертөсле муллалыкның файдасына китерелә торган дәлилләрдән, мулла булып торуның манзарәләрен ишетүдән котылыр өчен генә китәм. Мәдрәсәдә бернәрсә укый да алмаячакмын, укымаячакмын да. Укырга теләсәм дә, нәрсә укыйм! Укырлык әйберләр бармы? Мөмкин булса, русча укыйм, төрек әдәбияты укыйм! Нишлим сон, безнең кеби укыйсы килгәннәргә мәдрәсәсе, мәктәбе юк. Халыкның бәхетсез егетләре ни очраса шуны укымый ни хәле бар! Хәерче кеби, кемнән ни калса шуны миенә тутырмый ни юлы бар! Менә мин дә шулай итәргә тиеш. Шул фәннәрне, шул гыйлемнәрне беләсем килгәндә — калдык-постык берлә башымны тутырырга, дөрестлеге шөбһәле мәгълүматлар берлә миемне зәһәрләргә тиешмен. Бу ник болай? Шулай ук минем вә минем кеби әллә ничә мең, йөз мең татар балаларының шулай укырга, башкалар белгәнне белергә, башкалар кеби, белмәгәннәрне өйрәтергә хаклары юкмыни? Буңар ничек чыдарга кирәк? Ничек шул ак, якты мәгариф гасырында күрәләтә надан булып калырга кирәк? Ник без бу чикле бәхетсез туган! Ник без мәктәбе, китабы, акчасы бар бер кавемнең балалары булмаган! Яисә ник безнең мәктәбемез, китапларымыз, әдәбиятымыз булмаган?

*1 нче октябрь, 1897 нче ел*

## 56

Мәдрәсә мәдрәсә хәленнән чыккан: бик күп шәкерт, мәдрәсәне буш өй хисап итеп, русча укырга йөриләр. Мәдрәсәдә ашау-эчү, яту-кунудан башка бер эш тә эшләмиләр. Хәзрәт берлә шәкертләр арасындагы мөнәсәбәт тә бик начар. Хәзрәтне һич эшкә алмыйлар, аның сүзене тыңламыйлар, аның фатихасыннан курыкмыйлар. Мин дә русча укырга тотынам. Мәдрәсә бозылды! Ләкин сәбәбе, хәзрәт әйткәнчә: «Фатихадан курыкмау» гына!

*13 нче гыйнвар, 1898 нче ел*

## 57

Мин, русча укысам да, хәзрәткә дәрескә дә утырам. Хәзрәттән яхшы түгел. Дәрестә аз гына ихласым булмаса да, исәпкә тулсын өчен утырам. Инде хәзрәт тә хәзер шулай булса да утыруны ярата. Һәркөнне: «Мәдрәсә бозылды»,—дип зарлана. Менә үзең теләгәнчә, торырга яңа бер юл ачылды. Мине Сибириядә бер шәһәргә мөгаллимлеккә чакыралар. Вазыйфәсе дә шактый яхшы. Шәһәрдә торырга. Үзеңне үзең тәрбия кылып булачак, русча укырга да мөмкин булачак. Минем өчен зур бәхет. Әлбәттә, барам. Әле этиләрдән рөхсәт сорап хат яздым. Җавап көтәм.

*8 нче февраль, 1898 нче ел*

## 58

Ялтыраган ай яктысы берлә нурга коенган, ап-ак кар диңгезе кеби Кабан күленең кар бөртекләре шул матур түгәрәк айга, шул кәндилләр кеби сирәк-сирәк күренә торган йолдызларга җем-җем иттереп, елтыранып көлемсерәшәләр, анлар берлә уйнашкан кеби, күз кысышкан кеби елмаешалар. Кабан күленең теге тарафындагы фонарьлар да, тәрәзәләрдәге утлар да бу көннең матурлыгына кызыккан кеби, аның көмеш кеби саф елтырауларына, сөт кеби аклыгына көнләшкән кеби; аның шул ай, йолдызлар берлә күз кысышып уйнаш итүенә гаҗәпкә калып каткан кеби вә шул матурлыктан, ләззәтләнүдән аерылудан куркып, бер минутка да күзләрен аера алмаган кеби, туп-тугры ак карларга тегәп карап торалар. Анлар да, ул матур ак диңгезнең кырыйларыны үзләренең моң гына төшкән яктылыклары берлә челтәрләп-бизәкләп, шул зур Кабан күленең бөтен итәгенә төрле-төрле печемнәрдә кружевалар, челтәрләр ябыштыралар. Уртадан үтеп китә торган зур юл, аңар кушыла вә аерыла торган вак-төяк юллар да, көндезге иксез-чиксез атларның,

йөкләрнең, кешеләрнең үтүеннән арыган кеби, юлчының, юлаучының юклыгыннан шатланган кеби, бөтен кулларыны, аякларыны җәеп сузылып ятып хәл җыя, бабалардан мирас калган, безне суы берлә, бозы берлә сыйлый торган, матурлыгы, гүзәллеге берлә бөтен шәһәремезне бизи торган шул зур күлнең тынчлыгына, аның шул зур, озын, арыла торган хезмәтләреннән соң хәл җыюына ригайә кылган кеби, аны татлы тирән йокысыннан уятырга кызганган кеби, бөтен тирә-янда тавышсыз-тынсыз тик тора.

Минем кайный торган күңелем, эчемә сыймаенча ташып чыгарга тора торган йөрәгем, бөтен башымны биләгән уйларым әллә нигә шул матурлыкны җимерәсе килә; әллә нигә шул матур айның көмеш нурлары берлә коена торган ак күлнең тынчлыгын бозасы килә; аның каршысында бу кадәр баш игән бөтен шәһәргә каршы килеп, аны аяк астымда таптап, аның йоклаган тәннәрен уятып, шыгыр-шыгыр өстеннән үтәсем килә. Минем мәдрәсәдән ясап чыккан начар фикерем, ямьсез уем шул мине кочаклаган матурлык берлә тартыша, сугыша. Үзенең начарлыгы берлә, үзенең былчыраклыгы берлә шул матурлыкны җиңәсе килә; үзенең фикеренең гөнаһлылыгы берлә шул айдан, йолдыздан бүләкләр, сәламнәр китерә торган фәрештәләрне оялтасы килә; ахырдан, шул матурлыкка илтифат итмәенчә, акыртын гына атлап, шул матур күлне аяк астында калдырып, теге тарафка чыгасы килә. Үземнең гөнаһсызлыгымны, үземнең егетлегемне мәңгегә шул ай, йолдызлар берлә зиннәтләнгән күлнең бу тарафында калдырып, үземне үзем теге якның былчырагына чумдырасы, йөздерәсе килә.

Тагы үземне үзем җиңә алмаенча, тагы шул матурлыкка каршы бер хәрәкәт тә итә алмаенча тора идем, күңелемдә зур бер карар килде. Зур иттереп аягымны атладым. Аяк астымдагы карларның шыгыр-шыгыр еглап калуларына илтифат итмәенчә, үземнең кара гәүдәм берлә кара күләгә булып шул ак сөт диңгезе аша атлый башладым вә кара фикерләрем берлә ак кар диңгезен каралта башладым. Йөрәгемнең дөп-дөп тибүен ишетмәс өчен, кызу-кызу атлап ашыга башладым.

Менә каршы тарафтан соңга калган бер барабыз* атын суга-суга миңа

каршы килә башлады. Минем күңелемдә әллә нинди курку, үз-үзенең гаебен белү хисе уянды. Мин күрше бакчадан кыяр урлаганда тотылган бала кеби тетри, калтырый башладым: «Теге мине күрер, мине таныр, фәлән итәр»,— дип, аңар каршы очрамас өчен, икенче юлга борылдым. Күңелемдә тагы өйгә борылып кайту, барасы юлыма бару фикере сугыша башлады. Тагы җиңдем, тагы киттем. Тар урамнар үттем.Әллә нинди тәбәнәк кенә бер өйнең фонарь таккан ишегенә килеп кердем. Бер тар гына бүлмәгә кереп утырып, яныма җыелган әллә никадәр карт вә яшь хатыннарның күзләре берлә мине сөзүләре астында торганның соңында, берсен дә яратмасам да, шул күз караулардан котылыр өчен, үземне үзем калтыравым тетрәвем берлә көлдермәс өчен, берсен алдым. Ишекне бикләп, калтырап тишенеп, тупас кына, дорфа гына карт кына бер хатынны беренче мәртәбә кочакладым.Үземнең сөттән саф егетлегемне, алмастан кыйммәтле яшьлек хатирәмне шул сасы өйдә, сасы хатынның сасы караватында калдырдым. Фикерем кунарга булса да шул минутта бунда куна алмавымны, бунда, түгел куну тагы бер-ике минут тора алмавымны белеп, бик тиз киенеп чыгып киттем.

Тышка чыкканда күңелемдәге моңынча һич күрмәдегем, хис итмәдегем бер хис мине биләгән, әллә нинди бик каты хөкем итә торган хаким мине үзенең мәхкәмәсенә чакырган иде. Мин, нишләргә белмәенчә үземнең кылган эшемнең бик былчырак, бик кабахәт идеке фикереннән аерыла алмаенча, үземне үзем йоларга юл таба алмаенча, үземне үзем коткарырга җавап була алмаенча, сүгә-сүгә мәдрәсәгә борылдым. Тагы баягы минем җинаятемнең шаһите — ап-ак Кабан күле каршыма чыкты. Әллә ничә меңнәр, йөз меңнәр минем кеби кабахәт эш эшләгәннәрне күргән-оныткан Кабан күле минем дә кабахәтлегемне эченә йоткан, минем былчыраклыгымнан да чирканмаган кеби, мине дә эченә йотты. Зур ай да минем кара күңелемне үзенең яктылыгы берлә юа башлады. Мин әллә нинди эч изелүләре берлә атлый-атлый, үземнең теге сасы өй, сасы хатыннан алган хиссиятемне артымда калдырырга тырышкан кеби, ашыга башладым. Үз тарафыма чыгып җиткәч тә, Кабан күленең теге тарафына, аның соңында ак Кабан күленә айга, йолдызларга

карадым. Үземнең бу җинаятемнең шаһитләре алдында аякларым калтырый, тәннәрем тетри башлады. Күземнән ике бөртек яшь мөлдерәде. Егетлегемнең шулай мыскыл булуына, шулкадәр еллар шулкадәр мәшәкатьләр берлә сакланылган сафлыгымның бер минутта чүплек башына ыргытылуына күңелем протест ясый башлады. Мин балалар кеби егларга, үземнең былчырагымны кайнар күз яшьләрем белән юарга тотындым.

*15 нче февраль, 1898 нче ел*

## 59

Әтиләрдән хат килде. Әти каргый, әни еглый. Нишләсәң дә рөхсәт юк: «Әтиең карт, фәлән-төгән, мулла бул», — дип яза. Белмим, ни булыр. Буннан китә алмыйм ахрысы. Әллә нигә анларның сүзләренә каршы килә алмыйм. Бәлки, ничек тә ризаландырып булыр әле! Хәзергә калды.

*28 нче февраль, 1898 нче ел*

## 60

Мин хәзер русча бераз сукалыйм. Гәзитәләрне, ачыграк язылган китапларны аңлыйм. Лөгать китабыны кулдан төшермәенчә, бербуйдан рус китаплары укып утырам. Әллә ниләр хакында укып бетердем. Бал корты асрау хакында, йогышлы авырулардан саклану, бала тәрбия кылу, Бәйтелмөкаддәсне зиярәткә бару, әллә кайдагы телсезләр мәктәбендә укыту, диңгездә баткан бер көймәдән котылган бер кешенең вакыйгалары, матур язу өйрәнү ысулы, байлыкның юлы, тагы, белмим, ниләр-ниләр укыдым. Барысын да аңладым. Әлбәттә, бу зур тәрәкъкый!

*14 нче март, 1898 нче ел*

## 61

Мин беркөн, кайткач, никадәр үземне үзем шелтәләсәм дә, үземнән үзем җирәнсәм дә, әллә ничә көнгә кадәр борынмнан шул сасы бүлмәнең сасы исе чыкмаса да, вөҗдан газабымнан эчемнән көйсәм дә, тагы бардым. Тагы кайткан вакытта үземне үзем үтерәсем килде. Тагы, үземнән үзем качарга теләгән кеби, кайтканда ашыга-ашыга эштән чыктым. Тагы әллә ничә көннәр күңелемнән шул вөҗдан газабы, шундагы сасы исләр чыкмады. Ләкин күңелемне дә әллә нәрсә шул галәмгә зәгыйфь кенә җеп берлә булса да һәрвакыт өстери башлады. Мин, гакылым берлә уйлап, шул галәмгә никадәр дошман булсам да, шул эшләрне никадәр сөймәсәм дә, хисем берлә шунда барудан үземне үзем тыя алмадым. Буннан соң да тыя алырмын дип уйламыйм.

*6 нчы апрель, 1898 нче ел*

## 62

Тагы бер ел мәдрәсәдә мәгънәсез үтте.

*12 нче май, 1899 нчы ел*

## 63

Мин хәзер аз гына русча, аз гына төрекчә, аз гына гарәпчә, фарсыча, аз гына үз телем татарча беләм. Бу телләрнең барсында да, лөгать китаплары берлә, китаплар, рисаләләр аңлый алам. Шуның өстенә, тарихтан аз гына, җәгърафиядән аз гына, хисап, һәндәсәдән аз гына, әллә нинди үләннәр, хайваннар хакында, аз гына өй тәрбия кылу, бала тәрбия кылу, бала укыту, мәктәп идарә кылу хакында, аз гына дин вә игътикад хакында, аз гына тәфсире хәдис хакында, аз гына мантыйк вә хикмәт хакында — кыскасы гына, һәр нәрсә хакында аз гына мәгълүматым бар. Бунларның һәммәсен өсттән генә белсәм дә, берсене дә чынлап белмим. Барсы хакында да сүз сөйли алсам да, берсе хакында ап-ачык мәгълүмат бирә алмыйм. Берсене дә дөрест иттереп укыта алмыйм һәм күз алдымда анлар хакында ап-ачык бер фикер хасил итә алмыйм. Минем фикерем дә мәгълүматым кеби. Аңда да аз гына вөҗдан, аз

гына шәфкать, аз гына эшкә мәхәббәт, аз гына халкын сөю, аз гына үзен корбан кылырга хәзерлек, аз гына шөһрәт сөю, аз гына байлык сөю, аз гына үзен үзе сөю, аз гына тормыш сөю, аз гына ялкаулык, аз гына эш яратмау бар. Шуның өчен минем белмәгән эшем юк, кинәндергән төшем юк! Хәзер инде менә шул мәгълүмат берлә, шул фикер берлә дөньяга чыгарга кирәк. Шунлар берлә дөньяда торырга кирәк. Шунлар берлә тормышны мәгънәле үткәрергә кирәк, тормышның буш йирләрене тутырырга кирәк. Үзеңне, үзеңнең торганыңны белер өчен, үзеңнең соңында тормышта бер эз калдырыр өчен әллә нәрсә тудырырга кирәк. Ләкин бу мәгълүмат, бу фикер берлә чуалган, бер яктан шул мәгълүмат берлә тулган, шул хиссият берлә ашланган баш берлә нинди эш эшләргә кирәк? Ничек иттереп тормышны тулы мәгънәле, картайгач артка әйләнеп караганда: «Үлсәм үләм, гомерем әрәм китмәде»,—диерлек ясарга кирәк? Ничек шул чүп-чардан кулга алырлык бер нәрсә өйдерергә кирәк?

Мин менә шул белемем берлә нигә ярыйм? Нәрсә беләм дип дөньяга чыгып эшкә тотыныйм? Итекчелекне булдыра алмыйм, чөнки мин мулла угылы мәхдүм булып, эш эшләмәенчә үскән. Сатучылык юк, чөнки миндә сатучыга кирәк гайрәт, сатучыга кирәк акча сөю һәм дә алган юлын ташламаенча карлы бозда хезмәт итү юк. Кала мөгаллим булырга, йә мулла булырга! Сөеп, рәхәтләнеп мөгаллим булыр идем; әллә никадәр мәгълүматым булмаса да, бала тәрбия кылу хакында да башымда чүп-чардан башка нәрсә булмаса да, тырышып, сөеп укытыр идем — этиләр, әниләр разый булмый! Мулла булырга күңелем, вөҗданым разый булмый. Мулла булуны үзем өчен, үземнең мәхәлләм өчен зур җинаять дип хисап итәм. Соң нишләргә? Минем кеби бер эшкә дә ярамый торган, һәр эшкә ярый торган кешеләргә нишләргә? Шунда бер урын алган булып тора башлаган булып, тагы үзең кеби эшкә ярамый торган ярым-ярты мәгълүматлы балалар тудырып, шунларны үстерергәме? Бу туачак балаларга каршы һәм дә анларны ашатачак, эчертәчәк бөтен адәм балаларына каршы җинаять түгелме? Менә бу мәсьәләләрнең мин берсенә дә җавап бирә алмадым һәм җавап бирә алуымда шөбһәм бар. Ләкин гомер тик тормый, көн дә көн үтә. Мәсьәләләрне йә алай, йә болай хәл кылу

мәсьәләсе һәр минутта якынлаша.

Мин, хәзер үземнең эти кеби, укыган нәрсәләремә иманым булса, аның кеби, шул, шул укыган китапларындагы «һәммә нәрсә дөрест инде» дигән игътикадым булса, эти кеби, һәр зур мәсьәләгә: «Фәлән китапта шулай дип әйткән, фәләндә болай дип әйткән»,— дип җавап бирә алсам, шуның берлә вөҗданымны котылдыра алсам, үземне үзем чорнап алган мәсьәләләргә һәммәсенә дә үзем ышанган җавапларым булып: «Тәкъдир шулай, әл-әмер әмрелиллаһ»,— дип канәгать итә торган булсам, табигый, рәхәтләнеп-рәхәтләнеп эти кеби мулла булып торыр идем. Яисә мин, шул үземне чолгаган мәсьәләләргә, тормышның алдына көн дә килеп баса торган эшләргә фән күз карашыннан җавап бирерлек фәнни мәгълүматым булса, һәммә нәрсәгә дә фән күзе берлә: «Тарихта шулай булган, болай булган, хәзер дә шул сәбәпләр бар, шулай булырга тиеш, йә сәбәпләре шундыйлар, нәтиҗәдә шулай чыгарга тиеш»,—дия алсам, шул фән үлчәве берлә үземә күз карашлары ясый алсам, рәхәтләнеп бер яңа дөньяның яңа кешесе булып торыр идем. Ләкин миндә әүвәлгесе дә юк, ахыргысы да юк. Һәр нәрсә бар, бер нәрсә юк! Шуның өчен мин — ул да түгел, бу да түгел! Тәвә дә түгел, кош та түгел! Ат та түгел, ишәк тә түгел! Мин — иске мулла гыйлеме, иске мулла фикере берлә яңа фикерләр, яңа гыйлемнәрдән катыштырып начар иттереп ясалган мулла азгын! Менә шул мулла азгын үзенең шул чуалчык башы, чуалчык фикере, начар тәрбиясе берлә нишләсен? Сез дә җавап бирегез?! Бунның шулай калуында үзе генә гаепле ме? Нигә көлеп торасыз?! Бунның шулай, бер элгәреге игътикадын бозып, яңа игьтикадсыз калуында сез дә, аны чолгап алган бөтен татар тормышыгыз да гаепле түгелме?

Искедәге кеби, һәр яңалыкны кертмәс өчен меңәр-меңәр фәрештәләр саклый торган мөдрәсәгез булса, бу егет, бу укырга сөя торган үткен егет, карт муллаларыгыз кеби, динле, игьтикадлы, үз даирәсендә галим булмас идемени? Әгәр мөкәммәл иттереп ислях ителгән мәктәпләремез булса, һәр фәнне кирәгенчә укытылса, яшь башларга кая таба хәрәкәтләнергә юл күрсәтелсә, бу, хәзерге чүпрәк, эшкә ярамый торган егет, һәр нәрсә хакында фәнни фикер

ясап, тормышка каршы гыйлем коралы берлә коралланып, хәзер баһадир кыяфәтендә басып, тормышның буңа куярга теләгән ауларына каршы көлеп тормас идемени? Шулай булса, миннән көлмәңез! Мин еглыйм, сез дә еглаңыз! Минем генә түгел, минем кеби меңнәр-меңнәр егетләреңезнең, ике агым арасында, йомычка кеби, бер тарафка китәргә хәле булмаганыны, бер тарафның да куәтен арттырырга да көче җитмәгәнене — үзенә үзе ышанмаганыны күреп еглаңыз! Шунларга таза, нык аяк басар урын табарга уйлап, шунларны хәзерге хәлләреннән коткарырга теләп еглаңыз! Бунларның харап булган гомерләре өчен, шул әллә никадәр яшьләремезнең харап итәчәк гомерләре өчен егланыз! Үзеңезне чолгаган дөньяызның шул егетнең башы кеби идеке өчен еглаңыз! Еглаңыз!

*15 нче июнь, 1899 нчы ел*

## 64

Ике атнадан бирле өемез тәмугка әверелде. Иртә-кич тавыш, иртә-кич мулла булу мәсьәләсе. Әти мулла булуның кыямәт өчен яхшылыкларын, имамлыкның савапларын; әни мулла булып торуның тынычлыгын, рәхәтлеген, эшсез-нисез тик ятуның кәефлеген сөйләүдән башлады. Миңа, саваплар, тыныч кына бот күтәреп ятулар берлә кызыктыра алмагач, еглап-еглап: «Әтиең картайды, мин картайдым. Без нишлик? Ничек дөнья үткәрик?»—дип зарланырга, ялынырга, аның соңында каргарга тотынды. Әти дә: «Имамлыктан тартыну игътикадның зәгыйфьлеген күрсәтә, синең иманыңда шөбһә бар, имеш, фәлән»,—дип тиргәргә тотынды. Бу гына җитмәде, аңлар-аңламас: «Балам, апкаем, бул инде, бул!» — дип егларга тотындылар. Башым тегермән кеби әйләнә башлады. Нишләргә дә белмәенчә, аптырап калдым. Бу тормыш упкынннан чыгарга юл таба алмадым.

Нишлим? Ничек бунларга сүз аңлатыйм! Ничек үземнең зәгыйфь мәсләгемне көчсез, куәтсез игътикадым берлә саклыйм! Бу тавыштан, бу кычкырыштан, бу мәгънәсез моназарәдән шулкадәр туйдым — бөтен эчем-

тышым буңар протест ясый; бөтен эчем-тышым әллә кайларга, бу тавышлар ишетелми, бу мәгънәсез күз яшьләре күренми торган йирләргә, еракка-еракка китәсе килә! Әй шул бу авылны, бу үзләренең кечкенә даирәләреннән чыга алмый торган этиләр, әниләрне күрмәскә; әй анларның шул тормыш упкынна батырыр өчен ясый торган ауларына кертер өчен сөйли торган матур сүзләрен ишетмәскә, шул упкын янына сибелә торган җимнәрне күрмәскә, белмәскә! Китәргә! Китәргә! Башны алырга да кая булса да китәргә!

Ләкин кая китәргә? Мин нишли алам? Егерме өч яшенә кадәр салам селкетмәгән бер әрәмтамак, әрәмтамак булып бушка ашап ятудан башка ни эшли алам? Кыргыз эченә мөгаллим булып китәргә, Сибириягә приказчик булып китәргә? Ләкин мин шунларны эшли аламмы? Тагы, эшли алсам, шул кыргызның җир өеңдә тары өйрәсе ашап, көпе киеп сасып яту, яисә биш тиен көмеш өчен җанын кызганмый торган бер сатучыга хезмәтче булу — шул авылдагы тормыштан артыкмы? Икесендә дә, бертөрле «ирек»тән мәхрүм калып, гадәткә, йолага, карендәш-кабиләгә, ил-күршегә кол булынмыймыни?

Шулай булса, минем кеби үз ирегең үзе саклый алырлык булмаган кешеләр коллыктан чыга алмаса, әллә кая өйрәнмәгән, белмәгән җирләрдә кол булудан бунда үз йортында, үз тирә-яныңа кол булсаң артык булмасмы? Чынлап караганда, шул авылның наданлыгы, гадәтләре, йолаларының колы булсаң да, ерактан караганда хуҗасы, авылның юлбашчысы кеби күренә торган «кол мулла» булу артык түгелме?

*18 нче сентябрь, 1899 нчы ел*

**65**

Кичә тамга җыйдылар. Күңелем муллалык фикере берлә аз гына оеша алмаса да, үземне үзем мулла итеп уйлый белмәсәм дә, мин мулла булам. Нинди мулла булу, ничек яшәү, ничек хезмәт итү хакында, әлбәттә, аз гына да планнарым юк. Ничек тугры килсә, шулай яшәячәк, тормыш кай тарафка акса, шул якка китәчәкмен!

*19 нчы ноябрь, 1899 нчы ел*

## 66

Кеше өметсез, идеалсыз яши алмый. Чахутка берлә үләргә яткан, үлгәнчә зинданда калырга хөкем ителгән кешеләр дә киләчәкләре тугрысында озын-озын планнар коралар; киләчәктә шулай булыр, болай булыр уйлары, өметләре берлә яшиләр. Мин дә рухан үтерелергә, мәңгегә шул гадәт — йола зинданында калырга хөкем ителгән булсам да, үземнең муллалык тормышымны әллә нинди идеаллар берлә бутыйм, чолгыйм; мулла булып, мәгънәлерәк, тулырак иттереп торуга төшенәм, планнар корам! Мин мәктәп ачарга, мәктәптә рәтләп укытырга, мәчеттә халыкның фикерен ача торганрак вәгазьләр сөйләргә уйлыйм! Шулай итеп, бөтенеләй буш тормаска, әрәмтамак булып гомер әрәм итмәскә юллар табам. Үземнең киләчәк хезмәтләрем өчен сөенәм; киләчәгемдә якты көннәр күреп: «Бетмәдем әле, бетмим әле»,—дип шатланам. Эшлим, шөбһәсез эшлим!

*28 нче декабрь, 1899 нчы ел*

## 67

Мин өйләнәм. Кичә күрше авыл мулласының кызыны килешеп кайттылар. Тормыш мине хәзер кызу-кызу үзенең кочагына ала бара. Мин мулла булып бетмәгән, хатынлы булдым. Гомеремдә күрмәгән, ишетмәгән, белмәгән бер кызны үземә гомерлеккә иптәшкә алам.

Шуның берлә бергә гомер үткәрергә, шуның берлә кайгыларның ачысын бергә татырга, тормышның матурлыкларыннан бергә сөенергә, шатланышырга сүз бирәм. Мин бу кызны сөячәкме? Мин анын табигатен, холкын яратачакмы? Ул мине аңлаячак, мине сөячәкме? Минем өйләнү хакында фикерем ни иде соң? Мин элгәре өйләнүне кешеләрнең тормышының иң мокаддәс бер бәйрәме иттереп уйлый идем. Өйләнүдән элек озын-озак, матур иттереп сөюне, сөелүне, сөешүне иң зур шарт иттереп исәпли идем.

Үземнең өйләнүемне һәрвакыт мәгънәле күз караулары, хатлар берлә башланышып, качышып күрешүләр, eрактан сөешүләр, бергә кушылыр өчен әллә нинди каршы килә торган куәтләр берлә тартышулар, озын-озын тартышудан соң җиңүләр вә шул мәшәкатьләр аркасында кыйммәте тагы арткан сөю вә сөешүнең мөкаддәслекләре вә сөелешүнең ләззәтенең куәтләре, вә шул кушылуның мәңгелек бер рухани кушылу булуын уйлый идем; шулай булуына инана идем; шулай булачак дип, киләчәк өчен шатлана, сөенә идем.

Менә ул «киләчәк» «хәзер»гә әверелде. Аның бөтен матурлыклары, миңа әллә никадәр ләззәт биргән, әллә никадәр дәрт биргән кызыклыклары һәммәсе берьюлы җимерелде. Хәзер туп-тугры иттереп жаучы җибәреп, акча салдырып, бирнә алып, белмәгән, күрмәгән, аңламаган, сөймәгән бер кыз килә; аңлатылмаган, күрелмәгән, сөелмәгән фәлән авылның мулласы угылы, мулла булачак егете булып өйләнәм, идеалымның иң зур бер баскычын җимерәм!

*7 нче гыйнвар, 1900 нче ел*

**68**

Туй булды. Мин кыз катына кердем. Туйның шартларыннан һичберсе калдырылмады. Мин, гадәт буенча, балдызлар, каен энеләргә пәкеләр, кершәннәр, сабыннар, көзгеләр; кодача-кодагыйлар, каенаталар, каенаналарга бүләкләр; мунчага салырга, ишек тоткасына бирергә бүләкләрнең берсен дә онытмадым. Анда да һәркөнне ике мәртәбә ягыла торган мунчага баруны да, намаз укыган кеби, бер тәртип берлә үтәдем. Бикәчемә дә тиешле бүләкләрне бирдем. Гадәттә ничек кыланырга тиеш, һәммәсен кылдым.

Бикәчем шактый гына матур, яшь кенә, пөхтә генә, гакыллы гына бер кыз. Табигатьләре-ниләре дә, һәммәсе дә яраталмаслык түгел. Миңа мөнәсәбәтләрендә дә риза булмаслык бернәрсә юк. Матур сөйли, ачык көлә, күңелләрне хәрәкәтләндерә торган иттереп йөри, сөелергә, сөешергә ярата. Табигый, уйнадык, көлдек, дустлаштык, сөйләштек, серләштек, сөештек..

Ләкин һәрвакыт арамызда бер аңлашылмаган нәрсә — яшерен бер куәт хис иттек. Бер-беремезгә сарылышып, бөтен эчләремезне актарып салмадык. Сөйләшкәндә, көлешкәндә, сөешкәндә вазыйфа үтәгән кебирәк кылыныштык. Күңелләремездән әллә нинди бер-беремезгә ышанмауны бетерә алмадык. Бер-беремезне онытып, икемез бер кеше кеби кылыныша, икемез бер кеше кеби бер хис берлә яна алмадык. Арамыздагы икемезнең дә эчен пошыра торган, икемезнең күңелен рәнҗетә торган бер суыклыктан котыла алмадык. Шуның өстенә, ул да, мин дә, шул суыклыкны икенчемезгә аңлатмас өчен, әллә нинди хәйләләр, алдаулар корып, аны тагы ямьсезрәк иттереп мәйданга чыгардык.

Мин киткәндә, бик сөешеп, тизрәк килергә вәгъдәләшеп аерылыштык. Ләкин теге хис һаман бетмәде. Мин кайткан вакытта, кыңгырау тавышының моңлыгы берлә уйлый-уйлый, ул хиснең нәрсә икәнлегене аңладым. Без, сөешсәк тә, дустланышсак та, эч күңелемездән бер-беремезне сөймимез икән! Бу хәкыйкать минем күңелемә агулы очлы ук кеби барып утырып, тагы бер зур җәрәхәт ачты. Минем идеалымның тагы иң зур почмагын җимерде. Тормышымның тулы төсле күренә торган йирләренең дә буп-буш икәнлеген күрсәтте. Мин моң кыңгырау тавышлары берлә күземне йомып, уйларга тотындым. Күзләремнән ике түгәрәк күз яшьләре мөлдерәп, битемне юып, кулыма төште. Күңелемдә «бетте» дигән фикер туды. Бетте! Һәммәсе бетте! Бөтен идеал, бөтен тормыш бетте! Мәңгелеккә кайтмаска бетте!

*12 нче февраль, 1900 нче ел*

## 69

Кичә ясигъдан соң авылның могътәбәр картларыннан, безнең өйнең дустларыннан Әхмәт абзый кереп утырды. Аның керүе һичбер вакыт бушка булмаган кеби, бу юлы да бушка түгел иде. Ул, авылның бөтен кешесенең нинди уйда, нинди фикердә икәнен белгән кеби, иртәгә нинди уйда булачагын, мәгълүм эшкә нинди күз берлә караячагын да —һәммәсен дә белә. Авыл ирләренең генә түгел, хатыннарының нинди фикердәлекләрене, ил эшләреннән нәрсәне яратуларыны, нәрсәне сөймәүләрне һәммәсен белә.

Шуның өчен ул безнең авылның уеның, теләвенең көзгесе.

Шул авыл көзгесе, бик күп чынаяклар чәй эчкәч, бик күп сүзләр сөйләгәч, мине дә яшь мулла дип бик мактагач:

— Авыл халкымыз да ярата-фәлән итә, ләкин менә әле, көз көне мәдрәсәне тау астыннан күчертергә тели икән, аннан ары, Суфи абзыйны кертмәенчә, әллә кайдан мөгаллим китертергә тели икән, дип яратмаенчарак сөйлиләр. Кайсыберсе: «Хәзрәт исән булганда, Алла теләсә, бернәрсә булмас», дип берсен берсе бастырышсалар да, кайсылары: «Юк, болай ярамый, бик тиз әле баш булырга тели, атасы укыткан ярамаганмы? Менә, Аллага шөкер, барымыз да шуның шәкерте, Аллага шөкер, кирәгемез кадәр беләмез бит», дип әйтәләр, ди.— Шуның артыннан үз башыннан чыгарып:—Минемчә, бу елга шулай калдырырга кирәк. Әле менә, яңа мулла дип, йир дә бирелгәне юк. Анысы да кирәк бит, хәзрәт? Анлары үтсен әле. Бик яхшы гына йир алыйк. Бу елга син әле кыз катына йөре, аннан ары киләсе елга карарсың. Бик кызулап җибәреп, халыкны дулатып җибәрмик димен. Без бит мужик халкы, бер кызсак, сыер дулаган кеби буламыз,—дип сүзен бетерде.

Әти дә, миңа карап:

— Менә мин күптән әйттем бит, мине тыңламый идең,— диде.

Әни дә ишек артыннан гына:

— Кирәкмәс, зинһар, мәдрәсәләре. Үзләре теләсәләр нишләсеннәр, тавыш чыгармаңыз. Йә ары якка мәсҗед сала башларлар,—диде.

Мин үземнең әүвәл мәктәп төзетеп, шул мәктәптә укытып буш гомеремне тутыра алмавыма, ул яктан да алдануыма ияләшеп бетә алмадым. Әхмәт абзый тагы бер-ике чынаяк чәйдән соң:

— Яшь мулланың вәгазьләрен бик яраталар, ләкин китап сүзе азрак диләр. Шуның өчен, мулла, син китап сүзен күбрәк ычкындыргаласаң, тагы яхшырак булыр, — диде.

Анның өстенә әти дә:

— Мин һәрвакыт «Дөррәтеннасыйхин», «Тәрбиятел-гафилин» кеби мәгъруф китаплардан сөйлә, дим. Ул, әллә каплардан тапкан үзенең

китапларыннан сөйли,— дип, сүзен бетерә алмады, әни: — Китап булгач барыбер түгелме? Бик яхшы сөйли диләр ич!—диде.

Әхмәт абзый анар каршы:

— Яхшысын яхшы, абыстай, ләкин әле кара халык - кара сарык диләр бит. Анлар берлә яшәргә кирәк бит. Шуның өчен әле яна вакытта анлар теләгәнчәрәк кылынрга кирәк димез,—диде.

Әти дә шул фикер хакында озын сүзләр сөйләде, дәлилләр китерде. Ләкин мин бунларның берсен дә тыңламадым да, каршы жавап та бирмәдем, һәм җавап бирергә урын да юк! Бу сүзләр минем тагы бер кат алданганымны беркетте, авылда бер-бер эш эшләүдән бөтен өметемне өзде, хезмәт итәргә дәртемне бетерде. Мин, бөтен өметләрдән яп-ялангач көенчә калып, игьтикадсыз, имансыз яшәргә, яшәргә дә түгел, гомер үткәрергә мәҗбүр идекемне белдем. Башымда буңар каршы бик зур протест уянса да, күңелем эченнән еглаудан башка бер эшкә тотына алмады, үземне үзем коткарырга бер юл булмады. Мин иртә берлә бернәрсә дә уйламаенча, мин аны сөйми, ул мине сөйми торган авылдан ул мине сөйми, мин аны сөйми торган бикәчемә киттем.

*15 нче март, 1900 нче ел*

## 70

Мин, зинданга ябылган кеше кеби, үземнең яшьлек гайрәтемне кая куярга белмәенчә, эчемне кайната торган гайрәт көчен бастырыр өчен, үземне үзем арытыр өчен иртәдән кичкә кадәр идән буенда йөрим. Уйланам, уйлыйм. Әллә ничәшәр катлы «иске гадәт» диварлары берлә чолганган, үземнең мәгънәви зиндандагы тормышымны төшенәм; шуның богауларын өзәргә, үземне үзем азат итәргә юллар ззлим. Буннан качып китәргә, кая булса да китәргә уйлыйм. Ләкин тагы күз алдыма әллә нинди киләчәкнең ямьсез күренешләре килеп басып, мине куркыта. Мин үзем дә, шул «гадәт» богауларын өзәргә көч юклыгын хис итеп, язмышка риза булып, шул тормышны мәгънәләтә төшүдән башка юл габа алмыйм. Ләкин ничек мәгьнәләтим? Үзем ышанмасам да, ичмасам үземне азрак алдарлык эш кайдан

табыйм? Мәдрәсәгә керимме? Ләкин анда кереп, ничек оялмаенча «Төхфәтелмөлек», «Мораделгарифин» укытып торыйм? Мәсҗедкә барыйммы? Анда барып, тагы ничек иттереп, «Дөррелмәҗалис»тән хур кызларының матурлыгы хакында, канәгать кылу тиешлегендә үзем зарарлы дип ышанган сүзләрне сөйлим! Соң, нишлим? Бу озын кышкы төнне ничек үткәрим! Бу үгез йөреше берлә йөри торган төнге сәгатьләрне ничек уздырыйм?

*19 нчы декабрь, 1900 нче ел*

## 71

Кышкы төнне үткәрә-үткәрә арып бетеп эштән чыккач, өстемә киенеп йортка чыктым. Бераз һава алыйм дип, йорт буенда йөрергә тотындым. Суык һавада башым сафланып, күңелем куәтләнеп, тагы үземнең эшсезлегемә кайгыра башладым. Башым тагы әллә ниләр төшенә башлады. Шулай уйланып, моңланып йөргәндә, лапас астында аз гына ялтырый торган хезмәтче өенең утына күзем төште. Шул өйнең эчендә әллә никадәр рухани җылылык бар кеби, әллә никадәр рәхәт бар кеби тоелды. Мин шуның тәрәзәсе тугрысына туктап, кырыйлары ачык калган пәрдә ярыкларыннан өйнең эчен карый башладым. Сәкенең янына утырып тегү тегә торган хезмәтче хатынны күрү минем күңелемә әллә нинди уйлар уятты. Минем күңелемдә шул ят хатын берлә сөйләшәсе килү, шуның берлә бергә кичнең үтмәгән сәгатьләрен үткәрәсе килү, үземнең шул берсенә берсе охшаган көннәремне үзгәртәсе килү фикере туды. Мин акыртын гына лапас астына кереп, хезмәтченең бозлар берлә каткан ишеген куәт берлә ачып, өйгә кердем. Хезмәтче хатын миннән качмаса да, минем берлә эш тугрысында сөйләшсә дә, минем төнлә килеп керүемә исе китеп калган кеби булып, башындагы арттан бәйләгән яулыгын тишеп, муен астыннан бәйләде. Үзе бер сүз әйтмәенчә, минем бер-бер йомышымны көтеп торган кеби көтә башлады. Мин: «Йортка чыккан идем дә, эч пошканга сөйләшеп утырырга дип кенә кердем»,—дигәч, тегенең бөтен йөзенә тагы таң калу галәмәте чыкты. Мин, бер дә илтифат кылмаган булып,

узып утырып: «Күңелсез, эч поша»,—дип зарланырга тотындым. Теге хатын аз гына ачыла башлагач: «Миңнулла кая?» —дип, иренең каялыгы хакында сорадым. Ул да: «Иген төяп базарга китте»,—диде һәм дә, аптыраганын бетерер өчен кеби: «Ул булса, менә мин самавыр куяр идем, чәй эчерер идек. Хәзер яхшы түгел, йә берсе-берсе күрер»,—диде. Бу «берсе-берсе күрер» сүзе миндә икенче уй уятты. Чын, берсе-берсе күрмәсә, буның берлә төн үткәреп, шул берсенә берсе охшаган мәгънәсез тормышны үзгәләштерсәң ни булыр иде?

Шул фикер башымда бер карар алып җитә алмады, мин: «Шәйтан күрсенме, һәммә кеше йоклый»,—дидем. Хатын сөальле иттереп самавырга карады. Мин көлеп җавап биргәч, куыштан ярып куйган чыралардан бер зур уч алып, урталай шатырдатып сындырып, самавыр куя башлады. Самавырны куеп, урынына утырыр өчен минем янымнан үтеп барганда, мин кулыннан тоттым. Хатын әллә нинди тәрәддед аңлата торган бер хис берлә: «Кирәкмәс, мулла абзый, кирәкмәс!» — диде һәм дә, мине шул фикердән кайтарыр өчен кеби: «Бер-бер кеше күрер»,— диде. Мин бу сүздән тагы бик күп мәгънә аңлап, хатынны тәмам кочаклап янымa утырттым. Хатын, оялганга, башын теге тарафка борды. Минем кулларым берлә бөтен тәннәрендә кылган сәяхәтемә бер сүз әйтмәсә дә, күземә таба борылып карамады. Мин буның оялганыны белеп, ерак түгел лампаны өреп сүндердем. Хәзер өйнең тынчлыгын самавырның челтәрләреннән чыккан яктыга башка бернәрсә дә бозмый иде. Мин хатынны кочаклап урынына яткыра башладым. Ул да, азрак тартынган кеби, азрак риза түгел кеби иттереп, «кирәкмәс лә» дип, артык бер сүз дә әйтмәде.

Самавырның кайнавына да карамаеңча, түшәгенең катылыгына, урынның уңайсызлыгына да илтифат итмәенчә, мин кичне хезмәтче хатын янында үткәрдем.

Иртә берлә хезмәтче хатын миңа очраганда күзен миңа таба күтәреп карый алмаса да, өч көннән, соң ире урыска киткәч, тагы кереп кичнең күп вакытыны үткәрдем. Хәзер шул эш минем тормышымның программасына

кереп китте. Ләкин бу да туйдыра башлады, бу да тормышымның буш җирләрен тутыра алмады.

*8 нче гыйнвар, 1901 нче ел*

## 72

Менә мә! Кичә волостной судтан хөкемгә чакырып кәгазь китерделәр. Авылның ике тиенелек бер кешесе, мулланың бозавы ындырыма кереп кибәгемне ашады, дип өстемнән күрсәткән. Бундан элгәре ике күрше хатын, тавык йомыркасы өчен орышышкан вакытларында берсе берсен мыскыл итте дип, мине шаһит итеп хөкемгә биргәннәр иде. Улсында алдап-йолдап бер йомырка низагысының шаһиды булудан котылган идем. Бунсыннан, белмим, котылырмынмы? Бар, сөйлә! Шунлар берлә бер йомырка өчен, бер тубал кибәк өчен, биш тиен акча өчен судлашып йөре! Шуның өчен дуст бул, дошман бул! Орышыш, кычкырыш, хөкемләш! Менә шул кешеләр берлә чолган да, шул тормышта яшә! Мин шул йомырка өчен, бер тубал кибәк өчен, бер кочак салам өчен, биш-алты кисәк утын өчен дустлата, бозылыша, сүгешә, сугыша торган кешеләр дәрәҗәсенә төштеммени? Минем тормышым да шундый вак мәсьәләләр берлә тулыр, минем башым да шунлар берлә мәшгуль булырмыни? Мин дә шулкадәр вакландым, изелдем, беттеммени?

*9 нчы апрель, 1901 нче ел*

## 73

Күрше Сафа абзыйның яшь килене, Миңнесафа, һәрвакыт безгә кереп-китеп йөргәндә тәрәзәгә күзенең очы берлә карап үткәнгә, мин, йортта тугры килгәндә дә күземез каршы-каршыга очрашып киткәнгә, бу хатын хакында төрле фикерләрем бар иде. Хосусән, аның көязлеге, шактый пөхтә киеме өстенә, чибәрлеге, сынның килешлеге күңелемә дә бераз тәэсир итә иде. Алай булса да, аның артыннан йөрми, аны кулга төшерер өчен бер-бер эшкә керешми идем. Беркөн, хатыным ашта вакытта, мин ялгыз идән буенда

аптырап йөри идем, бүлмә ишеге ачылды. Мин, мәче-фәләндер дип, илтифатсыз гына бүлмәгә чыктым. Ни күзем берлә күрим, Миңнесафа басып тора! Мине күрү берлә: «Абыстай өйдә юкмыни? Иләк сорый идем»,—диде. Мин дә: «Әнә шунда чоланда, ал»,—дидем. Ул да, ишекне рәтләп япмаенча гына, чоланның ишеген «чыгыр» иттереп, караңгы чоланның шүрлегендә шатыр-шотыр әйберләр шотырдатып, иләк эзли башлады. Аның килеп алдыма басуы ук теге фикеремне уятканга, мин, буның таба алмавын хәйлә иткән булып: «Таба алмыйсыңмыни?»— дип, чоланга иләк эзләшергә кергән булып, киленне тоттым. Ул тотуымда «әһик» дип көлеп, чоланның теге тарафына киткәч, мин, тагы гайрәт җыеп, кочаклап алдым. Килен минем берлә тартышкан кеби тыпырчына, селкенә башлады. Ләкин кулымнан котылырга аз гына көч тә сарыф итмәде. Мин, аның таза биленнән кочаклап, өйгә алып керә башладым. Ул, әллә нидән курыккан кеби: «Кеше күрә, валлаһи, кеше күрә»,— диде дә тыпырчына башлады һәм дә бик тиз минем кулымнан котылып, кыр кәҗәсе кеби сикереп, ишек янына барып басып, миңа бармак селкеп чыгып китте.

Шуннан бирле ул хәзер, һәр көн кеби, минем хатын китте исә — керә, элгәреге кеби тыпырчынмый, тиресләнми!

*24 нче июнь, 1901 нче ел*

**74**

Мин икенче ел мулла булып торам. Язарга эш булмаганга, тормышта үзгәрү булмаганга, күптән бирле бернәрсә язмадым. Нәрсә языйм? Нәрсә бар?

*28 нче июль, 1902 нче ел*

**75**

Ыж-ыж итеп сызгырып, тәрәзә капкачларын шакылдата, morҗалардан кереп, озын иттереп сузып, моңлы, куркынычлы улый, тәрәзәнең элгечләренә килеп бәрелеп, анларны чат-чот шалтырата торган кышкы йилнең тавышына уянып киттем. Йилнең ыж иттереп ячулы сызгырулары, көтмәгәннән тәрәзә

капкачларының дөберт-дөберт итеп барабанлап куюлары, кинәттән генә моржага кергән йилнең моңлы, кайгылы көй берлә уу-уу дип, авыру кеше кеби, җәрәхәтләнгән ерткыч хайван кеби еглавы бөтен тамырларымнан йөреп чыкты. Әллә нинди куркынчлы уйлар уятты, башымда ямьсез төшенмәләр тудырды. Үземнең каялыгымны хәтеремә китермәенчә, үземне чолгаган өйләр, авыллар, кешеләрдән, җәмәгатьләрем-хатыннарымнан аерып, яп-ялангач кеби иттереп, шул куркынчның алдына китереп бастырды. Мин шул куркынчлы ыжылдый торган тавышлар, шул, бөтен дөньяны туңдырам дигән кеби, өйләрне, агачларны, авылларны каплаган кар арасында, һәрнәрсәдән аерылган, һәр ярдәмчедән мәхрүм булган көенчә, үземне үзем япа-ялгыз күрдем. Үземне үзем шул куркынчлы йилләр, шул мәрхәмәтсез суыклар, шул котны ала торган ялгызлыклардан саклар өчен, үземне үзем шул һәлакәттән коткарыр өчен, үземне үзем үземнең эчке җылыларым берлә җылыта, үземне үзем үземнең эшләрем берлә каплый, чолгый, шунлар берлә юата башладым. Гүя күңелемә үзем мөрәҗәгать иткән кеби: «Күңел! Тор! Күрәмсең, нинди ямьсез куркынычлы җилләр каплады? Күрәмсең, мине нинди котны ала торган, тәмугларны хәтергә китерә торган суыклар чормады? Күрәмсең, мине ничек куркыныч галәмдә ялгызлык биләде? Уян, күңел! Үзеңнең дөньяларны җиңә торган, тауларны тишә торган, диңгезләрне корыта торган, тарихларның көпчәкләрен теләгән тарафка әйләндерә торган көчеңне, гайрәтеңне сарыф кыл да, мине шул куркыныч диңгездән коткар! Уян, күңел, уян! Үзеңнең Сибирия суыкларыны эретә торган, каткан-кипкән кальбләрне майга әйләндерә торган, бөтен дөньяның бөтен эшләрен изгегә сөйри торган, бөтен дөньяның матурлыкларын үзеңнең йомшак матурлыгың берлә бизи торган сөю хисен уят та, мине шуның җылысы берлә җылыт! Мине шул биек мәхәббәт сараеннан алынган кечкенә генә, иске генә бер кием берлә өрет! Уян, күңел, уян! Шул меңәр-миллионнар адәмнәр берлә тулган, меңнәр-миллионнар фикерләр берлә кайнаган, меңнәр-миллионнар мәсләкләр берлә чолганган кешеләр диңгезендә уйсыз, фикерсез, мәсләксез, идеалсыз, ялгыз калган мине дә кечкенә бер идеал, иске бер мәсләк берлә булса да иптәш яса

да, мине дә шул ялгызлык, шул моңлык, шул мәгънәсезлектән коткар! Уян, баш, уян! Шул эшсезлектән селкенергә өйрәнмәгән, хәрәкәтләнергә оныткан миләреңне селкет тә, мине дә шул бушлык, тормышның шул мәгънәсезлегеннән коткар! Мине дә «мин» дип әйтерлек, «мин» дип телгә алырлык яса!

Бу сүзләр, бу уйларга каршы чыдый алмаенча, башым да, күңелем дә уянган кеби булды. Анлар да күңелемнең катлы-катлы амбарларыннан, башымның бормалы-бормалы, керделе-чыктылы чокырларыннан мине сакларга, мине җылытырга, мине «мин» иттерергә хәзерләнергә тотындылар. Күңелем яшьлегемнән бу көнгә кадәр үткән тормышымның кәгазьләрен берәм-берәм ача башлады. Менә мин — яшь, матур, маңкалы, таза-нык, ыштансыз, укырга дәртле, хикәя сөюче малай! Менә мин— мәдрәсәдә «дараба ядрибу, нәсара янсару» сарыфлый торган, каты икмәк берлә чәй эчә торган вә шул мәдрәсәдәге хәлфәләр кеби хәлфә булуны, эти кеби мулла булуны, пәйгамбәр кеби яхшы булуны идеал иткән бер шәкерт! Менә мин — мәдрәсәдән мәдрәсәгә барып, моназарә кылышып, «вөҗүд-важибләр, хөдүс-галәмләр, гадәм-заманлар»ны исбат кылып йөрүче, бөтен мәшһүр Кышкар, Казан моназирләре кеби булырга тырышучы, динле, суфый, эчми-тартмый тырыша торган кара бүрекле, озын чалбарлы, дәһри Казан шәкерте!

Менә мин — бу китаплар, бу моназарәләр, бу тәртипсез укуларның дошманы, мәдрәсәләр, мәктәпләр исляхының тарафдары, гәзитә укучы, төрек китаплары укучы, җәй көннәре русча укучы, киләчәктә бөтен халыкның фикерен үзгәртүне төшенүче яшь шәкерт, фикерле егет! Менә мин — әллә нинди ялгыш-йолгыш аңлаган фикерләрем берлә Аурупаның тормышына гашыйк булган, аурупаланыр өчен актык биш тәңкәсенә пальтә алган, бурычка алган акчасына исле майлар, кершәннәр алган, үзен француз романнарының каһарманы иттереп хисап иткән бер Дон Кихот! Менә мин — башымдагы фикерләр берлә тирә-янымны чолгап алган дөньяның аерым-аерым идекләрен аңлаучы, минем идеалымның дөньяда юклыгын күреп кайгыручы вә шул идеал дөньямны тудырыр өчен, тирә-янымны шул идеал

дөньяма әверер өчен тырышырга юл таба алмаучы ярты өметле, ярты өметсез бер яшь егет! Менә мин — үземнең җиңүемә шөбһә иткән, үземнең фикеремне мәйданга китерә алуыма шикләнгән, үземнең мәгълүб булуыма ышанып, игътикадым-иманымнан мәхрүм калган, тормыш сугышына кергәнче җиңелгән бер гаскәр! Менә мин —шул иске тормышка әсир алынган, аның кергән саен чыга алмаска иттереп ябыла торган унике ишекле зинданына куелган өметсез, имансыз бер имам! Менә мин — сөймәгән, сөелмәгән бер хатын берлә гомеремне үткәрергә, сөю-сөешү нәрсә икәнене белмәенчә, яшьлегемне уздырырга, картлыгыма кадәр былчырак хезмәтче хатыннар, әдәпсез күрше киленнәре берлә күңелне мыскыл итә, вөҗданны газаплый торган мөнәсәбәтләрдә яшәүче, йомыркалар, кибәкләр, утыннар, саламнар, чүпрәкләр өчен судлашучы кеше калдыгы!

Менә мин — хәзер шул суык көндә, шул ыжгырдый торган йиддә, шул хатыным берлә бер түшәккә яткан өйдә, үткән гомеремдә бер нәрсә эшләмәгән, киләчәгемдә эшләргә идеалыны, иманыны югалткан, күрше хатыннары берлә маташудан башка эшкә ярамый торган бер адәм калдыгы! Менә мин — шул үземнең тормышымның начарлыгыны уйлап та, аңлап та, үземне үзем шул начарлыктан, шул баткаклыктан чыгара алмаган көчсез, хәлсез бер әрәмтамак.

Әнә минем киләчәгем! Зур корсаклы, көненә ун бәлеш төбе ашый торган, күрше хатыннары, асраулар берлә маташа, былчырана торган мин! Әнә мужиклар берлә юк нәрсәләр өчен ялган шәһитләр яллап-яллап хөкемнәргә йөрүче мин! Әнә мужик хатыннары берлә каз бәпкәләре өчен орышышучы мин! Әнә тагы мин! Әнә тагы мин!

Тышкы йилнең ышылдавына минем күңелемнең ыжгылдавы, аның суыклыгына минем күңелемнең суыклыгы кушылды. Мин эчтән-тыштан туңа, калтырый, дерелди башладым. Үткән гомеремнең, үтәчәк гомеремнең начарлыгы өчен кайгырырга, егларга, шул беткән идеалымны озатырга, бәхилләшергә бер тамчы кайнар яшь таба алмадым. Мин туңдым, мин каттым, мин беттем!

*21 нче декабрь, 1902 нче ел*

Әллә кайда яшеренеп яткан шул кәгазьләрне кичә, өй юар өчен җыештырганда табып алдым. Башыннан ахырына кадәр укып чыктым.

Тагы иске тормышлар күз алдымнан үтте. Тагы бунлар минем йоклаган йөрәгемдә зур бер җәрәхәт ачты. Мин төн буе йоклый алмаенча уйладым. Үземнең нишләгәнемне, нишләвемне, нишләячәгемне төшендем! Бик озак уйлаган, төшенгәннең соңында күңелемә: «Шулмы гомер? Тормышмы бу?» — дигән сөаль килде.

Шул «Тормышмы бу?» сөале, үлгән кешенең өрәге кеби, алдыма килеп басты! Мин җавап бирә алмадым. Сездән сорыйм: «Тормышмы бу?»

*3 нче май, 1908 нче ел*

**Искәрмәләр һәм аңлатмалар:**

*Монзарә* — сүз көрәштерү, бәхәсләшү.

*Җамид* — туң, надан.

*Зөмрүд* — зөбәрҗәт,яшел төстәге асылташ.

*Вакыйган да* — чыннан да.

*Мәгълүб булу* — җиңел.

*Низам* — куелган тәртип.

Вәлбәгъсу бәгъдәл мәүти хак — үлгәннән соң.

*Хали* —буш.

*Истинса кылу* — аеру.

*Тарызы* — рәвеше.

*Низам* - *интизар* — тәртип – кагыйдә.

*Әләмрү лиллаһи* —хөкем Алла кулында.

*Харита* — географик карта.

*Зикер* — искә алу догасы

*Сәер итү* — карау, күзәтү.

*Гизле* —яшерен, аулак.

*Хасыйле* — кыскасы.

*Мөштәрәк* — уртак.

*Газизелвөҗүд вә кәсирелсөҗүд* — газиз булган һәм күп сәҗдә кылган.

*Бәгъденә* — соңында.

*Бәни бәшәр* — адәм балалары, кешелек дөньясы.

*Дүлә* — грушаның вак төре.

*Гайре ниһайә* — чиксез күп, чиктән тыш.

*Угърашу* — очрашу.

*Рәвафыйзлар* — динсезләр, мәҗүсиләр.

*Рәдде нәсари* — христиан динен кире кагу.

*Күкфараз* — купорос.

*Тасдикъ* — раслау, дөреслеген тану

*Хөдүсе галим* — галәмнең барлыкка килүе.

*Көтүбе сәләф* —борынгы китаплар.

*Хәмият* — башкаларның зарар китерүеннән саклау.

*Хосусән* — бигрәк тә.

*Тәрәккъкый* — үсеш, алга китеш.

*Сәләфләр* — борынгы, үткән замандагы кешеләр.

*Тәрәккъкый пәрвәр* — алга китү яклы кеше, прогресс сөюче.

*Мәсгуд* — бәхетле.

*Игътикад* — ышану.

*Тәгъзыйм* — олылау, хөрмәтләү.

*Дин токтаи нәзарыннан* — дини караштан  (күзлектән)

*Вазыйфә* — хезмәт хакы.

* *Барабыз* — кыш көннәрендә өяздән килеп шәһәрдә йөри торган прастуй чаналы ящик . ( Г. Исхакый искәртмәсе)

*Ригайә кылу* — хөрмәтләү.

*Мәхкәмә* —хөкем йорты.

*Лөгать*— сүзлек.

*Лөгать китаплары* — сүзлекләр.

*Рисалә* — кече күләмле әсәрләр, очерк, брошюра.

*Һәндәсә* — геометрия.

*Мантыйк* — логика.

*Хикмәт* —фәлсәфә.

*Әл – әмер әмрелиллаһ —әмер иясе Алланың әмере.*

*Ихляс* — яраштыру, үзгәртү, яхшыландыру.

*Мәгъруф* — билгеле, танылган. *Тәрәддед* — икеләнү, бер карарга киләлми тору.

*Кальб* — күңел

*Дараба ядрибу, нәсара янсару* —гарәп телендәге фигыль үзгәреше формалары .

*Вөҗүд-ваҗибләр, хөдүс-галәмнәр, гадәм-заманалар* – мөселман фәлсәфәсендәге терминнар.

*Мәгүлүб* —җиңелгән.

*Иттихад, иттифак* — берләшү.

*Хәмияте миллия* — милләтне саклау.

*Биззарур* — кирәк булганга.

*Дәреҗ итү* — урынлаштыру.

*Косур* — кимчелек, җитешмәгәнлек.

*Билфигыль* — чынлыкта.

*Шөрәкясе* — иптәшләре.

*Мәҗмугаи асар* — әсәрләр җыентыгы.

*Җилд* — том.

*Мөфассал* — җентекле.

*Табгъ ителү*— басылу.

*Маһирәт* — осталык.

*Һөҗү*— сатира.

*Билгакес* — киресенчә.

*Инкыйлаб* — үзгәрешләр.

*Сәнаигы нәфисә* — матур сәнгать.

*Хилаф* — зарарлы.

*Шәһвани* — җенси.

*Вәлиләр* — изгеләр.

*Мәфһум* — эчтәлек.

*Сәнгате мәһарәт* — сәнгатьтә осталык, сәләт.

*Тәшәккер итү*— рәхмәт әйтү.

*Икътидар* — көч,куәт.

*Мотлакан* — һичшиксез.

*Камаләт* —җитешкәнлек, өлгергәнлек.

*Мөхиб* — сөюче, яратучы

**«Тормышмы бу?»** — Повесть беренче тапкыр Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» наширлегендә И.Н.Харитонов типографиясендә 1911 елда басылып чыга. «Мөхәммәдгаяз әл-Исхакый мәҗмугам асаре» сигезтомлыгында 1 нче җилд, 2 нче китап. 103 бит. Әсәр Истанбулда язылган. Тышлыкта: «Роман. Язылган 1909. Беренче табгы» диелгән. Титул биттә: «Йосыф әфәнде Акчура җәнабләре тарафыннан язылмыш мөхәррирнең мөфассал тәрҗемәи хәле, рәсеме вә кульзмасы илә табгъ ителде» диелсә дә, китапта андый материал басылмый калган.

Әсәрнең апрель аенда ук чыгуы мәгълүм. («Йолдыз» гәзитәсенең 1911 ел, 17 апрель санында китапның басылып чыгуы турында хәбәр бар.)

Газиз Гобәйдуллин әсәргә язган рецензиясендә болай ди: «Тормышмы бу?» исемендәге китабында шәкерт-мөхәррир үзенең «Кыямәт»тәге маһирәтен янә күрсәтте. Ләкин бу мәңгелек комедиясендә Гаяз әфәнденең аһәңе көлкеле, һөҗүле булса, бу китабына, билгакес, авыр аһәң биргән. Шагыйрь Гаяз әфәнде үзенең куәтенең канатларын җәйгән дә, «Теләнче кыз»ындагы шикелле тормышның авыр, кайгылы урыннарын тасвир иткән. Без татарның әдәбиятымызны ярата торган, язу таный торган сыйныф — күбемез шәкерт

булган, күбемез каһарман чиккән газапларны, рухани инкыйлабларны, реакцияләрне — һәммәсен дә күргән, чиккән. Шуңарга күрә бу без «шәкерт сыйнфы» өчен бик кадерле, бик ачык булган бер әсәр... Бәлки бу әсәрне сүгәрләр, бәлки бу әсәрне бик күңелле дип мактарлар да, сәбәп итеп бәгъзе бик оятсыз, әмма бик табигый булган җирләрен күрсәтерләр. Мин дә бу сүзгә сәнаигы нәфисә тарафдары булганым өчен бер фәйләсүфчә: «Көлмәңез, җыламаңыз, анлаңыз!» дип васыять бирер идем... Безнең өчен инде җитәр, шул ук мөхәррир башка әсәрләрендә күп фәлсәфә, фикер сатты. Инде безгә мондый әсәрләр дә кирәк! Бу китап вөҗдан кагыйдәләренә хилаф, зарарлы, оятсыз» дигән кешеләргә бары шундый гына сөаль бирер идем: рәссам гаеплеме «Мадонна» (Мәрьям ана) сурәтен күреп шәһвани ләззәт алган кешеләргә? Менә шул мадоннаны табигый итеп, Рафаэль шикелле мөхәррир монда үзенең каләмен тыймаган, мөмкин кадәр тормыш, адәм өчен бик әһәмиятле булган тормышны тасвир итәргә карар биргән... Гаяз әфәнденең бу романында күп йирдә очрый торган фикер бар, хәтта ул фикер әсәрнең бәгъзе йирләрен фәлсәфә сатуга да әйләндереп җибәрә. Мөхәррирнең «Мөгаллим», «Солдат» вә башка кызыл әсәрләрен искә төшерә. Ул фидакяр Гаяз әфәнденең эш-хезмәт алдында сәҗдә кылуыдыр. Мөхәррир бу урынга җитсә, каһарманның куәтеннән тыш сүзләрне мөхәррир үзе сөйли башлый. Бәгъзан каһарманны илһам белә сөйләгән вәлиләр төсле итеп күрсәтә башлый.

Караңыз сез 95 елда язылган бер көндәлегендә нинди гимн җырлата: «Имез, ана, имез! Балаңызның әрәмтамак булмаенча, эшче булачагына ышанып, аның эшләячәк куллары, эшкә йөриячәк аяклары, эшне уйлаячак башлары үссен өчен имез!»

Дөрест, эшсезлектән туйган каһарман шундый мәфһүмдә уйлый да алыр иде. Әмма болай «Таң» сәхифәләрендәге мәкаләләр кебек уйлау «шәкерт хыялы» төслерәк бер анахронизмдыр. Мондый урыннар романда берничә урында очрый- лар.

Ниһаять, мөхәррирнең бу әсәрендә үзенең тормышны язучы, әмма социолог түгеллегенә ышанганлыгыны күреп, сәнгате мәһарәт исеменнән

тәшәккер итәргә мәҗбүр буламыз, икътидары алдында башымызны иямез». *(«Тормышмы бу?» — Вакыт. 1911, 1 май 771 сан.)*

Повестьны бик хурлап, әхлак бозуга өндәүче әсәр дип язып чыгулар да була. «Бездәге әдәбият яхуд яңа брошюралар» исемле мәкаләдә «... кеше хатыны илән мөнәсәбәттә булуларны тасвир әдәбияттан саналса, мотлакан безем бу көнге фахешханәләрнең әдәбияттан саналуы лаземдер... «Тормышмы бу?» брошюры әдәбиятымызны былчыратучы бернәрсә... Менә бездә шул фахешлек галәмене тасвирга хезмәт иткән брошюра... мактаучылар бик күп күренә, шуны күреп, акча исраф итүче әдәбиятчы агайлар да аз түгелдер» дигән юллар бар. *(Автор: «Г.»—Дин вә мәгыйшәт. 1911, 24 сан.)*

Г.Ибраһимов Г.Исхакыйның «Тормышмы бу?» повесте белән бергә «Шәкерт абый», «Мәдрәсә йимеше» хикәяләре турында «фахеш исе килеп торган бу нәрсәләр шундый күңелсез тәэсир калдыралар ки, гаилә тәрбиясенә җитди караган затлар боларны өйләренә кертү турында шөбһәгә калалар»,— ди, ул әсәрләрне «порнография» дип атый *(«Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән.— Тормыш. 1915, 26 февраль).*

И.Бикташев Г.Ибраһимов тәнкыйтенә җавап мәкаләсендә болай ди: «Порнография дип оятсыз нәрсәләрне вә шул оятсызлыкка (яхуд пычракка) укучының дәртен арттыру өчен язылган нәрсәләргә әйтәләр ки, бу Гаяз әфәндедә бөтенләй башкача — киресенчә. Аның каләме бу урыннарны язганда, әйтерсең лә шул тормыш тарафыннан җәберләнгән, каһәрләнгән каһарманнарның канлы яшьләренә буялып яза... аңлый алган кеше, ирексез, елый. Чөнки бу чын тормыш, чөнки бу тормышта безнең бетмәс-төкәнмәс кешеләребез изелә. Аның былчырак булуында мөхәррир гаепле түгел. Шундый тормышны шулай итеп язып чыгара белү Гаяз әфәндедә булган кәмаләт ул, аның әдәби тарихына бик зур плюс. Рус әдәбиятында ачык — дөрест язу берлән мәшһүр Купринга әдәби таҗ кидергән, сатлык кызлар тормышыннан алынып язылган «Яма» дигән романы, Максим Горькийның... «Трое» дигән хикәясе порнографиягә кертелмәгәндә «Тормышмы бу?», «Шәкерт абый»ларны порнографиягә кертүне, гомумән, әдәбиятны азрак

аңлаган кеше генә булдыра алыр. *(И.Бикташев.— Тәнкыйть тирәсендә.— Кояш. 1915, 13, 14 август.)*

Җамал Вәлиди Г.Ибраһимовның «Тормышмы бу?» повестена биргән бәяләмәсе белән килешми: «Галимҗан иптәш: «Бәдәвам»ны укучы карчыклар бетмәгән кебек, бәлкем «Тормышмы бу?»лардан мәгънә эзләүче карт хәлфәләр әле дә анда-монда бардыр»,—ди. Мин уйлыйм ки, «Тормышмы бу?»лардан мәгънә эзләп маташучылар арасында безнең кебек «карт хәлфәләр» генә түгел, бәлки бәгъзе яшь мөгаллимнәр, яшь шәкертләр дә бардыр. Бәлки ал арны да Галимҗан иптәшнең бу язганнары бу кадәр аптыраштa калдыргандыр. «Тормышмы бу?» минем үз карашымда Гаязның әсәрләре арасында иң өстен торганнарыннандыр. Монда реальный тормыш гаять куәтле вә ялкынлы бер шәхси тойгы белән яктырып мәйданга чыгадыр. Шуның өчен моны «Фәзаилешшөһүр»ләр белән беррәттән йөртү татар әдәбияты мөхибләренең йөрәкләрен әрнетәчәк вә аларны шаштырып калдырачак бер хәлдер... Әмма «Тормышмы бу?» тирән мәгънәле, матур телле, бай тасвирлы, чын мәгънәсе белән современный булган бер әсәр хакында мондый сүзләр әйтеп ташлауга нинди мәгънә бирергә кирәк?.. Галимҗан иптәш кеби үзен игътибарлы бер тәнкыйтьче итеп таныткан кешенең тар фикерлекне бу дәрәҗәгә җиткерүе соң дәрәҗәдә көенечле бер хәлдер, өсләренә яшьләрне тәрбия кеби мөһим бер вазыйфа йөкләнгән икән, әдәби извращение белән шөгыльләнүдер». *(Әдәби мосахәбә,— Татарстан хәбәрләре. 1922, 5 март.)*

Совет чорында Г.Исхакый иҗаты турында берьяклы гына язылып килде. «Тормышмы бу?» әсәренә бирелгән уңай бәяләмәләр түгел, ә нәкъ менә югарыда китерелгән кире бәяләмәләр генә гыйльми китапларның берсеннән икенчесенә күчеп йөрде.

Повесть Г.Исхакыйның «Зиндан» җыентыгында басылды.

Текст 11 елгы басмадан алынды.

*Нәхү* — синтаксис.

*Фикъһе* — ислам динендә хокук белеме.

*Виктория* — 1837 елдан алып Англия королевасы (1813— 1901).

*Шамил* (1797—1871) — Дагыстан халыкларының патша колонизаторларына каршы бәйсезлек көрәшенә җитәкчелек иткән шәех. 1859 елның 26 августында әсирлеккә төшә һәм Калугага сөрелә. Мәккәгә хаҗга барганда, Мәдинә шәһәрендә үлә. Шамилнең улы Мөхәммәд Шәфикъ (7—1906) патша хөкүмәтенә хезмәт итеп, генерал дәрәҗәсендә отставкага чыга һәм Казанга килеп сәүдәгәр Ибраһим Апаковның кызы Мәрьямгә өйләнә. Хәзерге көндә Казан шәһәрендә Тукай урамында Габдулла Тукай музее Апаковлар салдырган, халыкта «Шамил йорты» дип йөртелгән йортка урнашкан.

*«Вә рөтбәттә галә мөкаддәмәт вә сәлясә мәкаләт вә хати-мәт»не ишетү... мине әллә нишләтеп җибәрде* —бу урында повестьтагы вакыйгалар Г.Исхакыйның тәрҗемәи хәленнән туп-туры «күчерелгән». Язучы үзенең гарәп хәрефләре белән төрек телендә язылган, берничә вариантта каралама килеш сакланган «Тәрҗемәи хәлем»ендә Чистай мәдрәсәсендә шәкерт чагында әнисенең туган авылы Мөслимгә әбиләренә кунакка баруы һәм беркөнне иртән йокыдан уяныр-уянмас ятканда күрше бүлмәдә әбисенең бер кызга гадәттә мәдрәсәдә генә өйрәнелә торган «Шәмсия» китабын өйрәтеп маташуын ишетә, һәм ул китапның кызчык кулына ничек эләгүен белешә. Әдип болай яза: «Казанда Шиһабетдин әл-Мәрҗани шәкерте Шәйхетдин абзый язын түләмәдән вафат иткән, аның бер сандык китабы мәдрәсәдән кире кайткан... «Исагуҗи тәфсире», «Мулла Садыйк», мантыйктан «Сөлләмелголүм», «Тәһзиб», Тафтазани китабы, фикъһедән «Тәүзыйх» китапларыннан башка беркадәр госманлы төрекчәсендә язылган, Истанбулда басылган китаплар бар иде. Сәгыйдулла абзый: «Болар бездә буш ята, сиңа, шәкерт кешегә, ярарлык булса, ал шуларны»,— диде. Мин егерме-утыз кадәр гарәпчә, төрекчә китапларны туплап өйгә кайттым. Хәзер дә хәтеремдә, бу китаплар арасында Сәлим Сабит имзалы «Җәгърафия» китабы, бер«Госманлы тарихы» һәм бер «Әндәлес тарихы» бар иде. Бу китаплар минем өчен бер хәзинә булды.

Мантыйк китаплары — минем киләсе елларда укыячак дәреслекләремә, ә төрекчә китаплар бу вакытка кадәр һичбер күрмәгән бер гыйлемгә кертә иде. Авылыбызга (Яуширмәгә.— Л.Г.) кайткач, мин «Җәгърафия» китабын укырга һәм карталарын карарга тотындым. Картада ислам дәүләтләре дикъкатемне җәлеб итте... Мөселман мәмләкәтләренең ни өчен аерым-аерым дәүләтләр булулары, ни өчен берләшеп, бөтен дөнья кяферләренә каршы бер дәүләт тәшкил итмәүләре турында уйлана һәм шулар хакында әтиемнән сораша идем. Бу китаплар арасында иң яратканым «Госманлы тарихы» һәм «Әндәлес тарихы» булып, госманлы теле белән дә беренче тапкыр очрашуым иде. Бу китаплар темалары белән дә, теле белән дә минем дикъкатемне нык җәлеб иттеләр һәм мин, 12—13 яшьлек бер бала, бу китапларны берничә тапкыр укыдым... Аерым алганда, «Әндәлес тарихы» күңелемдә күп нәрсәләр уяндырды, госманлы (төрек,— Л.Г.) әдәбиятына игътибарым да шул китаплардан туды... Шуннан соң мин кайда госманлыча китап күрәм, шуны алып укый торган булдым».

Яшь Гаязның формалашуында әлеге өзектә китерелгән вакыйгалар — фактларның да билгеле бер роле булгандыр дияргә мөмкин.

*«Шәмсия»* — шәригать законнары системасын өйрәтүче китап; мәдрәсәләрдә дәреслек булып йөргән.

*«Тарихы Госмани»* — «Төрек тарихы», берничә китап шул исемдә йөргән.

*«Алты бармак»* — төрек язучысы Мөхәммәд Чокрыкчызадәнең чәчмә әсәре, XVI гасырга карый. Проза белән язылган. Эчтәлеге белән «Мөхәммәдия»гә охшый — Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең тәрҗемәи хәлләре бәян ителә.

*Әндәлес* — Көньяк Испаниядәге тарихи бер өлкә; күбрәк халкы гарәпләр булган Кортоба (Кордова), Гарната (Гранада) шәһәрләре борынгы гарәп культурасы үзәкләре булганнар.

*«Асаре Сәлим Сабит»* — Сәлим Сабитның «Җәгърафия» китабы.

*Зыяндаш* — вакыт-вакыт аң югалту һәм көзән җыеру рәвешендә өянәкләре була торган нерв авыруы.

*Аксак Тимер* — Тимерлән, Тимур, Тамерлан (1336—1405), Урта Азиядән чыккан әмир. Ул 1372—1405 еллар арасында егермедән артык зур сугыш походлары оештырган, Алтын Урдага, Һиндстанга һәлакәтле һөҗүмнәрдән соң, 1400—1402 елларда Төркияне яулап алып, төрекләрне аяусыз каты кысынкылыкларга дучар иткән, илне хәрабәгә әйләндергән. Г.Исхакый монда шуны күздә тота.

*Ахак* — кыйммәтле таш буларак, бизәү әйберләре өчен файдаланыла торган, төрле төстәге берничә катламнан гыйбарәт каты минерал.

*Кырык газизләр* — «гаип ирәннәр» дип тә йөртелә, күзгә күренмичә генә кешеләргә изгелек эшләп йөрүче затлар.

*Пырак (Борак)* —дини ривайәттә: Мөхәммәд пәйгамбәрне күз ачып йомганчы Мәккәдәге әл-Мәсҗид өл-Хәрәмнән Бәйтел-мөкатдәстәге (Иерусалимдагы) әл-Мәсҗид әл-Аксага («Иң ерак мәчет») илткән сихри ат. Соңыннан Мөхәммәд, ул атны Бәйтелмөкаддәстә калдырып, яктылык баскычы буенча Алла белән сөйләшергә күккә ашкан. Бу төн — Миграҗ төне дип атала.

*Йосыф, Зөләйха* — XII—XIII йөз болгар-татар шагыйре Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы геройлары.

*Алты берлә сугу* —алты кешенең кара каршы басып чабагач белән ашлык сугуы, башактан орлык төшерүе.

*Хан мәсҗеде* — Казан Кремлендәге архитектура истәлеге булып саналган Сөембикә манарасы.

*Мәкәрҗә* — Түбән Новгородка якын Макарьево бистәсендә ярминкә.

*Мәһди* — дөрес юлдан алып баручы. Дини ривайәт буенча, кыямәт көне алдыннан Мәһди чыгың, азынган халыкларны туры юлга салачак, имеш.

*«Гакаид»* — иман, дини ышанулар турындагы китап. Авторы: Низаметдин Нәсәфи (1068—1142). Мәдрәсәләрдә ул китапның үзен түгел, ә шул әсәргә шәрех китапларын өйрәнгәннәр. Халык арасында Сәгъдеддин Тафтазани (1321—1390) тарафыннан язылган «Шәрхе гакаиде Нәсәфи» киң таралган булган. Бу китап Казанда 1897 елда басылып чыккан. Габденна- сыйр Курсавиның да «Гакаид»не шәрехләп язган китабы бар.

*Шигый* — дүртенче хәлифә Гали һәм аның балаларына тарафдарлык мәзһәбе (юлы, юнәлеше) — мөселман динендәге ике төп юнәлешнең берсе.

*Хәзрәти Әбүбәкер, хәзрәти Гали* — Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң килгән бөек хәлифәләрдән (калганнары: Гомәр, Госман).

*Зәкят* — дин буенча, һәр мөселманга еллык керемнең 40 тан бере күләмендә салынган еллык налог.

*Әбҗәд, һәүваз* — борынгы гыйбрани (яһүд) әлифбасындагы хәрефләр тәртибен күрсәтү өчен ясалган сүзләрнең беренче икесе (калганнары: хоттый, кәләмән, сәгъфәс, коришәт, сәхоз, зазог). Бу сүзләрдәге тартыклар тәртибе берлеләр, унлылар, йөзлеләрне һәм ахыргы «Г» мең санын белдерә.

*Сарыф* — морфология.

*Пассаж* — борынгы шәһәрләрдә төзелеш өчен мәйданның аз булуын, сәүдә һәм җәмәгатьчелек учреждениеләрен урнаштыру заруриятен күздә тотып, яңа төр биналар — пассажлар салына башлый. Пассаж композициясенең төп нигезе — өстән яктыртылган (башы пыяла белән ябылган) һәм ике урамны тоташтыра торган галерея. Унтугызынчы йөзнең 80 нче елларында шундый бина — пассаж Казанда да төзелеп бетә. Фасадлары белән Воскресенская (хәзерге Кремль) һәм Черноозерская (хәзерге Дзержинский) урамнарына чыккан галереяның ике ягында берничә яруста күпсанлы кибетләр, учреждениеләр урнашкан була. Шулай итеп, урамдагы ыгы- зыгылы сәүдә тормышы биналар тирәнлегенә күчә.

*Проломный* — хәзерге Бауман урамы.

*Ләкин ник бу романнарның кешеләре барсы да Жор, Альфред, Карл, Эмма, Катрин кеби ят исемнәр? Төрекләрнең уз тормышыннан ник язылмаган ?* — Унтугызынчы йөздә Танзимат (1839— 1878) чорында Төркиянең мәдәни кыйбласы Аурупага таба борыла. Аурупа буржуаз җәмгыятенең, бигрәк тә французларның, иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник, әдәби-мәдәни өлкәләренә караган лексик берәмлекләр төрек теленә үтеп керә башлый. Күп кенә төрек язучылары әсәрләрен француз язучылары романнарына ияреп язалар. Бу турыда Г.Исхакый гасыр башында ук тәнкыйть мәкаләләре белән чыга. Мәсәлән, ул «Нур» гәзитәсендә барган тел бәхәсләренә катнашып, кайбер әдипләрнең әдәби тел итеп иске татар телен (гарәп, фарсы сүзләре күп кергән)

алырга кирәк диюләрен кабул итми, «әдәби тел», «гавам» теле дип бүлеп карауга каршы чыга. «Әдәби тел»не үз телемез, димен. Үземезнең сөйли торган телдә язарга тиеш, димен» ди дә төрекләрдәге аянычлы мисалны китерә: «Төрек әдәбиятын төрек рухыннан аерган... төреклекне белмәгән госманлы мөхәррирләре... телләренә әллә никадәр фарсы, гарәби, француз сүзләреннән уйдырма ясап, әдәбиятларыны шул «хәерче капчыгы» берлән изделәр... Ләкин төрек нишләде? Төрек, ягъни гауме төрек гүя Истанбулда матбага юк кебек бу китапларны... белмәде дә, аңламады да, төрек булды да калды»,—ди. (Тел.— Нур.— 1905, 8 нче сан.)

Г.Исхакый әлеге «Тормышмы бу?» повестен язган чорда һәм шәһәрдә (1909 ел, Истанбул) төрек матбугатында зур-зур мәкаләләрен тел мәсьәләсенә багышлый. Биредә ул төрек теле турында кайгырта.

Мәсәлән, әдип «Сирател мөстәкыйм» («Туры юл») журналында төрек әдәбиятының күп заманнар югары сыйныфларга хезмәт итүе турында яза: «Аурупада да гавам тарафдарлары һәм югары катлам тарафдарлары, ягъни артистократия белән демократия тарафдарлары бар иде. Ләкин Аурупа тарихлары боларның кайсысы дөрес икәнлеген күптән инде күрсәттеләр. Фәкать бу тарих дәресе безнең госманлы төрекләренә тәэсир итә алмады. «Тел садә булса, кабул булмаячак», имеш, «тел садә булса, матурлыгы бетәчәк», имеш... Менә Сөләйман Назыйф бәкнең мәкаләсендә баштан ахырга кадәр мондый дәлилләр күп китерелә... Фәкать төрекчә укый-яза белгән 15 миллион госманлы төрекләренә «Әфәндем, сезнең телегез тупастыр, сез аңлаган телдә язсак, безнең укымышлы әфәнделәрнең, югары тәрбия күргән затларның кәефе кырылачактыр. Сез төрек, сездә ни сәясәт, ни әдәбият, ни мәгариф» диячәксезме? Әллә алар аңлый торган телдә аерым гәзитәләр, рисаләләр чыгарачаксызмы?.. Бу фикерем ялгыз бер лыгырдаудан гыйбарәт түгеллеген исбатлар өчен, мин Русия татарларының тормышыннан бер мисал китерәм — моннан биш-алты ел элек безнең татарларда да «әдәби тел», «садә тел» бәхәсе бар иде. Безнең «әдәби тел» тарафдарлырыбыз сез китергән дәлилләрне китерделәр, ләкин өч-дүрт ел узмады, болар җиңелүләрен таныдылар. Хәзер

бездә гәзитә мәкаләсен булсын, рисаләне яки театр әсәрен булсын — Ру сиянең шәһәрләрендә дә, авылларында да андыйлар. Хәзер без матбугатта тормышның төрле яклары турында бер телдә аңлатабыз. (Казанлы Гаяз.— Лисан мәсьәләсе.—Сирател мөстәкыйм.— 1909, 42 нче сан, 316 бит.)

Төркия матбугатында Г.Исхакыйның мәкаләсенә каршы язып чыгучылар да була. Шундыйларның берсенә — Гали Носратбәккә җавабында ул «әдәби тел»не халык теленнән ераклаштыру милләтнең үсешен тоткарлый, ди. «Мәкаләгездәге 1440 сүзнең нибары 368е — төрекчә... Ни өчен сез ап-ачык аңлашылып торган фикерләргә фанатикларча каршы киләсез? Моның сәбәбе ни? Минемчә, моның иң зур сәбәбе сезнең төрекчә белмәвегездә». (Казанлы Гаяз.— Лисан мәсьәләсенә даир.— Сирател мөстәкыйм — 1909, 50 нче сан, 380 бит.)

*Бакыр бабай бакчасы* — Казанда хәзерге Карл Маркс һәм Пушкин урамнары чатында М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры урынында (Ленин исемендәге бакчаның дәвамы) булган мәйданда рус шагыйре Г.Р.Державинга (1743—1816) бакыр һәйкәл куелган булган. Татарлар аны «Бакыр бабай бакчасы» дип йөрткәннәр.

*Яхъя мулла пәриләре* — Яхъя бине Сәфәр бине Арслан 1838 елда Татарстанның Арча районы Шекә авылында үлгән. Ш.Мәрҗани аның турында: «Халык арасында Яхъя ишан исеме белән... мәшһүр иде. Халык арасында әле дә куәтле җил яки тавыш ишетелгәндә, Шекә пәриләре дип сөйлиләр»,—дип яза. Яхъя муллага ияләшкән пәриләр, имеш, хуҗаларының һәммә теләген үтиләр икән. Шул хакта халыкта ривайәтләр иҗат ителгән. Шуларның берсе: «Яхья хәзрәт бервакыт кунаклар җыйган. Кунаклар өйдә ашап-эчеп утыралар икән. Шул вакытны Яхья хәзрәт аларның атларын төз лапас түбәсенә мендереп куйган. Кунаклар атларын карарга чыккач, аларны төз лапас түбәсендә күреп бик гаҗәпкә калганнар.

Кунаклар бүлмәдә утырганда эссе, тынчу була башлагач, йортның тәрәзәләре үзләреннән-үзләре ачылып киткән. Кунаклар хуҗаның бу хикмәтләренә бик гаҗәпләнгәннәр, ди».

Яхья мулла һәм пәриләре турындагы ривайәтләр «Татар халык иҗаты, ривайәтләр һәм легендалар» китабында бергә туплап бирелгән. (Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы С.Гыйләҗетдинов.— Казан. 1987, 258 бит.)

*Руза гаете* — мөселманнарда рамазан аенда 30 көн ураза тотканнан соң уздырыла торган бәйрәм.

*Фитыр* — ураза тәмамлангач бирелә торган садака.

*Гошер* — мөселманнардан ярлылар өчен алына торган салым. Ул барлык уңышның уннан берен тәшкил итә. Мөселман илләрендә гошер дәүләт казнасына кергән, ә патша заманында Рәсәйдәге мөселман халыклар аны ярлыларга өләшкән, руханиларга биргән.

*Бәйтелмөкатдәс* — Иерусалим (Коддес) шәһәрендәге изге гыйбадәт йорты.

*Тәфсире хәдис* — Мөхәммәт пәйгамбәрнең хәдисләрен андату.

*Кыямәт (көне)* — дини тәгълимат буенча: ахырзаман җитеп, Исрафил пәйгамбәр сур өргәннән соң, үлгән кешеләр барысы да терелгәч, аларга Алла тарафыннан үткәрелә торган хөкем көне.

*Көпе* — куй йонынннан сырып тегелгән бишмәт.

*Ясигъ* — кояш баегач, төнлә укыла торган намаз.

*«Дөррәтеннасыйхин»* — («Нәсыйхәт сөйләүчеләрнең энҗеләре»), урта гасырда язылган дини-әдәби әсәр. Казанда 1870— 1879 елларда басылган.

«Тәрбиятелгафилин» — «Гафил (белми) калганнарга тәрбия»; китап исеме.

*«Төхфәтелмөлек»* — («Патшалар бүләге»), Зәйнетдин Мөхәммәд бине Әбү Бәкер Әрразыйның (XIII гасыр) фикъһ ислам хокук фәне) буенча китабы.

*«Мөраделгарифин»* — («Суфыйлык юлында иң югары дәрәҗәләргә ирешүчеләрнең максаты»), Суфый Аллаһиярның суфыйлык буенча тезмә әсәре. XVII гасырга карый. Татар мәдрәсәләрендә дәреслек булып йөргән.

*«Дөррелмәҗалис»* — («Мәҗлесләр энҗесе»), Сәйфе Баһар бине Борһанетдин Нәүбаһарның суфыйлык буенча китабы. Татарлар арасында популяр әсәр булган.

*Дон Кихот* — Испания язучысы Сааверда Мигель Сервантесның (1547—1616) «Тапкыр рыцарь Дон Кихот Ломанческий» (1609) исемле романы герое. Бу исем киң таралып, аны изге ниятләре, омтылышлары чынбарлык белән фаҗигале каршылыкка очраган кешегә карата әйтәләр.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.33-102.